Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2024

**Духовное наследие**
Поиски и открытия
*Выпуск 25*

**Салах Камал**

# СТАРИННЫЕ ТАТАРСКИЕ ШКОЛЫ И МЕДРЕСЕ

**Рухи мирас**

Эзләнүләр һәм табышлар

*25 нче чыгарылыш*

**Сәлах Камал**

# БОРЫНГЫ ТАТАР МӘКТӘП-МӘДРӘСӘЛӘРЕ

УДК 94 (093)
ББК 63.2
К 18

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау»
ТР Дәүләт программасы кысаларында ТР Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Язма мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**

***И.Г. Гомәров*** *(проект җитәкчесе),*
***А.М. Ахунов, Ф.Ф. Гыйлемшин***

**Фәнни редактор**

*филология фәннәре кандидаты* ***И.Г. Гомәров***

**Рецензентлар:**

*филология фәннәре докторы* ***Л.Р. Надыршина****,*
*филология фәннәре кандидаты* ***Г.Н. Зәйниева***

**К 18** **Камал С. Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре** / С. Камал; төз., текст. иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, А.Н. Хәсәнова. – Казан: ТӘһСИ, 2024. – 160 б. («Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия» сериясе. 25 нче чыгарылыш).
ISBN 978-5-93091-503-7

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең 25 нче чыгарылышы педагог, рәссам, каллиграф, җәмәгать эшлеклесе, күпсанлы дәреслекләр һәм укыту әсбаплары авторы Камалетдинов Сәлахетдин Камалетдин улының (1885–1954) «Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре» хезмәтен үз эченә ала.

Басма белгечләр, татар мәдәнияте, мәгарифе һәм тарихы белән кызыксынучы киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-503-7

© ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2024

# С. КАМАЛ ҺӘМ АНЫҢ «БОРЫНГЫ ТАТАР МӘКТӘП-МӘДРӘСӘЛӘРЕ» ХЕЗМӘТЕ ТУРЫНДА

Татар мәгарифе өлкәсендә зур хезмәт куйган һәм үзеннән соң бай мирас калдырган шәхесләребез арасында исемнәре киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаганнары да байтак. Бу китапта шуларның берсе – педагог, рәссам, каллиграф, ташка уеп ясаучы, җәмәгать эшлеклесе, дәреслекләр һәм укыту әсбаплары авторы Сәлах Камалның «Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре» хезмәте укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

Камалетдинов Сәлахетдин Камалетдин улы (Сәлах Камал) 1885 елның 10 маенда Тәтеш өязе Апас авылында мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне Буа районы Иске Шәйморза авылы мәктәбендә ала, соңыннан укуын Буада, Казандагы Айтугановлар мәдрәсәсендә дәвам итә. 1901 елда дөньяви белем алу теләге белән, Төркиягә китә, Константинополь университетын тәмамлый (1905).

1905–1943 елларда Хөсәеновлар мәдрәсәсендә, Шәрык халык мәгарифе институты, Татар халык мәгарифе институты, Башкортстан педагогия институты, Хива шәһәрендәге Хатын-кызлар педагогия техникумы, Казан татар педагогия техникумы һ. б. уку йортларында физика, рәсем сәнгате, сызым, татар тарихы фәннәрен укыта, төрле педагогик курслар оештыра, аларның эшендә үзе дә катнаша.

Гражданнар сугышы чорында (1919–1920) Көнчыгыш (соңыннан Төркестан) фронтының 1 нче армиясе сәяси бүлегендә рәссам булып эшли.

Балачактан ук рәсем ясау һәм гамәли сәнгать техникасы элементлары белән мавыккан С. Камал татарлар арасында график сәнгатьне пропагандалый. Рәсем, сызым кебек предметларның татар мәктәпләрендә укытыла башлавында да аның өлеше зур.

Казан университеты китапханәсендә сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге мөдире булып эшләгән чорда (1946–1954), ул Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Утыз Имәни, Г. Курсави, Г. Чокрый, Х. Габәши кулъязмаларын, фольклор материалларын һ. б. кулъязмаларны тасвирлап тәртипкә китерә.

С. Камал 1954 елның 15 февралендә эш өстәле артында вафат була.

* * *

С. Камалның «Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре» исемле хезмәте 1945–1946 елларда Тел, әдәбият һәм тарих институты җитәкчелеге соравы буенча языла. Мәдрәсәләр тарихы аеруча киң

яктыртылган әлеге кулъязмада мәдрәсә тормышының байтак нечкәлекләре дә тасвирлана.

Хезмәтнең беренче бүлеге борынгы татар мәктәпләренә багышлана. «Ир балалар өчен башлангыч мәктәп» бүлекчәсендә төп игътибар мәктәпнең урынына, эчке һәм тышкы күренешенә, хуҗалык һәм эчке тәртип кагыйдәләренә юнәлтелә. Автор дәреслекләргә җентекләп туктала, язу өйрәтү, ана теле, хезмәт һәм сәнгать дәресләре турында мәгълүматлар бирә.

«Кыз балалар өчен башлангыч мәктәп» дип аталган икенче бүлек исә чагыштырмача кыска, һәм ул кызлар мәктәбендә укучылар һәм укытучылар составы, укыту программасы, дәреслекләр һәм укыту методларын колачлый.

Өченче бүлек – «Борынгы татар мәдрәсәләре» – хезмәтнең иң саллы өлеше. Анда мәдрәсәләрне оештыру тарихы, аларның эчке-тышкы күренешләре, идарә, эчке тәртип кагыйдәләре, уку-укыту барышы, мәдрәсә программалары, уку планнары, дәреслекләр, уку-укыту методлары белән танышырга мөмкин.

Хезмәттә мәдрәсәләрдәге кызыклы вакыйгалар, бәйрәмнәр белән беррәттән шәкерт-хәлфәләрнең көндәлек тормышыннан да төрле хәл-әхвәлләр бәян ителә.

Заманында татар халкы тормышында зур урын тоткан ысулы җәдит хәрәкәте һәм җәдиди мәктәп-мәдрәсәләр турындагы дүртенче бүлектә автор аларның уку-укыту программалары, планнары һәм расписаниеләренә кыскача гына туктала. Моны ул алар турында аерым хезмәт таләп ителү белән аңлата.

С. Камалның әлеге хезмәте бүген кулъязма хәлендә Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондларында саклана. Ул автор тарафыннан тулысынча эшләп тәмамланган, тикшереп басмага тәкъдим ителгән текст түгел. Шуңа күрә анда стиль җәһәтеннән уңышсызрак төзелгән җөмләләрне, аерым бер грамматик хаталарны да очратырга мөмкин. Бу китапта әлеге текст, автор стилен саклаган хәлдә, берникадәр редакцияләнеп тәкъдим ителә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар халкы тормышында зур урын тоткан мәктәп-мәдрәсәләр тарихы, анда укыткан һәм белем алган шәхесләргә бәйле тарихи ядкәрләр әле тиешле дәрәҗәдә тикшерелмәгән. Аларны туплау, өйрәнеп, укучыга тәкъдим итү – безнең алда торган бурычларның берсе. С. Камалның «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясендә нәшер ителгән хезмәте дә тарихтагы ак тапларны бетерүдә кыйммәтле чыганакларның берсе булыр дип ышанасы килә.

*Айгөл Хәсәнова*

# КЕРЕШ СҮЗ

Борынгы татар мәктәпләре һәм борынгы татар мәдрәсәләре татар тормышында тарихи фактор булып торалар. Шушы ноктадан караганда, борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре татар тарихында күренекле бер урын алып торырга тиешле булалар.

Яшь укучылар, педагогик уку йортларында укучы студентлар һәм совет яшьләре борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре белән таныш түгелләр. Моны яшереп булмый.

Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре белән таныш булмаганда, хәзерге татар мәктәпләренә дөрес бәя бирү шактый авыр. Шушы яктан караганда, борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләренә педагогиканың үзендә дә һәм аның тарихында да лаеклы урын бирелергә тиешле була.

Шактый озын тарихка ия булган бу мәктәп-мәдрәсәләрнең үзенчәлекле һәм катлаулы төзелешләренең шул замандагы халыкларның иҗтимагый һәм икътисади якларына бәйләнеше бар. Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләренең шушы якларын татар укытучысы, һич шөбһәсез, белергә тиешле.

Борынгы татар мәктәпләрен һәм мәдрәсәләрен ачу турындагы хөкүмәт карары XVIII йөзнең икенче яртысында була[1]. Ләкин бу карар моннан элек татар мәктәп-мәдрәсәләре булмавын күрсәтми. Мондый уку йортлары бу карардан гасырларча элек тә яшәп килгәннәр.

Татар мәктәп-мәдрәсәләре, үз тарихларында хөкүмәт тарафыннан матди яки мәгънәви буларак, бертөрле ярдәм күрмәделәр. Киресенчә, патша хөкүмәте татар мәктәп-мәдрәсәләреннән тыгызланды. Кирәк булганда, аяк чалудан да кире тормады. Хөкүмәтнең татар мәктәп-мәдрәсәләре турындагы карары авыз ерта торган коры кашык кына иде.

Бөек Октябрь революциясеннән соң татар халкы киң һәм иркен сулыш алды. Партия һәм Советлар хөкүмәтенең дөрес сәясәте, гадел кайгыртучанлыгы аркасында, татар халкы чын мәгънәсе белән

[1] Биредә Сенатның 1773 елның 10 июнендә имзаланган «О терпимости всех вероисповеданий и о запрещении архиереям вступать в разные дела, касающиеся до иноверных исповеданий и до построения по их закону молитвенных домов, предоставляя все сие светским начальствам» фәрманы күз уңында тотыла.

киң мәдәният юлына аяк басты. Аз гына бер вакыт эчендә бик күп санда мәктәпләргә һәм культура йортларына ия булды. Шушы мәктәпләр аркылы татарлар арасыннан фән, техника һәм промышленность өлкәсендә меңләгән кадрлар җитеште. Менә шушы ике чордагы ике төрле уку йортларын бер-беренә чагыштырганда хәзерге тормышыбызга да, хәзерге мәктәпләребезгә дә туры бәя биреп була.

Ысуле җәдидә[1] хәрәкәте, ысуле җәдидә мәктәпләре турында матбугатта бик күп материал табарга мөмкин. Бу турыдагы материал Октябрь революциясенә кадәр булган матбугатта да, Октябрь революциясеннән соңгы матбугатта да күп, андый кульъязмалар бик күп санда гыйльми китапханәләрдә дә саклаunion. Димәк, ысуле җәдидә хәрәкәте, ысуле җәдидә мәктәпләре тарихыбызга кереп урнашкан була. Ләкин борынгы мәктәп-мәдрәсәләр турындагы материаллар һәр ике матбугатта да бик аз. Бу турыда һәр ике матбугат бик ярлы. Димәк, әле борынгы мәктәп-мәдрәсәләребез тарихыбызга кереп урнаша алмаган була. Аларны тарихыбызда ныгыту өстә изге бурыч булып тора.

Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре турында язу фикере язучылар арасында күптән кузгалган иде. Берничә иптәш бу эшне башлап та җибәргәннәр иде, ләкин бу иптәшләрнең гомерләре вафа итмәде[2] – вафат булдылар. Әсәр мәйданга чыга алмый калды.

Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре турында язганда, матбугатта канәгатьләнерлек материал булмагач, әлеге хезмәтне очлап чыгу һәркемнең көченнән килми. Бу хезмәтне башкаручы шул мәктәп, мәдрәсәләрне күргән, шуларның ачысын-төчесен татыган кеше булырга тиеш. Борынгы мәктәп, мәдрәсәләрдә кайнаган кешеләр хәзер бетеп баралар, алар хәзер Казанда, турысы Татарстанда бармак белән санарлык кына калдылар. Берничә елдан алар да юкка чыгачаклар. Бу зур хезмәтне башкару өчен, борынгы мәктәп-мәдрәсәләрне күрү генә җитеп бетми әле. Борынгы мәктәпләрне белү өстенә Совет чынбарлыгы белән дә нык таныш булырга кирәк.

Бабаларыбыз – Идел болгарлары – X йөз башларында гарәп-ислам тәэсиренә бирелгән булсалар, шул йөзнең эчендә Болгар шәһәрендә гарәп культурасына нигезләнгән, гарәп гореф-гадәтенә бирелгән мәктәп-мәдрәсәләрнең булуында шик тотарга ярамый.

[1] Ысуле җәдидә – җәдитчелек; уку-укыту системасындагы яңарыш хәрәкәте.
[2] Вафа итмәде – монда: мөмкинлек бирмәде.

Димәк, борынгы татар мәдрәсәләренең тарих очы Болгар, Суар һәм Биләр мәктәп-мәдрәсәләренә барып тоташа.

Мөселман шәрык культурасы Мавәраэннәһергә (Междуречье) күчеп, Сәмәрканд, Бохара шәһәрләре гыйльми мәркәзгә әйләнгән бер чорда, Болгар мәдрәсәләре Мавәраэннәһер тәэсиренә биреләләр. Шул көннән башлап бу мәктәп-мәдрәсәләрдә Сәмәрканд-Бохара гореф-гадәтләре урнаша башлый.

XVI йөз ахырында – XVII йөзнең башларында, тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә, Болгар мәктәп-мәдрәсәләре «татар мәктәп-мәдрәсәсе» исеме белән йөртелә башлыйлар һәм шушы көннән башлап, борынгы татар мәктәп-мәдрәсәсендә Мавәраэннәһер программасын кабул итәләр һәм Мавәраэннәһер уку-укыту системасына нигезләнәләр.

Борынгы татар мәктәпләренең программасы белән Бохара мәдрәсәләренең программаларын чагыштырып карагыз, бер-береннән бик ерак булган бу ике өлкә мәдрәсәләренең дәреслекләренә һәм гореф-гадәтләренә күз салыгыз. Ике мәдрәсә арасында кардәшлек, берлек күрерсез.

Борынгы Бохара һәм Сәмәрканд мәктәп-мәдрәсәләре көчле контроль астында тордылар. Дини һәм сәяси нокталардан чыгып куелган шушы контроль аркасында мәктәп-мәдрәсәләрнең программаларында да, дәреслекләрендә дә һәм гореф-гадәтләрендә дә үзгәреш ясарга мөмкин булмады. Мәдрәсәләрдә үзгәреш ясау турында сүз чыгару, фикер әйтү динне җимерү, тәхеткә һөҗүмнең башы дип каралды. Шушы уңай белән, мәдрәсәләрнең үз эчләрендә, шәкертләр арасында да, мөдәррисләр арасында да һәм голәма арасында да шымчылар тотылды. Бу шымчылар мәктәп-мәдрәсәләр турындагы «төймәне дөя» итеп күрсәттеләр. Нәтиҗәдә Сәмәрканд һәм Бохара мәдрәсәләренең программалары да, дәреслекләре дә гасырлар буена үзгәреш күрә алмадылар.

Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләренә беркем тарафыннан да контроль ясалмады. Борынгы татар җәмәгатьчелеге контрольне кирәк дип уйламады. Мәктәп-мәдрәсә башында торучы муллалар программа белән дә, дәреслекләр белән дә үзләре теләгәнчә эш иттеләр. Шуның нәтиҗәсендә, борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре арасында үзгәреш барлыкка килде. Ләкин бу үзгәрешләр нигездә түгел, фәкать тармакларда гына иде. Шуңа карамастан бу үзгәреш һәркемнең күзенә бәрелерлек ачык иде.

Борынгы мәктәп-мәдрәсәләр чорында татар укымышлылары өчен «хезмәт ишеге» бер генә – мулла булып, мәдрәсә ачу, шәкерт тәрбия итү иде. Моннан башка ишекләр укымышлылар өчен ябык иде. Шуның өчен һәрбер укымышлы берәр мәдрәсә башында торып, шәкерт тәрбия итүне үзенә бурыч итеп куя иде. XVIII һәм XIX йөзләрдә хәзерге Татарстанга караган урыннарда гына илле-алтмышлап мәдрәсә булган. Бу мәдрәсәләр үз вакытында гөрләп-шаулап торганнар.

Казан дәүләт университеты карамагындагы гыйльми көтепханәдә саклана торган кульъязмаларга күз салсак, аз гына вакыт эчендә бик зур мәдрәсә исемлеге төзеп була: Чистай, Әлмәт, Бәйрәкә, Тайсуган, Мәчкәрә, Көек, Теләнче Тамак, Саба, Сулакаш[1], Сатыш, Сәрдә, Кышкар, Мәңгәр, Түнтәр, Яңасала, Норлат, Дәвеш, Буа, Шәйморза, Кишет, Тымытык, Вәреш, Мөндеш, Арбаш, Мәмсә, Сасна, Кавал, Суыксу, Кенәр мәдрәсәләре гади авыл мәдрәсәләре түгел, бәлки киң колачлы мәдрәсәләр иде. Бу мәдрәсә шәкертләре тарафыннан язылган кульъязмалар шушы фикерне аныклыйлар.

Бик күп санда булган мәктәп-мәдрәсәләр башында бик күп санда укымышлылар утыра. Бу укымышлылар белем ягыннан да, дин һәм дөньяга караш ягыннан да тигез түгел. Укымышлылар арасында хөббеннәфес – самолюбие, рәкабәт – конкуренцияне дә исәпкә алырга кирәк. Менә шушы ноктадан караганда борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләрендәге үзгәрешләрнең төп сәбәбе түбәндәге була:

1. Мәктәп-мәдрәсә башында утыручы укымышлыларның белем дәрәҗәләренең төрлелеге: югарылыгы, түбәнлеге.
2. Укымышлыларның дин һәм дөньяга карашларының төрлелеге.
3. Шул ук укымышлылар арасында булган конкуренция һәм фикер көрәше.

Димәк, белем дәрәҗәләре югары булган хәзрәтләр мәдрәсә программасын тулы һәм киң күләмдә саклаганнар, җитди һәм катлаулы дәреслекләр кулланганнар. Белем дәрәҗәләре түбән булганнары исә программаны кыскартканнар, катлаусыз, җиңел дәреслекләр кулланганнар. Шуның белән бергә, дөньяга карашларының үзенчәлекләренә карап, теге яки бу фәнгә күбрәк урын биргәннәр.

Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре турында язганда, бу үзгәрешләр авторга шактый комачаулык күрсәтәләр. Материалны билгеле

[1] Сүз хәзерге Татарстанның Әгерҗе районы Салагыш мәдрәсәсе хакында барса кирәк.

бер мәктәп, билгеле бер мәдрәсә өстендә чагылдырып, кыска юл белән барырга мөмкинлек бирмиләр.

Мин бу әсәрдә борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләренең тарихын язарга уйлаганым юк. Биредә фәкать борынгы мәктәп-мәдрәсәләр барышында һәм аларның торышында булып үткән фактларны гына теркәп үтәргә телим.

Исеменнән аңлашылганча, мин бу әсәрдә төп мәсьәлә итеп борынгы мәктәп-мәдрәсәләрне алам. Шуның өчен дә бу мәсьәләгә киң урын бирәм. Ысуле җәдидә хәрәкәте, ысуле җәдидә мәктәпләре турында бик кыска һәм схематик рәвештә генә язып үтәм.

Ысуле җәдидә хәрәкәте, ысуле җәдидә мәктәпләре – тарихи һәм гыйльми яктан шактый киң өлкә. Бу мәсьәләне тулы һәм киң итеп язарга кирәк. Бу үзенә аерым тикшеренүне таләп итә.

Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре турында булган материаллар бу хезмәткә тәмам урнашып беткән фикерендә түгелмен, монда теркәлмәгәннәре теркәлгәннәреннән күбрәк әле. Мин бу әсәр белән әлеге мәсьәләне башлап җибәрү хезмәтен үтәдем. Калган материалларны башка иптәшләр теркәрләр дип ышанам. Минем кулдан килгән хезмәт шул кадәр.

*Сәлах Камал,*
*Казан*

# БОРЫНГЫ ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕ

## I. ИР БАЛАЛАР ӨЧЕН БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘП
*(мәптек яки мәфтек)*

### *Мәктәпнең урыны, эчке һәм тышкы күренеше*

Гадәттә, мәчетсез татар авыллары бик сирәк була. Күп авылларда берничә мәчет була. Җиде-сигез мәчетле татар авыллары да аз түгел иде.

Татар авылларында мәчетләрнең күп булуы аның кирәклеге белән бәйләнмәгән. Мәчет күп булуның сәбәбе төрлечә:

• Мулланың ике улы бар. Аларның башка авылларга мулла булып урнашулары икеле. Белем ягыннан игътибарлары чамалы. Шуны сизенеп, мулла план кора. Улларының берсенә үзе янына икенче мәчет торгыза: менә сиңа бер авылда ике мәчет.

• Авыл баеның мулла белән эше пешми. Ике арадагы ачыклык ачылганнан-ачыла. Байның мулладан ачу аласы килә. Мулладан ачу алуның иң зурысы – мәчет салып, мәхәлләне бүлү. Авыл куштаннарын ашату-сыйлау юлы белән мәхәллә икегә бүленә. Авылда тагын бер мәчет арта.

• Байның кызы бар. Аны муллага биреп, кызын рәхәтле, бәхетле итәсе килә. Бай үзе дә мулла бабасы булып, халык арасында күренекле булу белән кызыксына. Тотылган юлларның нинди булуына карамастан, берәр авылга мәчет сала. Кияү хәзрәтне шул мәчеткә урнаштыра.

Борынгы гадәт буенча, авылда ничә мәчет булса, шул санда мәктәп була. Димәк, кайбер авылларда җиде-сигез мәктәп тә була ала.

Авыл мәктәпләре зурлык ягыннан да, стиль ягыннан да авыл өйләреннән аермалы булмыйлар. Алар тышкы күренеш белән авылның гади өйләренә охшап торалар. Авыл мәктәпләренең зур күпчелеге сигез-тугыз тәрәзәле кечкенә бер өйдән тора. Кайбер авылларда сирәк кенә биш стеналы зур мәктәпләр дә булгалый. Мәктәпләрнең күпчелеге салам түбәле. Такта һәм тимер түбәле мәктәпләр дә булгалый.

Гадәттә, мәктәп мәчет мәйданының тигез һәм матур бер урынына салына. Ләкин ташланган чүпләрне алмау, тазартмау нәтиҗәсендә, берничә елдан соң бу урын чүплек-тиреслек башына әйләнә.

Мәктәпләрнең әйләнәсендә бәдрәфтән башка бертөрле каралты заты булмый. Бик күп мәктәпләрдә бәдрәф тә юк, булса да, файдала-



нырга ярамый торган хәлдә җимерек була.

Мәктәп башлап салынган елларда һәр яктан төзек һәм бөтен булса да, берничә елдан аның ишек һәм тәрәзәләре таушала – укучылар тарафыннан өзлексез ясалып торган һөҗүмне күтәрә алмый. Җимерек урыннарга үз вакытында ремонт бик сирәк эшләнә. Шуның өчен тәрәзәләре төзек, ишекләре бөтен мәктәпләр бик сирәк була иде.

Мәктәпнең ишегенә керү белән, гомум идәнгә караганда түбән итеп эшләнгән бер урын була. 3–4 кв. м зурлыгында булган бу төшенке урынга «әчелек» диләр. Мишәр халыклары бу урынны «пләтән» дип атыйлар. Аяк киемнәре салу һәм кию шушы әчелектә эшләнә. Укучыларның аяк киемнәре белән кергән балчык һәм кар шушы әчелектә кала. Шунлыктан әчелек һәрвакыт җепшек һәм былчырак булып тора. Төрле былчыраклар төшеп калу аркасында, әчелектән һәрвакыт сасы һәм авыр ис күтәрелеп тора. Бу сасы ис гомуми мәктәп һавасын шактый гына бозучан була.

Әчелекнең югары почмагында мәктәпнең миче, әчелекнең ике ягында ике бүлмә була. Бу бүлмәләрнең берсендә хәлфә, казый тора, икенчесендә ярдәмче хәлфәләр яки зуррак шәкертләр торалар. Мәктәпнең гомуми мәйданы «җәмәгать сәкесе» дип атала.

Җәмәгать сәкесенең идәнендә ике урында тишек була. Кеше сыярлык бу тишекләрдән идән астына аяк киемнәре салалар. Кайбер саграк балалар аяк киемнәрен үзләре төшереп куялар. Ничек кенә булмасын, аяк киемнәрен салу, алуга караганда, бик күп җиңел һәм тиз эшләнә. Аяк киемнәрен идән астыннан алу мәсьәләсе – бик катлаулы эш. Укырга теләмәгән, укудан тәм тапмаган малайларның күбрәк вакытлары идән астында үтә. Алар анда кылмаган кылыкны[1], эшләмәгән эшне калдырмыйлар. Аяк киемнәрен тизлек белән таба алмый торган хәлгә китерәләр. Чабаталарның киндерләрен кисәләр, берсен икенчесе белән саташтыралар. Аяк киемнәрен былчыраталар.


Сабак бетү белән, барлык балалар бердән идән астына ташланалар. Талаш, кычкырыш, җылау китә. Идән өстендә башланган бу күренеш идән астына да күчә. Сәгатьләргә сузылган бу шау-шу бик

[1] Кылык – холык.

күп аңлашылмауларга сәбәп була һәм берничә бәхетсезлек белән тәмамлана: чабатасы пәке белән туралган, чабатаны әшәкеләгәннәр, чабатаны яшергәннәр. Болар – кечкенәләре. Күзгә төрткәннәр, чабуны яндырганнар, авызга нәрсәдер сөрткәннәр, тагын, тагын әлләниләр.

***Мәктәп планы***

Җәмәгать сәкесенең стена әйләнәсендә аслы-өсле ике рәт шүрлек була. Бу шүрлекләрнең өске каты ятак әйберләре (мендәр, юрган, киез шикелле әйберләр) куяр өчен, түбәнгесе китап һәм дәреслекләр куяр өчен була.




Бик сирәк мәктәпләрнең генә тәрәзәләре ике катлы, ә күп мәктәпләрнең тәрәзәсе бер генә катлы була. Күбесенең тәрәзә капкачлары да булмый, булганнары да ябылмаслык хәлгә килгән була. Шунлыктан кыш көннәрендә тәрәзә пыяласы бәс һәм боздан арынмый. Бу бозлар кыш буенча бер дә тыныч тормыйлар. Аларга балалар язулар язалар, рәсемнәр ясыйлар, акча, шуңа охшаган нәрсәләр басып, эзләр төшерәләр.

Укучылар булганда мәктәп җылына, парлана, мунчага әйләнә. Тәрәзә боздан арчыла, тәрәзә төпләре боз суыннан күлгә әйләнә. Укучылар кайтып китү белән, мәктәп суына, температура ноль градуска төшә, тәрәзә яңадан бозлана, яңадан бәсәрә.

Тәрәзә төбендә җыелган суларны өзлексез түгеп тору мөмкин түгел. Моңа җиңел юл табылган: тәрәзә рамын тишеп, суны урамга агызалар. Рамдагы тишек тик тормый, ул да туңа-бозлана. Аны арчырга кирәк. Арчу кыздырылган яки кызган тимер басу белән эшләнә. Шуның аркасында тишек зурайганнан-зурая бара. Бик күп мәктәпләрдә бу тишек йодрык сыярлык хәлгә килгән була.

Татар халкы икмәк, гомумән ашамлык нәрсәләренә хөрмәт белән карый иде. Шуның өчен ашамлык (валчык) кырындыклары[1] теләсә кайда ташланмый иде. Шуннан чыгып, мәктәп балалары да икмәк

[1] Кырындык – күәсне кырып җыйган камырдан пешерелгән икмәк.

валчыкларын тынычрак урынга – тәрәзә төбенә салалар иде. Шуның аркасында тәрәзә төпләре икмәк баткаклыгына әйләнә иде.

Икмәк сыныклары, ашамлык калдыклары бер яктан тишек аркылы тышка чыгып торалар. Икенче яктан өстәлеп баралар иде. Өзлексез агып торган бу азык тирә-күрше хайваннарын үзенә ияләштерә иде. Шунлыктан мәктәп тирәсе хайваннардан, кошкортлардан буш тормый иде. Монда кәҗә дә була, сарык та күренә, казлар-тавыклар да була иде.

Тарих буенча сузылып килгән шушы хәл балалар арасында уен-көлке ясау фикерен тудырды. Укучылар кәҗә, каз һәм тавыклар белән уен алып бара башладылар. Ахырында бу уен гомум мәктәпләргә күчте. Менә бу уеннар күп вакыт шома гына үтсәләр дә, аратирә шактый зур күңелсезлекләр белән дә тәмамлана иде. Мәсәлән:

• Күрше Сафа бабайның кәҗәсе капка ачык калуны сагалап кына тора: җай килү белән, мәктәпкә юнәлә. Тәрәзә төбендәге азыкны ул оныта алмый. Бүген укучылар кәҗә белән уйнарга хәзерләнеп килгәннәр. Укучылар арасыннан берсе элмәкле бау алып килгән. Күзләре Сафа бабай капкасында. Кәҗәне көтеп торучылардән берсе «кәҗә» дип кычкырды. Шул минут тәрәзә тишегеннән элмәкле бау төшерелде һәм кәҗәне элеп тә алдылар. Берсе, урамга чыгып, кәҗә тирәсендә нәрсәдер эшләде. Озак та үтмәде, кәҗә ямьсез тавыш белән кычкыра башлады. Бауны өстерәп, кәҗә өйгә йөгерде. Укучылар сикеренделәр, көлделәр, шатландылар. Мәктәп тынды.

Кәҗәнең ямьсез тавышын ишетеп, Сафа бабай йортка чыкты. Кәҗәнең койрык астын тикшерде һәм аннан нәрсәдер алды. Бу нәрсә кызыл борыч кузасы иде.

Сафа бабай мәктәп ишегеннән кергәндә, гаепле укучылар инде качып беткәннәр иде. Уенга турыдан-туры катнашмаган гөнаһсыз укучылар гына калган иде. Укучылар «без түгел» дип карадылар. Файдасы чыкмады. Сафа бабай укучыларны чыбыркы белән рәхимсез рәвештә ярды. Укучыларны кәҗәдән артыграк кычкыртты. Уйнау-көлү белән башланган эш елау белән тәмамланды.

• Кәшифә әбинең бердәнбер казы яңа гына алтынчы йомыркасын салып чыкты да туп-туры мәктәпкә йөгерде. Аны монда малайлар күптән инде хәзерләнеп, көтеп торалар иде. Тәрәзә тишегеннән ташланган кармаклы икмәкне каз күз ачып, күз йомганчы йотып җибәрде. Укучыларда шатлык туды, шау-шу күтәрелде. Көлүкычкыру башланды. Берсе казны кармак бавы белән югары күтәрде. Тагын түбән төшерде. Шул арада казның авызыннан кан күренде.

Иртә белән Кәшифә әби казны ашатам дип чыкса, каз инде үлгән иде.

Мәктәпнең җәмәгать сәкесендә бер өстәл, ике бүлмәдә берәр өстәл, барлыгы өч өстәл була. Гадәттә, бу өстәлләр бик тәбәнәк (0,5 метр биеклегендә) булалар һәм мулла белән хәлфәләр бу өстәлләрдән сабак биргәндә файдаланалар. Укучыларның куллары тик тормаганга, өстәлләрнең юнылмаган, казылмаган һәм буялмаган урыны бик аз була.

Мәктәпнең җәмәгать сәкесендә зурлы-кечкенәле бик күп санда саныклар (сандык) була. Кунып яшәгән укучыларның әйберләре бу сандыкларда саклана. Гадәттә, бу сандыклар товар (кадак, шырпы, прәннек) ящикларыннан бозып эшләнгән була. Шунлыктан бу сандыклар бик дорфа һәм бик төрле булалар. Сандыкларны бикләгән йозаклар да бик төрле. Йозаклар иң кечкенәдән башлап богау йозакларына кадәр барып җитә.

Ул замандагы укучыларның киемнәре бик билгеле: күлмәк, ыштан, тула оек. Камзул бик сирәк укучыда гына була. Чалбар кию гаеп санала. Чалбар кияргә хәлфә дә җөрьәт итә алмый. Күлмәк, ыштаннарда кесә булмый. Шунлыктан һәр укучының ачкычы ыштан бавында – ычкырында була иде. Сандык ачарга туры килгәндә, укучы сандыгы янына тезләнеп утыра, ачкычны ычкырдан алмыйча гына сандыгын ача иде.

Мәктәптәге бүлмәләрнең төзелеше җәмәгать сәкесе төзелеше белән бертөсле. Биредә дә ике катлы шүрлек, шул ук идән тишеге дә. Бүлмәләрнең идән асты үзләренә аерым итеп, бүленеп алынган була. Аларның берсенә гомуми мичнең бер өлеше туры килә иде. Бүлмәнең берсендә мич булмый, шунлыктан бу һавасы шактый җиләс була.

Җәмәгать сәкесенең стеналарына бернәрсә ябыштырылмаган һәм бернәрсә тагылмаган була. Бүлмәләрнең стенасына чуар кәгазь, иң кимендә газета кәгазе ябыштырыла. Кайбер бүлмәләрнең стенасына шәмаилләр, Мәккә-Мәдинә рәсемнәре, Солтан Әхмәт[1], Әйя-Суфия мәчете[2] рәсемнәре тагыла. Шуның белән бергә, бүлмә стенасына берничә камчы, берничә чыбыркы да эленә.

[1] Солтан Әхмәт мәчете (Зәңгәр мәчет) – Истанбулдагы иң зур мәчетләрнең берсе. 1609–1616 еллар арасында госманлы солтаны Әхмәд I (1590-–1617) тарафыннан төзелгән.

[2] Әйя-Суфия мәчете – Истанбулдагы дөньякүләм мәшһүр архитектура истәлеге.

Мәктәпнең әчелегендә дистәләрчә агач комган җыелып тора. Моның белән кунучы укучылар бит-кул юалар, тәһарәт алалар. Гадәттә, бу комганнарны ата-аналар Аллаһ ризалыгы өчен дип куялар иде.

***Мәктәпнең хуҗалыгы һәм идарәсе***

Бик күп авылларда мәктәп бинасы авыл халкы тарафыннан салына. Бу, әлбәттә, берничә төрле юл белән эшләнә: 1) мәчеттә халыктан акча туплау; 2) көз көннәрендә халыктан ашлык туплау; 3) авыл басуларыннан берәр участокны арендага бирү; 4) авылның берәр хәлле кешесенең ярдәме – иганәчелеге.

Борынгы мәктәпләрнең идарә эшенә хөкүмәт тә, халык үзе дә катнашмады. Идарә эшен тулысы белән мулла алып бара иде. Мулла мәктәпнең тормышы турында да, барышы турында да һичкемгә отчет та бирми, информация дә ясамый. Мулла бу турыдагы отчетның да һәм информациянең дә маликлар өчен кирәге юк дип белә иде.

Лампа чыкканга кадәрле мәктәпләрдә чыра яндырылды. Чыраны һәр көн һәр бала үзе белән алып килә. Кайбер ата-аналар, Аллаһ ризалыгы өчен, чыраны күпләп тә китерәләр. Мәктәпләрдә шәм куллану расходлы булганга, шәм фәкать мулла һәм хәлфә өстәлләрендә генә яндырылды. Чыра мәктәпләрдә 5–6 урында яндырыла иде.

Авылларда лампа куллана башлау белән, мәктәпләрдә чыра яндырулар кимеде. 1880 елларда әле мәктәпләрдә чыра яндырмасалар да, кызлар укый торган мулланың аш өйләрендә чыра яндыру хөкем сөрә иде.

Мәктәпләрне ягу-яктырту берничә юл белән башкарыла. Боларның билгеле рәте түбәндәгеләр иде:

1) Мәктәпнең җылыту һәм яктырту чыгымнары мәчет белән бер суммадан тотыла. Мәктәпкә кирәк булган керосин һәм утынны мөәзин һәр көн кизү торучыларга биреп килә.

2) Мәктәпне җылыту, яктыртуны укучылар үзләре нәүбәт белән алып баралар. Ягу материалы итеп төрле әйбер китерәләр. Кайберләре салам яга, кайберләре утын яга, кайберләре исә тизәк кирпече кулланалар. Мәктәпләрне җылыту өчен, аерым исемлек төзелә. Бу исемлекне төзегәндә, урам һәм күршелек игътибарга алына. Шунлыктан укучылар, исемлекне күрмәсәләр дә, үзләренең көннәрен белеп торалар.

3) Кайбер авылларда мәктәп җылытуны авылның хәлле кешесе үз өстенә ала иде.

***Мәктәпнең эчке тәртип кагыйдәләре***

Борынгы мәктәпләрнең эчке тәртип кагыйдәләре бар урыннарда да һәм бар мәктәпләрдә дә бертөрле иде. Элекке Чиләбе өязе Сары авылы мәктәбендә нинди кагыйдә булса, элекке Сембер өязе Шәйморза авылы мәктәбендә дә шул ук кагыйдә иде.

Мәктәпләрнең эчке тәртип кагыйдәләре катлаусыз дип әйтергә кирәк. Шуның белән бергә, бу кагыйдәләр үзгәрешсез саклана. Әлеге кагыйдәләргә тарих буена үзгәреш кертелми. Алар укучылар һәм ата-аналар күз алдына язма рәвештә тагып та куелмый. Шулай була торып та, аны ата-аналар да һәм укучылар да ачык беләләр һәм шуның белән эш итәләр.

Мәктәпнең төп хуҗасы шул мәхәлләнең мулласы иде. Мулланың мәктәп турында әйткән сүзе һәркем өчен закон, канун. Мулла мәктәпнең өлкән укытучысы да иде. Шуның белән бергә, мәктәптә мулладан башка укытучылар да бар. Бу укытучыларны мәктәп телендә «хәлфә» дип йөртәләр. Мәктәптә ярдәмче хәлфәләр дә булырга мөмкин. Гадәттә, мәктәпнең өлкән хәлфәсе мәктәпнең казыйлык хезмәтен дә үти. Казый мәктәпнең эчке тәртип эшләрен дә күзәтә.

Мәктәптә өлкән хәлфә булу өчен, эшчән һәм белемле булу гына җитми. Бу почетлы эшкә эләгү өчен, муллага файдалылык һәм муллага якынлык шарт. Гадәттә, хәлфәләр мулла тирәсендә әйләнүче кешеләрнең балалары була торган иде.

Кайбер хәлфәләр үзләренең бөтен гомерләрен хәлфәлектә уздыралар: өйләнәләр, бала-чага иясе булалар. Мондый кешеләр хәлфәлекне профессиональ бер кәсеп итеп алалар. Кайбер мәктәпләрдә ак сакаллы карт хәлфәләр дә була. Кулларыннан күп укучы үткәнгә, мондый хәлфәләр авылда халык арасында зур авторитет белән файдаланалар.

Мәктәпләрдә укучылар арасыннан көндәлек дежурлар билгеләнә һәм бу дежурлар мәктәп телендә «кизү» дип атала. Кизүләр тәүлек буе мәктәптә була: мичкә ягалар, мәктәпне чистарталар һәм мәктәпнең барлык көндәлек эшләрен үтиләр. Ял көненә туры килгән укучылар мәктәпнең идәннәрен дә юалар.

***Мәктәпләрдә уку срогы сезоны һәм уку сәгатьләре***

Мәктәпләргә керү өчен, баланың яшенә игътибар ителми. Шуның өчен бер үк сабакны укучылар арасында 7–8 яшьлек балалар

да, 10–12 яшьлек балалар да ала. Мондый өлкәнрәк балаларны «күсәк» дип йөртәләр иде.

Мәктәпкә яңа башлап кергән балаларны хәлфәләр укыта. Бик сайланган кешеләрнең балалары гына турыдан-туры муллада сабак башлый ала. Мондый балалар берәр бай баласы яки авылның сүзчән-тешчән кешесенең баласы була. Хәлфәләрдә укучы балалар гарәпчәгә керер алдыннан гына муллага күчәләр иде.

Борынгы мәктәпләрнең уку срогы еллары белән күрсәтелә алмый. Бу мәктәпләрне хәзерге шикелле 4 еллык яки 7 еллык дип әйтеп булмый. Бер укучы мәктәп программасын 2–3 елда үтә ала. Шуңа карамастан икенче бала программа материалын 4–5 елга сузарга мөмкин иде. Шуның белән бергә, борынгы мәктәпләрдә программа материалларын төгәлләү белән дә исәпләшелми. Бала бер-ике ел мәктәптә була. Атасы: «Я, ярар инде, мулла буласың юк, мәктәпкә йөрмәсәң дә булыр», – ди. Шуның белән бала укудан туктый.

Укучыларның мәктәптә озак торулары ата-аналарның хәленә дә бәйләнгән була. Ата-ана хәлле кеше булса, укучының мәктәп чоры озын була, хәлсез булса, кыска була. Шуның белән бергә, бу хәл йорттагы эш кулының җитәрлек булу-булмавына да бәйле. Шуның өчен дә мәктәпләрдәге хәлфәләр хәлле кеше балалары була.

Мәктәпләрдә уку елының башлануы да һәм укуларның тукталу көннәре дә электән билгеле булмый. Гадәттә, уку елының башлануы да, укуларның тукталуы да авылдагы кыр эшләренең башлану һәм төгәлләнүенә бәйләнә. Шуның өчен көз көннәрендә укучылар мәктәпкә бик акрынлык белән тупланалар һәм яз көннәрендә акрынлык белән мәктәпне ташлыйлар иде. Мәктәпләрнең башлануларына да, тәмамлануларына да һава хәлләре нык тәэсир итә.

• Сәйфи бабайның карт хатын балалары аерылып чыкканнар. Алар үз башларына көн күрәләр. Яшь хатын-кызы шактый зур булса да, аны сукага, тырмага йөртеп булмый – кыз бала. Шуның өчен кыр эшенә чыгуның беренче көнендә Сәйфи бабай Әхмәтшаны мәктәпкә йөрүдән туктатты, тырмага кушты.

• Хисамилар йортында эш кулы күп. Ыжгырып торган өч егет өстенә, сезонлы бер-ике эшче дә яллана. Укучы улы Сәлимнең Хисамига кирәге төшми, ансыз да эш үз вакытында төгәлләнә. Шуның өчен Сәлим мәктәпкә иртә керә һәм соң чыга ала иде.

Кайбер урыннарда, мәктәптә укулар тукталуның соңгы билгесе итеп, мәктәп мичен җимерәләр иде. Моны укучылар «мич сүтү» диләр. Мич сүтү өчен, бер укучы да җавапка тартылмый. Бу гадәт

хөкеменә кергән. «Сездә укулар тукталдымы әле?» дигән сорауга, ата-аналар «мич сүттеләр инде» дип җавап бирәләр. Мишәр авылларында мич сүтү, гомумән, тарихи гадәт булып киткән.

Мәктәпләрдә мич сүтүләр максатсыз эшләнми. Мичләрне кирәгеннән артык кыздыру һәм төрле нәрсә белән бутау аркасында, мәктәп миче эштән чыккан була. Шул килеш калдырылса, киләсе уку елына мәктәп өчен бәла була. Яз көне мич сүтелсә, көз көне яңа мич чыгарыла. Мич сүтүне укучылар шул исәп белән эшлиләр иде, моның төп сәбәбе шунда иде. Ләкин бер гадәт алгач, мич таза булса да сүтелә, начар булса да сүтелә.

Борынгы мәктәпләрдә укучылар ике төрле була: кунып укучылар, йөреп укучылар. Йөреп укучылар сабакны иртә белән генә укыйлар. Кич белән мәктәпкә килү йөрүчеләр өчен ихтыяри була. Мулладан йөреп укучы балалар кич белән дә килергә мәҗбүрләр иде.

Борынгы мәктәпләрнең һәм андагы укучыларның көндәлек эшләрен язып үтсәк, мәктәптәге уку сәгатьләре тулырак күренер.

Гадәттә, борынгы мәктәпләрдә яту-тору да, ашау-эчүләр дә һәм сабак укулар да бер урында, җәмәгать сәкесендә башкарыла. Монда дәрес-сабак өчен аерым урыннар, класс-бүлмәләр юк. Мәктәпнең тәүлекле эше тулаем белән җәмәгать сәкесендә уздырыла.

Кич укулар туктау белән, укучылар ятарга-йокларга әзерләнәләр. Ятак урыннары турыдан-туры идәнгә салына. Идәннең квадратурасы кечкенә булып, кунучы балаларның күп булуы аркасында, укучыларга артык дәрәҗәдә тыгызланып, кысылып ятарга туры килә иде. Урынга яту белән, укучылар: «Әлиф ят», – дип кычкыра башлыйлар. Бу сүз таяк шикелле «туп-туры ятыгыз» дигән сүз була. Монда рәхәтләнеп, аяк сузып, киңәеп, җәелеп ятарга мөмкинлек булмый. Ут сүнү белән, төртешү һәм этешү башлана, кычкырыш-талаш китә. Шуның аркасында көчле һәм усал укучылар җәелеп, сузылып алалар. Көчсез, йомшак укучылар тагын бер кат кысылышалар иде. Укучылар яту белән йокыга китәрлек булмый. Бу вакыт әле караңгылыктан файдаланып, әйбер белән бәрешүләр, аяктан өстерәшләр һәм шуңа охшаган шаянлыклар дәвам итә иде. Урын җитмәү аркасында, кайбер укучылар шүрлекләргә урнашалар. Иртәнгә кадәр мәктәпнең һавасы бозыла, авыр исләр чыга.

Иртән караңгыда мулла, килеп, тәрәзәне шакый. Бу вакыт әле сәгать дүртләр чамасы гына була. Шул тавышка укучылар йокыдан торалар. Мендәр һәм юрганнарны шүрлеккә бәрү башлана. Сасы ис

өстенә тузан аралашып, мәктәп һавасы күз ача алмаслык бер хәлгә керә. Шушы сәгатьтән алып, мәктәпнең көнлек эше башлана. Ул түбәндәге тәртип белән дәвам итә:

Дистәләрчә хисапланган агач комганнар тышка чыгарыла. Алар әйләнәсендә чират башлана. Бик күп бала комганнан файдалана алмый, болар кар белән канәгатьләнә. Күпләрендә сөлге, тастымал да булмый. Болар чабу һәм җиң белән эшне бетерәләр. Шул арада кизү, ишек ачып, һаваны тазартып ала.

Озак та үтми укучылар, идәнгә утырып, төрле тавыш белән сабак хәзерли башлыйлар. Тавыш бер күтәрелә, бер төшә. Бу хәл хәлфәнең камчысы уйный башлауга юл ача. Шул арада кизү муллага урын әзерли. Яхшырак 4–5 мендәрне өстәл янына өеп куя. Мулла шул мендәрләр өстенә утыра.

Сәгать 5 ләр булганда, зур итеп ишек ачыла һәм зур чалмалы мулла мәктәпкә килеп керә. Укучылар, аякка басып, мулланы каршы алалар.

Мулла үз урынына утыру белән, укучылар сабак чиратына тезеләләр. Мулладан сабак алу башлана. Шул ук вакытта хәлфә дә сабак башлап җибәрә.

Берничә укучыга сабак бирү белән, иртә намаз вакыты килеп җитә. Мулла, сабак бирүне туктатып, мәчеткә китә. Балалар өйләренә таралалар. Мәктәп бушап кала.

Иртә намазын тәгәлләп, ашап-эчкәннән соң, мулла тагын мәктәпкә керә. Бу вакыт инде йөреп укучы балалар да тупланган була. Мәктәп идәнендә бармак төртерлек урын булмый. Мулла да, хәлфә дә сабак укыта башлый. Бу вакыт иртә сәгать 8–9 чамасы була.

Чама белән сәгать 10–11 ләр тирәсендә сабак бирү эше төгәлләнә. Мулла чыгып китә. Укучылар тагын өйләренә таралалар. Мәктәп бушап кала.

Кич, караңгы төшү белән, укучылар тагын мәктәпкә җыела башлыйлар. Тагын сабак хәзерләү башлана. Мәктәп тагын бакалы күл төсен ала.

Ястү намазыннан соң мәктәпкә тагын мулла керә. Сабак алып өлгермәгән укучыларга тагын сабак бирү башлана. Бу сабак бирү озынга сузыла алмый. Күп булса, бер сәгать чамасы вакыт ала.

Мулла чыгу белән, укучылар йокыга әзерләнәләр, йөреп укучы балалар таралалар. Шуның белән мәктәпнең көндәлек эше тәмам була.

Югарыда күрсәтелгәннәрдән чыгып, көндәлек эшне расписаниегә салсак, түбәндәге таблица мәйданга килә:

*(чама белән)*

| Эш вакыты | Мулла белән бәйләнгән эш төре | Хәлфәләр белән бәйләнгән эш төре |
|---|---|---|
| с. 4–5 арасы | Йокыдан тору, юыну... | Йокыдан тору, тәртип саклау<br>Сабак бирү, укуларны күзәтү |
| с. 5–6 | Иртәнге 1 нче сабак бирү | Намаз һ. б., ашау-эчү<br>Йөреп укучыларга сабак бирү |
| с. 6–8 | Намаз һәм ашау-эчү | Укуларны күзәтү |
| с. 8–10 | Иртәнге 2 нче сабак бирү | Тәртип саклау |
| с. 20–21 | Кичке сабак бирү | |
| с. 21–22 | Йокыга әзерлек | |

***Борынгы мәктәпләрнең уку программасы***

Борынгы мәктәпләрдә дәрес һәм сабаклар үзенчәлекле программа астында барды. Бик озын тарихка ия булган бу программа үз тарихы буенча һичбер кеше тарафыннан язылмады да, расланмады да. Бу программа елларга, чирекләргә бүленми. Сәгатьләр белән исәпләшми. Бу яктан ул хәзерге программаларга охшамый. Шуңа карамастан бу программа бөтен татар мәктәпләре өчен уртак бер программа булып тора иде.

Дөрес итеп әйткәндә, борынгы мәктәп программасы мәктәпләрдә укыла торган дәресләрнең үтү чорларына нигезләнеп эшләнгән иде. Бу дәреслекләрне үтү чоры кайбер балалар өчен озын вакытка сузылса, икенчеләре өчен кыска да булырга мөмкин. Түбәндә программаның якынча схемасын күрсәтеп үтәбез. Схемада күрсәтелгән дәреслекләрнең кайберләренә анализ һәм аңлатма ясап үтәргә туры килә.

Борынгы мәктәп программасы биш чорга бүлеп күрсәтелә. Ул шулай биш чорга бүленә дә.

***Программаның якынча схемасы***

| Чорлар | Чорлар эчендә укучылар нәрсәләр белән таныштырыла | Чорга карата нинди дәреслекләр кулланыла |
|---|---|---|
| I | Хәреф, хәрефләрнең исемнәре һәм шәкелләре белән таныштыру. Башлангыч иҗек. Күңел сабагы. «Әгузебисмилла». | 1. «Иман шарты»<br>2. «Ясин» |

| | | |
|---|---|---|
| II | Һәфтияк иҗеге. Башлангыч сүрә. Төрки уку. Догалар ятлау. | 1. «Һәфтияк»<br>2. «Бәдәвам» китабы.<br>3. «Кисекбаш» яки «Ахырзаман» китабы.<br>4. «Ярым алма» китабы.<br>5. «Фәзаил әш-шөһүр» китабы. |
| III | Сүрә. Төрки уку. Язу эшләре. Дога һәм сүрәләр ятлау. Намаз тирәсе. | 1. Коръән.<br>2. «Йосыф китабы».<br>3. «Шәрхе Газизә» китабы.<br>4. «Өстүвани» китабы. |
| IV | Сүрәне төгәлләү. Гарәпчә дини китаплар уку. Язу эшләре. | 1. Коръән.<br>2. «Кырык хәдис».<br>3. «Шөрут әс-саләт»[1].<br>4. «Әлбаб яки тәгълим әс-салават». |
| V | Гарәпчә уку. Фарсыча уку. Догалар, сүрәләр ятлау. Мәшкъ-тәҗвид белән Коръән уку. | 1. «Ширгать әл-ислам»[2].<br>2. «Кодури» яки «Мохтәсар».<br>3. «Як хикәят» яки «Хәмде би-хәдд[3]». |

***Уку-укыту тәртипләре һәм методлары***

Борынгы мәктәпләрдә класс бүлмәсе дә, класс системасы да юк иде. Монда индивидуаль уку системасы иде. Шуның белән беррәттән, 3–4 укучы бергә кушылып, бер үк сабакларны бергә укулар була иде. Бер үк сабакларны бергәләшеп укуларга «шәрик булып уку» диләр. Укучыларны «шәрик» дип атыйлар. Шәрик булып уку ирекле-ихтыяри иде. Шәрикләр күбрәк зуррак укучылар арасында була.

Мәктәпләрдә укучылар өчен парта да, өстәлләр дә булмый. Өстәлләр хәлфә һәм муллалар өчен генә саклана. Укучылар җәмәгать сәкесенә, идәнгә, теләгән бер буш урынга утыра алалар. Дәреслекне тезгә куеп яки кулына тотып укыйлар. Сабак кычкырып хәзерләнә, эчтән уку укуга исәпләнми. Дәреслекләрнең күпчелеге көйле булганга, укучы көйләргә бирелеп китә. Ахырында көйсез сабакларны да көйләп укырга мәҗбүр була.

Мәктәптәге йөзләрчә укучыларның көйләп кычкырулары аркасында, колак тонарлык тавыш үзара сөйләргә мөмкинлек бирми иде. Укучылар, әйтәсе сүзләре булганда, колакка авыз куеп әйтәләр.

[1] «Шөрут әс-саләт» – намаз шартларын һәм кагыйдәләрен өйрәтү буенча гарәп телендәге әсәр.

[2] «Ширгать әл-ислам» – дин галиме, хәнәфи мәзһәбе вәкиле Сәет Гализадәнең (вафаты 1524 елда) ислам әхлагына караган китабы. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дәреслек сыйфатында киң кулланылышта йөргән.

[3] «Хәмде би-хәдд» – мәшһүр фарсы шагыйре Фәридетдин Гаттарның «Пәнднамә» исемле шигъри нәсыйхәтләр китабы.

Күп бакасы булган зур күлне искә төшерегез. Борынгы мәктәпләрдә сабак хәзерләү вакыты шаулап торган бакалы күлне искә төшерә.

Гөрләүләр һичбер вакытта да тигез-шома бармый, ул бер күтәрелә, бер төшә. Хәтта вакыты белән тавыш бөтенләй басылып кала. Озак үтми, тавыш-гөрләү тагын күтәрелеп китә. Бала кычкырудан арый, ялчыга, башкаларның тавышыннан туя. Нәтиҗәдә баланы авырлык-ялкаулык баса. Балалар туктарга мәҗбүр була. Шул арада бүлмә ишегеннән хәлфә күренә яки аның камчы уйнаганын балалар сизә. Укучы яңадан кычкырырга мәҗбүр була. Мәктәп яңадан гөрләргә башлый, яңадан тавыш күтәрелә.

Менә шулай мәктәп шаулап, гөрләп торган бер вакытта ишектән мулла күренә. Бердән тавыш туктала. Барлык укучылар, аякка басып, мулланы каршы алалар.

Мулланың кереше укучыларның утырышында үзгәреш ясый. Электән тәртипсез утырган укучылар бер-бер артлы булып тезелеп утыралар. Бу инде сабак алыр өчен ясалган чират тезмәсе була. Боргаланып-боргаланып киткән бу озын ике тезмәнең берсе мулла өстәленә, икенчесе хәлфә ишегенә терәлгән була.

Шушы минутта мулла да, хәлфә дә сабак башлый. Иске сабакны тыңлата, яңа сабакны бирә. Укучы яхшы хәзерләнгән булса, сабак алу озакка тартылмый, 3–4 минутта эше бетә. Начар хәзерләнгән булса, кире кайтарыла, яңадан укып килергә кушыла. Бик начар укыган булса яки бөтенләй хәзерләмәгән булса, кире кайтарыла, яңадан укып килергә кушыла. Бик начар укыган булса яки бөтенләй хәзерләмәгән булса, җәзага эләгә. Борынгы татар мәктәпләрендә җәза бер генә төрле – кыйнау-суктыру иде. Гадәттә, мулла кыйнауны кул белән үти. Хәлфәләр камчы белән үтиләр. Бик сирәк муллалар гына камчы кулланалар.

Муллалар һәм хәлфәдән сабак алу башлану белән, сабак хәзерләү туктатылмый. Гөрләү, тавыш элеккедән дә көчәя. Чөнки хәзер мулланың күзе дә укучылар өстендә була. Хәлфә дә әледән-әле ишектән камчы күрсәтә.

### *Мөкяфәт[1] һәм җәза*

Борынгы мәктәпләрдә укучыларга мөкяфәт бирү булганы юк. Ләкин җәза бирү көчле иде. Җәза бер генә төрле – кыйнау-суктыру иде. Тантаналы кыйнаулар камчы һәм чыбык белән үтәлә иде. Мәктәп камчысы кыска саплы итеп, каештан ясалган була. Нык төшсен

[1] Мөкяфәт – бүләк.

өчен, каешның очы утта көйдерелә. Шуның белән бергә, кайбер очракларда кыйнау камчының сабы белән дә үтәлә иде. Идән астына ябу, ашсыз калдыру шикелле җәзалар бирелсә дә, болар сирәк мәктәпләрдә генә күрелә.

Борынгы мәктәпләрдә укучыларны кыйнау законлы санала. Бу хәлне ата-аналар үзләре дә шулай дип таныйлар иде. Каты һәм күп кыйнаучы хәлфәләр макталып сөйләнә, тырыш һәм кайгыртучан дип исәпләнелә.

Ата-ана, мәктәпкә баласын биргәндә, каты куллы хәлфәне сайлый һәм әйтеп бирә: «Үзеңә тапшырдым, әүвәл – Ходა, икенче – син. Тиресе белән сөяге – минеке, ите – синеке», – ди торганнар иде. Халык арасында «хәлфә суккан урын утта, тәмугта янмас» дигән сүз халык арасында нык тамыр җәйгән иде. Моны укучылар үзләре дә шулай аңлыйлар иде. Кыйнаган өчен, укучылар хәлфәгә һичбер вакыт кинә тотмыйлар, мулла һәм хәлфәгә хөрмәтләрен киметмиләр, укып, дөньяга чыккач та, хәлфәгә зур хөрмәт саклыйлар.

Борынгы мәктәпләрдә шимбә, якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәр гади сабак көннәре булып санала иде. Чәршәмбенең үзенчәлеге бар. Чәршәмбе – атна буенча үтелгән сабакларны тыңлату һәм күңел сабагы ятлауны тикшерү көне. Шуның өчен чәршәмбе көнендә сугылмаган, кыйналмаган укучы сирәк була иде.

Пәнҗешәмбе көн – сәдака көне. Бу көн укучылар муллага да, хәлфәгә дә сәдака бирәләр. Икенче төрле әйткәндә, уку хакы түлиләр иде. Пәнҗешәмбе көн тулы уку булмый, иртәдән уку бетү белән, укучылар өйләренә таралалар.

Рамазанда гадәттәге сабаклар туктатыла, күңел сабагы, мәшкъка[1] киң урын бирелә иде. Шул уңай белән мулла да, хәлфә дә расписаниесен үзгәртә. Рамазанда җәза бирү шактый кими иде.

### *Укытучыларның хезмәт хаклары*

Борынгы мәктәпләрдә муллага да, хәлфәгә дә ай хисабыннан хезмәт хакы түләнми иде. Хезмәт хакы алып сабак укыту мактаулы эш булып саналмый. Хезмәт хакы урынына кече атна сәдакасы тотыла. Пәнҗешәмбе көн укучылар муллага да, хәлфәгә дә сәдака китерәләр. Сәдаканың үлчәве ата-ананың материаль хәленә һәм сабакларның югары яки түбәнлегенә карап була. Уртача алганда, бер тиеннән башлап 10 тиенгә кадәр. 15–20 тиен сәдаканы бик сирәк мәктәпләрдә генә күрергә туры килә.

[1] Мәшкъка – матур язу үрнәге.

Гадәттә, укучы сәдаканы, иске сабакны тыңлатып, яңа сабак алганнан соң – эш беткәч бирә иде. Сәдака җыелып беткәнгә кадәр өстәлдә саклана. Мулла да, хәлфә дә һәрбер сәдакага кул күтәреп дога кыла, ишеттереп «рәхмәт» ди торган иде.

Хәлфәләр, сәдакадан тыш, түбәндәгеләрдән файдаланалар:

• Мулла-мөәзиннәр белән беррәттән аш мәҗлесләренә чакырылалар. Монда да аларга сәдака бирелә.

• Кайбер ата-аналар хәлфәнең үзен генә чакырып сорыйлар. Укучы балалары турында сүз кузгаталар. Монда да хәлфә сәдакасыз калдырылмый.

• Өйләрдә пешкән тансык-тәмле ашларны хәлфәгә дә китергәлиләр.

• Байлар хәлфәгә зәкят һәм гошер бирәләр.

• Хәлфә чит авылдан булса, мунчага чакыралар, өс-башларын, кием-салымнарын юалар.

• Үлекләр рухына Коръән укыталар.

• Хәлфә халыкның яхшы карашын казанса, аңа кыз бирергә теләүчеләр күп була.

• Хәлфәләр мәчеткә йөриләр, намаздан калмыйлар. Мәчеттә аларның урыны мулла тирәсендә була. Гаетләрдә, бәйрәмнәрдә муллага сәдака бирүче аталар хәлфәне дә коры калдырмыйлар.

***Иҗек, аваз һәм хәрефләр белән таныштыру***

Борынгы мәктәпләрдә укучыларны авазлар белән таныштыру юк иде. Хәлфә үзе дә, укучылар да авазларның нәрсә икәнен белмиләр иде. Монда балага хәрефләрнең шәкелләре күрсәтелә, исемнәр өйрәтелә. Менә бу, таяк шикеллесе, «әлиф» була, менә бусы – чана табанына охшаганы «би» була дип аңлаталар.

А – آ – таякка охшаганы әлиф була.

Б – ب – чана табанына охшаганы би була.

М – م – чукмарлы таякка охшаган мим була.

Н – ن – дугага охшаганы нүн була.

К – ك – кәкре-бөкре кәф була.

Шуның белән бергә, укучыга гарәп язуында кулланыла торган хәрефләр генә күрсәтелә. Татар теленә карашлы хәрефләрдән (پ ج ۋ ڭ گ) хәрефләре күрсәтелми иде. Укучы бу хәрефләр белән үзлегеннән очраклы рәвештә генә таныша.

Гарәп телендә 34 аваз булып, шулардан: тартык авазлар саны – 28, сузык авазлар саны – 6.

Сузыклар ике төрле: тулы сузык – آ و ی

Кыска сузык – (хәрәкә) – َ өс, ِ ас, ٌ өтер.

Гарәп телендә тулы аваз билгесе булып хәрефләр кулланылса да, кыска аваз билгесе итеп ас, өс, өтер дип атала торган билгеләр генә кулланыла. Гарәп телендә бу билгеләр «хәрәкә» дип йөртелә. Тулы һәм кыска сузыкларның куллану урыннары түбәндәгечә була.

Тулы сузык белән

1. а – مال – ا мал, ә (хәрәкә) مَل – мәл.

2. у – مول – و мул, е (хәрәкә) مُل – мел.

3. и – ميل – يِ мил, и (хәрәкә) مِل – мил.

Борынгы мәктәпләрдә элек авазлар белән таныштыру, таныш авазлардан сүзләр төзетү ысулы юк иде. Монда турыдан-туры хәреф күрсәтелә һәм укырга керешелә. Хәрефләр һәм сүзләр ятлатыла. Укучыларга хәреф таныту һәм уку өйрәтү түбәндәгечә иҗек юлы белән алып барыла.

**Беренче сабак.** Башлап мәктәпкә килгән балага беренче көндә дүрт хәреф күрсәтелә. Шул дүрт хәрефне ятларга кушыла. Дүрт хәрефне ятлау өчен, аны берәзлексез әйтергә, укырга кирәк була.

آ – әлиф, ب – би, ت – ти, ث – си (сакау «с»).

**Икенче сабак**. Икенче сабакта, беренче сабакка өстәп, тагын өч хәреф бирелә. Шуның белән икенче сабак түбәндәгечә була:

ث ت ب آ + җим ج, хый خ.

Шушы рәвешчә, иске сабакларга яңа хәрефләр өстәлә тора.

**Өченче сабак.** ا ب ت ث خ ج ح د ذ ر ز

**Дүртенче сабак.** ض ب ت ث ج ح خ د ذ ر ز س ش ص

**Бишенче сабак.** غ ع ط ظ ض ب ت ث ج ح خ د ذ ر ز س ش ص

**Алтынчы сабак.** ف ق ک ل غ ع ط ظ ض ب ت ث ج ح خ د ذ ر ز س ش ص

**Җиденче сабак.** ی ه و ن م ف ق ل ک غ ع ط ظ ض ب ت ث ج ح خ د ذ ر ز س ش ص

Моннан соңгы сабаклар барлык хәрефләрне кабатлаудан тора. Бу кабатлау 15–20 көнгә сузылырга мөмкин. Шуның белән бергә, 1–7 нче сабаклар да бер көндә төгәлләнә алмый, бер сабак 3–4 көнгә тартыла. Нәтиҗәдә балага хәреф таныту 30–40 көнгә сузыла.

Беренче сабак башланганда, балада зур кызыксыну була. Ләкин алга барган саен, баланың хәле авырлаша бара, 4–5 нче сабакларда инде баланың башы тубалга әйләнә, сабактан да, мәктәптән дә бизү дәрәҗәсенә килә.

Моннан соң хәреф танытуның икенче этабы башлана. Бу сабаклар баланы хәрәкә – өс, ас, өтер белән таныштырудан тора. Бу сабак

аерым хәрефләр өстендә хәрефләрнең әйтелеше турында бара. Ялгыз хәрәкәле хәрефләрне танытуга атна-ун көн вакыт бирелә.

Бала хәрәкәле хәрефләр белән танышкач, аңарга «тәнвин» дип атала торган куш хәрәкә ике өс ً , ике ас ٍ, ике өтер ٌ күрсәтелә. Иң ахырда сүзне өзеп, кистереп әйтү билгесе булган сәкен ْ күрсәтелә. Шуның белән балага хәреф таныту тәмам була. Менә бу соңгы дәрес өчен биш-ун көн вакыт бирелә.

Бала, хәрефләрне үзләгәннән соң, иҗек башларга тиеш була. Ләкин күп мәктәпләрдә иҗек башланганга кадәр «Әбҗәд» сүзләре күрсәтәләр. Бала әбҗәдне аңлы рәвештә үзләми, фәкать механик рәвештә ятлый. Бала үзе дә, хәлфә дә әбҗәднең мәгънәсен белми.

**Иҗек.** Борынгы мәктәп хәлфәләре иҗекне русча «слог» мәгънәсендә алмыйлар. Иҗек, хәлфәләрчә, сүзләрне хәрефләргә таркату юлы белән уку булып санала. Иҗек өчен уку материалы итеп, башлап, түбәндәге гарәпчә җөмлә алына:

أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ

Бу гарәпчә җөмләгә «Кәлимә тайибә» диләр. Яше җиткән бала, шул сүзне әйтү белән, мөселман була. Шуны әйтүдән тартынган кеше кяфер-динсез санала. Яңа орфография белән язганда, шулай укыла: Кәлимәтен тайибәтен - Әшһаде эн лә иляһә иллә-лляһә вә әшһәде әннә Мөхәммәдән габдеһү вә рәсүлеһү.

Мәсьәлә ачык булсын өчен, «кәлимәтен» сүзен иҗекләп күрсәтик: 1) «кәф»нең өсте – «кә», «ләм»нең асты – «ли» = «кәли», «мим»нең өсте – «мә» = «кәлимә», «ти»нең ике өтере «тен» = «кәлимәтен» була. 2) Тайибәтен иҗеге: «тый»ның өсте – «та», «йай»ның тәшдид асты – «айи» = «тайи», «би»нең өсте – «бә» = «тайибә», «ти»нең ике өтере «тайибәтен» була. Асылда, иҗек югарыда күрсәтелгәнгә, ачык һәм балага аңлаешлы итеп төшендерелергә тиеш булса да, хәлфәләр алай эшләмиләр. Иҗек сүзләрен хәлфәләр бала алдында механик рәвештә такмаклыйлар гына. Нәтиҗәдә балага такмаза өйрәтүдән гыйбарәт булып кала. Бу такмаза түбәндәгечә була: 1) Кәпсенкә ләм асылли, кәли мим сен мә, кәлимә тиктер төн, – «Кәлимәтен». 2) Тыйсын тайя тәшдид асын и тайибисенбә, тйибәтик тертен – «Тайибәтен».

Югарыда күрсәтелгән ике сүзнең иҗеге бер көндә тәмамлана дип уйланмасын. Укучы бу сүзләр өстендә атна буенча утыра. Шунда да әле ул механик рәвештә ятларга гына өйрәнә, эшнең кая барганын төшенә алмый.

Укучы бик күп көчләр куйгач, бик күп яшьләр түккәч, бик күп вакытлар үтеп киткәч кенә, эшнең кая барганын сизенә башлый. Иҗек такмазасын нәрсә әйткәнен төшенә торган хәлгә килә. Димәк, балада үзлегеннән туган шушы хәл иҗекли ала торган хәлгә килә. Шуның белән бергә, бала кайбер кыска, җиңел сүзләрне иҗекләми дә укый ала торган була. Балада булган шушы күренеш аның сүрәгә керергә, сүрә башларга яраклы икәнен күрсәтә.

«Иман шарты» һәм «Ясин» сүзләрен иҗекләү нәтиҗәсендә туган иҗек сәләте һәм кайбер җиңел сүзләрне сүрәләү сәләте балага «Һәфтияк»кә күчәргә хак бирә.

«Ясин»ны иҗекләп бетергәннән соң, бала «Һәфтияк»кә төшә. Ләкин ул әле монда да иҗектән котыла алмый – иҗек дәвам итә. Ләкин бу вакыт бала буйдан-буйга иҗекләми, авыр сүзләр туры килгәндә генә иҗектән файдалана. Берәр сүзне турыдан-туры әйтә алмаса, иҗекләп карый, иҗек белән турылап җибәрә.

«Һәфтияк»не тәмам иткән укучы сүрәгә ныклы төшенгән була. Шунлыктан ул хәзер Коръәнгә төшә. Коръән укыганда, ул иҗеккә мохтаҗ булмый. Хәтта күп укучыларга хәлфә яки мулла үзе укып та күрсәтми, «шуннан шунда кадәр укырсың» дип, күрсәтеп кенә үтә.

Борынгы мәктәпләрдә (белемне ныгыту теләге белән) бер дәреслекне баштан ахыргача 2–3 мәртәбә укыту гадәте дә бар. «Иман шарты», «Ясин» һәм «Һәфтияк» кайбер укучыларга 2–3 кабат укытыла.

***Борынгы мәктәпләрдә ана теле***

Борынгы мәктәпләрдә ана теле, татар теле дигән нәрсә юк иде. Монда ана теле урынына «төрки теле» дигән сүз кулланыла. Бала төркигә төште, төрки таный, диләр иде. Төрки дәреслекләре яки чыгтай телендә яки чыгтайча тартым авыр бер телдә була.

Борынгы мәктәпләрдә бала татар, башкорт, казакъ булуына карамастан, элек гарәпчә укырга өйрәтелә. Төрки уку икенче дәрәҗәдә генә тора. Бала гарәпчә сүз һәм җөмләләрне укырлык хәлгә килгәч кенә, аңарга төрки дәреслеге бирәләр. Төрки теле авазлардан, сүзләрдән башланмый, бәлки турыдан-туры шигырьләр, хикәяләр укудан башлана.

Барлык татар мәктәпләрендә дә беренче төрки уку дәреслеге булып «Бәдәвам-бидәвам» бирелә. «Бәдәвам» үзенә бертөрле көй белән көйләп укыла һәм бу көйне һәр бала белә. Хәлфәләр көй өйрәтү эшенә керешмиләр. Борынгы мәктәпләрдә ятлауны үзләү дип аңлаганга, һәр укылган дәреслек ятлана. Шул яктан чыгып,

«Бәдәвам китабы» да ятлана. Ятлау бер әйберне кабат-кабат уку юлы белән эшләнә.

Мәктәпләрдә кулланыла торган төрки дәреслекләр гарәп алфавиты, гарәп орфографиясе белән язылган була. Татар яки төрки сүзләрнең үзенчәлеге бик аз чагылдырыла. Мәсәлән: بلكز الله برلكن احمد پيعمبرلكن اسلام دينى حقلغن الله دكل بدوام җөмләсе хәзерге орфография белән: «Белегез Аллаһ берлеген, Әхмәд пәйгамбәрлеген, ислам дине хаклыгын, Аллаһ дигел бәдәвам» дип языласы урында «Блгз Аллһ брлгн, Ислам дини хклгн Әхмд пигамбрлгн» рәвешендә сузыкларны ташлап языла иде. Шуның белән бергә, сүзләрне язуда кагыйдә һәм режим да юк иде. Шунлыктан бер үк сүз төрле китапта төрлечә языла. Мәсәлән, «татар» сүзе طاتار – تاتار – تتر – ططر – تاطار – طاطار шәкелләрендә языла.

Борынгы дәреслекнең орфография һәм тел ягын күрсәтер өчен, «Газизә» китабыннан бер өземтә күрсәтелә. Мәсәлән, «Ул китапны төрки теленчә аның өчен әйләдем, үзем кеби хаста күңеллеләр укып, шадлык әйләсенләр» дигән җөмләләр түбәндәгечә языла: اول كتابنى تركى تلنچه آننك اچون ايلدم اوزم كبى حسته كونكلى لر شادلق ايلسونلر

Борынгы мәктәпләрдә язуларда тыныш тамгаларына игътибар ителми иде. Шунлыктан басмаларда да һәм кулъязмаларда да тыныш тамгалары булмады. Кайбер очракларда Коръәндә, шигырь һәм нәзымнарда нокта урынына үзенә бертөрле фигуралар кулланыла.

Бала «Бәдәвам» брошюрасы укып ятлап чыкканнан соң, аңа «Фәзаилеш-шөһүр» китабы бирелә. Моннан соң «Йосыф китабы»на төшерелә, «Сөбател-гаҗизин» һәм «Шәрхе Газизә» китаплары укытыла.

«Бәдәвам» брошюрасын укып чыгу белән, укучыда уңай якка үзгәреш канәгатьләнерлек булмаса, «Фәзаил әш-шөһүр»гә кадәр балага өстәмә буларак «Ярым алма», «Кисекбаш» һәм «Ахыр заман» китабы укыталар. Моннан соң гына «Фәзаил әш-шөһүр» башлыйлар. Кайбер мәктәпләрдә «Фәзаил әш-шөһүр» белән «Йосыф китабы» бер вакытта укытыла. Димәк, укучының кулына бердән ике уку китабы бирелә.

***Борынгы мәктәпләрдә язу өйрәтү***

Борынгы мәктәпләрдә язу өйрәнү, язу өйрәтү мәҗбүри түгел, ихтыяри иде. Бала яки баланың ата-анасы язу өйрәнүне кирәк дип тапсалар, хәлфә балага язу өйрәтә, мондый теләк булмаса, язу өйрәтү белән баш ватмый. Шуның нәтиҗәсендә мәктәп бетереп чыккан балаларның 60–70% ы укый белә, ләкин яза белми торган иде.

Язу өйрәнергә теләгән бала хәлфәдән дәфтәренә берничә сүз яки берничә җөмлә яздырып ала. Хәлфәнең балага язып биргән бу язуына «күчергеч» диләр. Бала язу эшенә яңа керешкәндә, күчергеч бер-ике сүздән генә торучан була. Тора-бара катлаулана, ахырында бөтен бер эш кәгазенә әйләнә.

Бала бирелгән күчергечнең һәрберсен бик күп тапкырлар күчерә һәм яңадан-яңа күчергечләр ала. Шулай итә торгач, берничә вакыттан соң бала күчергечсез, үзлегеннән язу язарлык хәлгә килә.

Әле XIX йөзнең соңгы еллары булуга карамастан, 1890–1895 елларда мәктәпләрдә дәфтәрләр (ученическая тетрадь) куллану гадәте юк иде. Бала табаклы кәгазьне бөкләп, дәфтәрне үзе ясый. Мәктәпләрдәге кайбер балалар кәгазь урынына махсус ясалган такта кулланалар. Мондый такталар язу өйрәнү өчен генә түгел (китапны күп туздырган балаларга), сабак язып бирер өчен дә файдаланыла.

Хәлфәнең балага беренче биргән күчергече баланың исем һәм фамилиясеннән гыйбарәт була.

Исем-фамилиядән башланып киткән бу язу темасы көннән-көн катлаулана, көннән-көн баланың көнкүрешенә, тормыш шартларына якыная бара.

Кайбер хәлфәләр язу өйрәтүне аерым хәрефләр яздырудан башлыйлар һәм «Әбҗәд» күчертәләр иде. Шул күнегүләр аркасында кул, бармак язу сәләтен алгач кына, исем-фамилиягә күчәләр.

Укучы әбҗәд сүзләрен һәм исем-фамилия яза алырлык хәлгә килгәч, тормышта очравы мөмкин булган эш кәгазьләрен язарга өйрәнә. Бу да күчереп язу юлы белән башкарыла. Күчергечләрдә чынбарлык белән исәпләшелми, фәкать язуның матурлыгына гына игътибар ителә. Шуның аркасында күчергечләр түбәндә күрсәтелгәнчә килеп чыга:

*1. Әүвәл алдым ун баш төлке тиресе, хакы булды сигез сумнан ике йөз сум көмеш вә янә алдым йөз баш сыгыр тиресе, хакы булды өч сумнан, суммасы булды сиксән сум.*

*2. Мин Әхмәдҗан Мөхәммәдҗан углы Галиханов үземнең хәләл милкем булган җирән айгырымны шул ук авылның Сөләйман Солтан углына егерме биш сум тәкабеленә саттым. Аллаһ ахырын хәерле кылсын. Мин Гали Хәбибулла углы гуаһ[1] булып кул куйдым.*

[1] Гуаһ – шаһит.

*3. Бу китапны сатып алдым Покрау ярминкәсеннән егерме биш сумга, Аллаһы гыйльме нафигъ[1] бирсен. Бу китапның иясе Шәрифҗан Садретдин углы торыр. 1335 елда август аенда.*

*4. Әүвәл алдым ун баш куян тиресе, бәһасе егерме сум, янә алдым биш баш куй тиресе, бәһасе булды ун сум, янә алдым кырык баш кама тиресе, бәһасе булды илле сум, янә алдым бүреклек, бәһасе егерме биш сум, янә алдым утыз баш сарык тиресе, бәһасе булды биш сум.*

*5. Әүвәл алдым бер баш бүре тиресе, бәһасе булды ике сум, янә алдым ике баш аю тиресе, бәһасе булды өч сум, янә алдым дүрт баш...*

Югарыда күрсәтелгән язулар күчертелгәннән соң, укучыга хат язу юллары күрсәтелә. Хат язу юллары да күчергеч аркылы эшләнә. Укучыга берничә төрле хат формасы күрсәтелгәч, язу эше тәмам булган санала. Гадәттә, мулла язу эше белән шөгыльләнми. Язу эше хәлфәдә уку дәверендә тәмам була. Түбәндә бер күчергече күрсәтелә:

*Хат башы – яз каршы.*

*Сез ки гыйzzәткә лаек вә хөрмәт муафикъ улып торгучы, Кәгъбәи-Шәриф тик күргүче әнкәем белән әткәемә без ки падиша хезмәтенә грифтар[2] булып торгучы углыгыз Гарифулладан бик саргаеп, бик сагынып, бер күрергә интизар[3] булып, күпдин-күп сәламнәр соңында хәер-догаларыгызны үтенеп калдым вә кинә тумачы[4] апага без ки Гарифулладан бик сагынып, бик саргаеп, күпдин күп сәламнәр укып, догаи-фатихаларын үтенеп калдым. Вә кинә тирә-күршеләргә бик сагынып, бик саргаеп, күпдин күп сәламнәр укып калдым вә кинә мәсҗед картларына бик сагынып, бик саргаеп, догаи булып, падишага хезмәт кылмакдамыз. Моннан соң әмер Ходадыр. Сүземез күп иде, мохтәсар[5] кылдык вәс-сәлләм.*

Борынгы мәктәпләрдә язу өйрәтү булса да, язуның матурлыгына һәм кулларның бертөсле булуына игътибар бирелми. Шунлыктан укучыларның язулары бер-беренә охшамый һәм бик ямьсез була иде. Укучыларның язу өйрәнүләре хәлфәләрдән башлана һәм хәлфәләрдә тәмам була дигән идек. Бик сирәк урыннарда муллалар да язу өйрәтүгә катнашалар. Ләкин бу эш бик сирәк була.

Язу эшенә һәвәсле кайбер укучылар хәлфәләр тарафыннан бирелгән күчергечләргә генә канәгатьләнмиләр, алар китаплар

[1] Гыйльме нафигъ – файдалы гыйлем.
[2] Грифтар – дучар.
[3] Интизар – зарыгу.
[4] Тумачы апа – туганнан туган, өлкән кыз кардәш.
[5] Мохтәсар – кыска.

күчерәләр, үзлекләреннән чыгарып язалар иде. Менә шундый күнегүләр нәтиҗәсендә мондый укучыларның язулары шактый матур була. Мондый матур язулы укучылар мәктәп эчендә дә, халык арасында да дан казаналар. Хат яздырасы кешеләр болардан шактый файдаланалар. Кызлар хатын нәкъ менә шундый укучылар башкара.

***Борынгы мәктәпләрдә хезмәт һәм сәнгать***

Борынгы мәктәпләрдә үзенә бер төрле сәнгать эшләре дә бар иде. Ләкин мәктәпләрдә бу эш белән беркем дә җитәкчелек итми. Бу эшне укучылар үзара өйрәнәләр. Кыскасы, һөнәр укучыдан укучыга күчеп йөри иде. Борынгы мәктәпләрдәге сәнгать эшләренә мисал итеп, түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

**Рәсем эшләре.** Ислам дине буенча, җанлы әйбер рәсеме ясау харам һәм гөнаһ эш санала. Ясалган рәсем теге дөньяда ахирәттә җан сорый, диләр. Өйдә җанлы әйбер рәсеме булса, ул өйгә фәрештә керми, өйдән фәрештә кача, диләр. Шуңа күрә борынгы мәктәпләрдә кеше, хайван һәм кошлар рәсеме ясаудан тыялар иде. Гадәттә, укучылар өй, мәчет, бакча, гөл һәм төрле узорлар-бизәкләр ясауны яраталар.

Шуңа карамастан ат, кеше һәм кош рәсемнәре дә ясаучылар булгалый иде. Ләкин мондый рәсемнәр мулла, хәлфә һәм ата-аналардан яшерелә, аларга күрсәтелми.

Рәсем ясаучы укучылар рәсемнәрнең төп сызыкларын кара карандаш белән сызалар, кирәкле урыннарын төрле төскә буйыйлар иде. Буяу итеп төсле карандаш яки төрле төстәге кара кулланалар. Бер очы кызыл, икенче очы зәңгәр карандаш рәсем эшендә киң кулланыла.

Укучылар сызгыч һәм җәзбә[1] ярдәме белән төрле геометрик формалар ясауны да яраталар һәм боларны да төрле төс белән бизәкләмиләр иде.

Укучылар арасында иң сөеп ясалган рәсем – өй һәм мәчет рәсемнәре. Бу хәлнең, әлбәттә, сәбәбе бар иде. Гадәттә, балалар ясаган әйберләренең эшкә ашуы белән кызыксыналар. Мәчет ясаудан тыючы юк, ясалган мәчет рәсемнәрен өйнең югарысына, иң күренекле урынга тагып куярга да мөмкин. Менә бу яктан караганда мәчет рәсеме ясау мактаулы бер эш булып тора. Шушы чорда авылларда, өйләрдә мондый рәсемнәрне күп күрергә мөмкин.

Гадәттә, мәчет рәсемнәре фәкать яннан күренешле профиль итеп кенә эшләнә. Шуның белән бергә, мәчет һәм өйнең эчендә булган

[1] Җәзбә – циркуль.

өстәл, шкаф, мич һәм мөнбәр шикелле әйберләрне күрсәтеп ясыйлар. Ясалган әйберләр төрле төскә буяла, ләкин төснең турылыгына, аның туры килешенә бертөрле дә игътибар ителми.

**Уку һәм эш кораллары ясау.** Туры сызыкларны сызар өчен, сызгыч кирәк. Түгәрәкләр сызар өчен, җәзбә-циркуль кирәк. Бу коралларны авыл кибетләрендә табып булмый. Укучыларның шәһәр белән элемтәләре юк. Шунлыктан укучылар мондый коралларны үз кул көчләре белән эшлиләр.

**Пенал һәм төрле тартмалар ясау.** Укучылар арасында, ташландык кәгазьләрдән ябыштырып, папье-маше юлы белән пенал һәм шуңа ошаган әйберләр ясаучылар да була иде. Ташландык кәгазьләрдән, катыргы-картоннан ясыйлар. Тартма һәм пеналларны чәй һәм конфет кәгазьләре белән матурлыйлар.

**Кәгазь эшләре.** Борынгы мәктәпләрдә бик нык таралган кул эшләреннән берсе – кәгазь эшләре. Кәгазьне кисү, тишү һәм бөкләү юлы белән эшләнә торган бу эш түбәндәгеләрдән тора:

а) сабак урыннарын билгеләү өчен кәгазь тоткычлар;

ә) гармун, сәгать, өрдергеч, карга һәм шуңа охшаган күләмле әйберләр;

б) бөкләп яки ябыштырып эшләнгән конвертлар.

**Кызлар хаты һәм шәҗәрәләр язу.** Тар, озын кәгазьгә язылган әйберләрне укучылар «шәҗәрә» дип йөртәләр. Мондый кәгазьләргә нәсел-буын килешләрен, Нәүруз, Әлвидаг, Мәүлид һәм төрле бәетләр, нәзымнар язалар. Борынгы мәктәпләрдә нәфис сәнгать белән бәйләнгән ике төрле язу бар иде: 1) кызлар хаты язу, 2) шәҗәрәләр язу. Бу эшләрне башкару һәрбер укучының кулыннан килми иде. Моның өчен матур яза белү, матур бизәкли белү кирәк. Гадәттә, кызлар хаты язу яшерен эшләнә, кешегә күрсәтелми. Хатлар авыл егетләренә, авыл кызларына акчага сатыла.

Кызлар хатының эчтәлеге стандарт була. Шуның белән бергә, бу хатларда ике якның да исемнәре аталмый. Кызлар хатының эчтәлеге белән таныштырыр өчен, түбәндә бер хатны урнаштырабыз.

*«Әл хат нисъфел мөлякәт,*
*Сән сылукаема сәлам хат.*

*Әссәламүгаләйкем вәл-икрам. Сез ки гакыллы җиһан вә сәрвәри заман вә тәхсин әл-Кәлям, дин тоткасы, гыйбадәт иясе. Күзем нуры, җәннәт хуры былбыл, тутый. Сәрвәр буйлы, дилбәран*[1] *вә мөшфикаи*

[1] Дилбәран – сөекле.

*дү җиһанем, кара кашым, куй күзем, күкдә йолдызым, җирдә ялгызым, төндә көндезем. Гыйшык идеп, күңелемне алган, бәни гыйшык утына салган. Әгәр сәни бер күрсәм, хаста башым сау була. Әгәр сәни күрмәсәм, сау башым хаста була. Сән йөрисән күңелеңдән Аллаһны хисаплап, мән йөримән көн бикөн сәни хисаплап. Сәни күрмәсәм, хәддин ашып, йөрәгем бәгъринә ут доташа. И җанымның җаны, вай бәгърем пәрәсе, ике күзем карасы. Синең агызындин гәүһәр сачелгәнне күрсәм, гамькин күңелем ачыла, янган йөрәгем ял таба. И җаным, һич сабрым калмады. Тәкатем беткәнгә күрә, әдәпсезлек кыйлып хат яздым. Вә янә мәхфи улмаясезләр*[1]*. Иблис галәйһел-ләгънә үзен зур күреп, адәм галәйһис-сәламга сәҗдә кыйлмады. Сән дә шуның кебек, үзеңне зур күреп, бәни хур күрмәясән. И сылукаем, бу сүземне тотма ялган. Бу гыйшык пәйгамбәрләрдин калган. Үзе сәүгәнен үзе алган. Бил-хәйри, вәссәлам вәл-бакый гыйндәт тәлакый.*

Янә:

*Әссәламүгаләйкем вә галә мән ләдәйкем.*

*И фәсахәт*[2] *былбылы, бәлягать*[3] *сөнбеле, кямиләт энҗесе. Энҗе дешлү, зифа буйлу. Камыш бармаклы, көмеш тырнаклы мәхбүб*[4] *вә мәргуб*[5] *хур кызына бу җиһанда тиңдәш юк. Һай җаныем, нә сәбәпдин гакылымны алдың, гыйшык утына салдың. Әмма бәнем халем сәндә улса, һичбер сәгать түзә алмас идең. Әмма бәнем халем ушбу хат үзрә мәгълүмдер. Бу хатны кабул итмәй җибәрмәясән. Кабул итсәң, бәңа дөнья нәрсәләрдин берәр нәрсә бүләк идәрсәң. Ничек булса да, гаеп итмәгәйсезләр. Һичкемгә фаш итмәгәйсезләр. Шәргы боерган эшләр оят булмаса кирәк. Зарымны кабул ит, үз хәлеңне мәгълүм ит. Тәмам».*

Кызлар хатының тексты кәгазьнең уртасына урнаштырыла. Кәгазьнең дүрт ягында буш урын – киң поля калдырыла. Бу буш урынга, поляга гыйшык җырлары урнаштырыла, бизәк һәм чәчәкләр ясала.

Соңгы вакытларда кызлар хатына кул белән чәчәкләр ясау башланды. Хатларга фабрикаларда эшләнгән чәкәннәр ябыштырыла, хат төсле почта кәгазенә языла.

### *Борынгы мәктәпләрдә күңел ачу, уен-көлкеләр*

Уеннарны хәлфәнең рөхсәте белән балалар үзләре оештыралар. Һәрбер мәктәптә уен оештырырга сәләтле берничә укучы була.

[1] Мәхфи улмаясезләр – сездән яшерен булмасын.
[2] Фәсахәт – матур теллелек.
[3] Бәлягать – сүз сөйләүдә матурлык, төзеклек.
[4] Мәхбүб – сөекле.
[5] Мәргуб – яхшы сыйфатларга ия.

Гадәттә, уеннар ял көне яки бәйрәмнәргә каршы кичләрдә башкарыла. Мондый кичәләр уеннар белән генә чикләнми иде. Кайбер яшьрәк укучылар ашау-эчүләр дә оештыралар. Акча салышып, кибеттән тәмле нәрсәләр сатып алалар яки өйдән алып килгән әйберләрдән берәр нәрсә пешерәләр, самавыр кайнатып, чәй эчәләр. Әлбә, ботка, коймак шикелле әйберләрне укучылар яратып, сөеп эшлиләр. Ашау-эчүгә исә күп кеше катнаштырылмый.

Уен кичәләрендә бер үк вакытта (төрле урында) берничә уен бердән оештырылуы да мөмкин иде, чөнки һәр баланың үзе сөйгән уены була.

Борынгы мәктәпләрдә уртак уеннардан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

**1. Выж-вожак.** Бу уенга 15–20 уйнаучы катнаша ала. Башка балалар карап торалар. Уйнаучылар, табын булып түгәрәкләнеп, кысылып, идәнгә утыралар. Табын уртасына бер уйнаучыны куялар. Моңарга «тәкә» диләр. Уйнаучыларның куллары артта була. «Тәкә»дән яшереп, кулдан-кулга ишелгән сөлге йөртәләр һәм күрмәгәндә «тәкә»гә сугалар да тагын яшерәләр. «Тәкә» сөлгене кем кулыннан алса, шул кеше уртага чыга, «тәкә»гә әйләнә.

**2. Кем сукты.** Бу уенга 10–15 кеше катнаша ала. Аслы-өсле сандык куеп, бер уйнаучыны утырталар һәм моңарга «Мулла» диләр. Мулланың итәгенә бер бала йөзтүбән башын куя. Башка уйнаучылар саф булып басып торалар. Арадан берсе яткан балага ишелгән сөлге белән суга. Арадан берсе: «Кем сукты?» – ди. Кем сукканы дөрес әйтелсә, шул кеше «тәкә» була.

**3. Очты, очты, каргалар очты.** Бу уенны уйнаганда, уйнаучылар табын булып идәнгә утыралар. Уенчыларның куллары тезенә куелган була. Бу уенда «тәкә» булмый, монда такмазачы була. Такмазачы түбәндәгеләргә охшаган сүзләрне такмаклый:

*Очты, очты, каргалар очты.*
*Очты, очты, арбалар очты.*
*Очты, очты, саескан очты.*
*Очты, очты, Фәезхан очты.*
*Очты, очты, торналар очты.*
*Очты, очты, каргалар очты.*
*Очты, очты, казлар очты.*
*Очты, очты, тазлар очты.*
*Очты, очты, үрдәкләр очты.*
*Очты, очты, күлмәкләр очты.*

*Очты, очты, бүдәнәләр очты.*
*Очты, очты, бүрәнәләр очты.* һ. б.

Шушы сүзләрне такмаклаганда, уенчылар яхшылап тыңлап торырга тиешләр һәм оча торган әйбер исеме әйтелгәндә кулларын күтәрергә, очмый торган әйбер исеме әйтелгәндә кулларны күтәрмәскә тиешләр. Уенчылардан берсе ялгышса, ул җәзага тартыла.

**4. Күз бәйләш яки сукыр тәкә.** Уйнаучылар арасыннан берсенең күзен бәйләп уртага алына. Моңарга «сукыр тәкә» диләр. «Сукыр тәкә»не чеметәләр, итәгеннән тарталар да качалар. Кем дә булса «сукыр тәкә» кулына эләксә, ул үзе «сукыр тәкә»гә әйләнә.

**5. Палач уены.** Бу уенга 6 кеше катнаша, калганнары карап кына торалар. Уен түбәндәгечә бара: алты кечкенә генә кәгазь хәзерләп, аларга «Хан», «Казый», «Шаһид», «Угры», «Тугры» һәм «Палач» сүзләрен язалар. Кәгазьләрне бүректә селеккәннән соң, алты кешегә өләшәләр. «Тугры» язуы чыккан уйнаучы: «И ханым-солтаным! Бер корчаңгы атым бар иде, шуны урлаттым», – ди.

Моннан соң «хан» исеме чыккан кеше үзен белдерә һәм: «Менә шуларның эченнән «угры»ны табып ал», – ди. «Тугры», уйнаучылардан берсенә карап: «“угры” синсең», – ди. Дөрес әйтсә, «угры»га, дөрес әйтмәсә, «тугры»га җәза бирелә. Уен шулай дәвам итә. «Шаһид» дөрес әйтмәсә, җәза аңа да бирелә. Җәзаны «Казый» билгели.

**6. Йолдыз санау.** Бу уен – шаян уен. Монда эштән хәбәре булмаган берәр баланы мәсхәрә итәләр. Уен түбәндәгечә бара: берәр савытка көл салып, су белән изәләр. Үз араларыннан бер укучыны идәнгә яткызып, башын тун белән каплыйлар. Тунның җиңен укучының күзенә туры китерәләр дә, очын югары күтәрәләр. Труба формасына охшаталар. Унга кадәр санарга кушалар. «Күрдеңме?» – диләр. «Күрдем», – дигәч, бу укучыны торгызып, башка укучыны яткызалар, санарга кушалар.

Соңгы укучы санап торганда, җиң буенча көлле су түгәләр. Шуның белән уен тәмам була.

Мәктәпләрдә һәртөрле уен уйнарга рөхсәт ителә, ләкин җырлау, көйләү һәм музыка уйнарга рөхсәт ителми. Уку булмаган чакларда, кубыз уйнауга начар каралмый иде. Кайвакытларда мәктәпләрдә кубыз уйнау һәм кубызга биюләр дә оештырыла. Ашык[1] уйнау, чиертлек уйнау мәктәпләрдә сезонлы уеннардан исәпләнә.

[1] Ашык – татар халык уены. Уенда хайванның (гадәттә сарыкның) тубык сөяге кулланыла. «Бишташ», «кузна» дигән атамалары да бар.

***Борынгы мәктәпләрдә күңел сабагы***

Борынгы мәктәпләрдәге укулар турыдан-туры ятлау нигезенә корылган иде. Укучы сабагын тиңгә-тиң ятлаган булса, ул укучы сабагын укыган дип исәпләнә. Сабагын ятламаган, бикләмәгән булса, ул укучы сабагын укымаган дип исәпләнелә. Укучы сабагын ятламаган булса, аның аңлый белүенә игътибар бирелми. Шундый система булуга карамастан, мәктәпләрдә аерым күңел сабаклары да була. Гадәттә, күңел сабакларында намаз тәртипләре, намаз өчен кирәк була торган догалар һәм Коръән сүрәләре ятлатыла. Күңел сабаклары буенча эш бирү, күңел сабакларын тыңлату чәршәмбе көн эшләнә. Гади көннәрдә дә күңел сабагы буенча өй эше бирү булырга мөмкин.

Бик күп мәктәпләрдә, рамазан керү белән, гадәттәге дәресләр туктатыла, алар урынына күңел сабаклары башлана. Рамазан ае буйдан-буйга күңел сабагы белән үтә.

***Укуларны йомгаклау***

Борынгы мәктәпләрдә еллык укуларны йомгаклау, укучыларның белем дәрәҗәләрен билгеләү булмый иде. Җирләр ачылып, хайваннар җиргә басу белән, укучылар мәктәпне ташлый башлый. Мәктәпкә йөрүдән тукталу турында беркемгә хәбәр дә ителми. Шул рәвешчә, мәктәптә укучылар кимегәннән-кими бара. Шушы хәлне күргән мулла дәрестән соң иртәдән башлап дәрескә кермәячәген белдерә. Менә шушы белдереш мәктәптә дәресләрнең тукталу көне була. Ләкин бу вакытта мәктәптә укучылар бик аз калган була инде.

Мәктәптә укулар тукталу белән, казый һәм хәлфәләргә дә эш калмый. Шунлыктан казый һәм хәлфәләр мәктәпне ташларга мәҗбүр булалар.

Укучылар таралып бетү белән, мәктәпнең тәрәзә ишекләре кадаклана. Кеше йөрмәү сәбәпле, мәктәп әйләнәсен чүп үләне баса. Мәктәп тирәсен шомлы бер тынлык басып ала. Инде балалар гына түгел, кайбер зурлар да мәктәп ягына барырга шикләнәләр, куркалар. Укучылар да, халыкның күпчелеге дә хәзер мәктәпкә «җен оясы» дип карый. Мәктәпкә хәзер «пәриләр тулай торагы» дип карала. Шул уңай белән, мәктәпләр турында төрле сүзләр дә тарала.

# II. КЫЗ БАЛАЛАР ӨЧЕН БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘП

Кыз укучылар «мәктәпкә барабыз» яки «мәктәптә укыйбыз» дигән сүзләр кулланмыйлар. Кыз балалар «сабакка барабыз» яки «абыстайга барабыз» диләр. Чөнки авылларда да, шәһәрләрдә дә кыз балалар өчен мәктәп биналары булмый иде. Кыз балалар мулланың аш өендә яки мулланың кара өендә генә укыйлар. Авылларда аш өйләре һәм кара өйләр хайвансыз, кош-кортсыз була алмый. Шунлыктан бу өйләр, мәктәптән бигрәк, хайван абзарына охшыйлар. Бу өйләрдә мәктәплекне күрсәтә торган бертөрле дә билге юк. Кайбер урыннарда мәктәп мөәзин өенә урнашкан була. Кыз балаларны мөәзин хатыны – мөәзин абыстай укыта.

Мәктәп мулла өендә урнашкан булса, мәктәпнең укытучысы да, хуҗасы да мулла абыстай (мулланың анасы яки хатыны) була. Әгәр мәктәп мөәзин өендә урнашкан булса, мәктәпнең хуҗасы һәм укытучысы мөәзин абыстай була. Кыз балаларны мулла абыстайлар укытырга теләмәсәләр генә, мөәзин абыстайлар укыта алалар. Кайбер авылларда яки шәһәрләрдә кыз балаларны мулла абыстай да, мөәзин абыстай да укытырга теләми. Мондый урыннарда кыз балаларны укыту эшен башка берәр хатын алып бара. Ничек кенә булмасын, авылда берәр абыстай укыту эшен алып бара.

Авылларда мәктәп күрмәгән ир бала бик аз, 4–5% кына булырга мөмкин. Авыл кызларының исә 20–30% ы сабак һәм мәктәп йөзе күрә алмый.

Кыз балалар мәктәбенең уку сәгатьләре ир балалар мәктәбенә охшамый. Кыз балалар мәктәбендә укулар көнгә бер мәртәбә була. Шуның белән бергә, кыз укучылар бер очтан мәктәпкә килә торалар, икенче очтан китә торалар иде.

Хатын-кызларның бөтен җирләре – гаурәт. Гаурәтне ирләргә күрсәтергә ярамый. Борынгы вакытларда ата-аналар кыз балаларның гәүдә килешләрен дә ирләргә күрсәтүдән сакланалар иде. Шулай булгач, көпә-көндез бер кызның мәктәпкә баруына кайсы ата-ана разый булсын?! Менә шуның өчен дә кыз балалар сабакка караңгыда киләләр, караңгыда китәләр иде. Иртә намазының соңгы срогы кояш чыгу белән билгеләнә. Кызлар иртә намаздан чыгучылар белән очрашудан куркып, кояш чыкканчы, мәктәптән таралган була. Уртача исәп белән, кыш көне кояш 7–8 сәгатьтә чыкса, укучы кызлар мәктәпкә төнге 5–6 сәгатьләрдә килә башлыйлар, 7–8 сәгатьләрдә

таралып беткән булалар. Кыз балалар мәктәбендә өстәлләр дә, шүрлекләр дә булмый. Идән пычрак, анда укучылар утырырлык чиста һәм таза җир дә булмый иде. Шуның белән бергә, мәктәптә барлык киемгә җитәрлек элгечләр дә һәм барлык киемне куярга урын да булмый. Шунлыктан укучылар дәрес вакытында өс киемнәрен салмыйлар да, утырмыйлар да. Сабак тыңлату, сабак алу аяк өстендә генә дәвам итә. Утырырлык урын да һәм утырырлык вакыт та булмый. Өйнең сәкесе аш-су әйберләре, табак-савытлар белән тулып калган була. Монда тик абыстай утырырлык кына буш урын була. Бу урын – абыстайның дәрес бирә торган урыны. Бөтен укучы шул урынга карап юнәлгән. Сабакка чиратта торалар: «Мин Галимә артыннан, Галимә Фатыйма артыннан», – диләр. Урынны үзара ныгытып куялар.

Кагыйдә буларак, кыз балаларның сабак вакыты абыстайның кызу эш вакытына туры килә. Мичләргә ягасы бар. Моның өчен салам яки утын кертергә кирәк. Сыер савасы, хайваннарны карыйсы бар. Хәзрәтнең урын-җирләре җыелмаган. Бала уянган, аны көйләргә кирәк. Хәзрәткә ашарга бирәр нәрсә пешерәсе бар. Абыстай менә шул хәлдә сабак укытырга тиеш. Шулай булгач, бу эшләрне кем башкара? Бу – бик ачык, барлык эшләрне укучы кызлар эшли, йорт эшләре укучылар өстенә төшә.

Укучы кызлар арасында уку белән кызыксынмый торганнары да була. Мондый кызларны сабактан азат итсәң, теләгән эшне эшләтергә мөмкин. Менә бу кызлар абыстайның уң кулы булып торалар, йортның барлык эшен башкаралар. Эшкә үзләре генә җитешә алмасалар, башка кызларны да кушалар. Бу кызлар башкалардан элек киләләр, соң китәләр.

Кайбер исәпсезрәк абыстайлар бу кызларга тагын да киңрәк хокук бирә. Шуннан файдаланып, бу актив кызлар хәзрәт тирәсендә дә әйләнә башлый: тәһарәткә җылы су бирәләр, сөлге тоталар, урын җыялар һәм ашарга әзерлиләр. Шулай эшли торгач, йортта намәхрәм[1] булган бу кызлар мәхрәм булып китәләр. Элек шәүләләрен күрсәтергә тартынган кызлар хәзер, яулык читен тешләп, хәзрәт янына кергәли башлыйлар.

Менә шундый актив кызлар, кайбер очракларда абыстай хакына катнашып, мәктәп тарихына кер дә төшерәләр. Мулланың да исеме чыга, кызлар да атка калалар.

[1] Намәхрәм – ерак кардәш һәм бөтенләй кардәш булмаган кеше.

Кыз балалар мәктәбендә дә уку елының башлануы электән билгесез була. Гадәттә, кыз балаларның укуы җир туңып, кар төшкәч башлана һәм каз өмәсе, каз бәйрәме чорына туры килә. Кыз балалар да, ир балалар шикелле, мәктәпкә бик акрынлык белән генә тупланалар. Шуңа карамастан, яз көнендә бик тиз таралалар, бер көн эчендә юк булалар да куялар. Кыз балалар мәктәбенең дә уку елы, уку срогы билгеле түгел. Ул, кайбер укучыга карап, озын була ала, кайбер укучыга карап, кыска була ала.

Укучы зур кызлар арасыннан кайберләре укыту эшендә абыстайга ярдәм дә итешәләр иде. Болар кечкенә кызларның сабакларын өйрәтәләр, яңа сабак та бирәләр.

***Кызлар мәктәбендә укучы һәм укытучылар составы***

Гадәттә, кызлар мәктәбенең башында бер хатын тора. Әгәр бу укытучы хатын мулла хатыны булса, «мулла абыстай», мөәзин хатыны булса, «мөәзин абыстай», гади кеше хатыны булса, исеме белән, «Җәмилә абыстай», «Фатыйма абыстай», диләр.

Бик күп мәктәпләрдә укыту эшләрен абыстайлар үзләре генә алып баралар. Ярдәмче укытучылардан файдаланучы абыстайлар да була. Кайбер абыстайлар мәктәпнең хуҗасы саналсалар да, үзләре укытмыйлар, күз-колак кына булып торалар. Укытучы итеп башка кеше алына. Ләкин мондый мәктәпләр бик сирәк.

Ир балалар мәктәпләрендә хәлфәләр дә, ярдәмче хәлфәләр дә мөстәкыйль иде. Хәлфәнең дә, ярдәмче хәлфәнең дә үзенә беркетелгән укучысы була. Кызлар мәктәпләрендә эш башкачарак тора. Монда ярдәмчеләргә укучылар беркетелми. Ярдәмчеләрнең укытулары абыстайның кушуы буенча гына эшләнә. Абыстайның: «Сара, син кил монда!», «Галия, син Фатыймага бар!» дигән сүзе – укучылар өчен закон. Сара – абыстайдан, Галия Фатыймадан сабак ала иде.

Бер мәхәлләнең кыз балалары икенче мәхәллә абыстаена йөри алмый. Бу хәл ике мулла арасында да һәм ике абыстай арасында да зур шау-шуларга сәбәп була. Мондый шау-шуларның судлашуга кадәр җитү фактлары бар.

Ир балалар мәктәпләрендә кыз балалар уку гадәте юк. Мәктәп тарихында мондый хәл күренми. Ләкин ир балаларның абыстайлардан сабак укулары мөмкин була торган иде. Кызлар мәктәбендә ир балалар уку билгеле яшькә кадәр генә була.

Ир балалар мәктәбендә хатын укучылар, кыз балалар мәктәбендә ир укытучылар укыту булмады, чөнки моңарга халык начар карый иде.

***Кызлар мәктәбенең программасы, дәреслекләре һәм укыту методы***

Кыз балалар мәктәбе программасы белән ир балалар мәктәбе программасы арасында кискен бер аерма юк иде. Авыр төрек телендә нәзым белән язылган «Мөхәммәдия» китабы ир балалар мәктәбе программасына кертелми. Кыз балалар мәктәбендә «Мөхәммәдия» күренекле урын ала иде. Шуның белән бергә, кыз балалар мәктәбе программасында (дәрес ятлаудан тыш) ятлауларга аз урын бирелә.

Кыз балаларның дәрес вакыты аяк өстендә үтә. Шуның өчен кыз балалар мәктәптә озак тора алмыйлар. Кызлар, мәктәптә иске сабакны тыңлатып, яңа сабак алу белән, эшне беткәнгә хисаплыйлар иде. Шуның өчен дә кызлар мәктәпкә бер очтан килеп торалар, икенче очтан китеп торалар.

Кыз балалар мәктәбендә камчы белән чыбыркы да һәм камчылау, чыбыркылау да бик сирәк була. Моны кайбер «ирдәүкә», карт абыстайлар гына эшли.

Кыз балалар мәктәбендә язу өйрәтү бик нык тыела. Кызларга язу өйрәтүне шәригать тыймаган булса да, язу хатын-кызны бозыклыкка тарта, ирләргә хат язарга юл ача, диләр иде. Шушы фикер белән кызларга язу өйрәтү гөнаһ эшләр рәтенә куела. Кызлар мәктәбендә язу өйрәтүгә мөмкинлек тә булмый. Чөнки укытучы абыстай үзе дә яза белми. Абыстай язу өйрәтүнең юлын да, рәвешен дә белми.

Укытучы абыстайлар арасында төрекчә, гарәпчә һәм фарсыча язылган дини китапларны иркен аңлаучылар да булгалый. Шуңа карамастан бу абыстайлар үз исемнәрен язарлык кадәр генә дә язу белмиләр. Араларында язу белүчеләр сирәк була.

Ир балалар мәктәбендә нинди дәреслекләр кулланылса, кыз балалар мәктәбендә дә шул дәреслекләр кулланыла. Шуның белән бергә, кызлар мәктәбендә нәзым юлы белән төзелгән дәреслекләр алда тотыла, сөеп-яратып укыла.

Укучы кызларның үзләре өчен дә, кызның ата-аналары өчен дә «Мөхәммәдия» уку зур теләк һәм тәмле хыял иде. Авылда кызлар өчен «Мөхәммәдия» укый белү зур шәрәф, зур бәхет санала.

Авылларда җомга көн төш вакытында ирләр мәчеткә баралар. Шул ук вакытта хатын-кызлар мулла өенә җыела. Бу хатын-кызлар арасында карт әбиләр дә, урта яшьле апалар да, яшь киленнәр дә була. Хатын-кызлар абыстайга буш кул белән килмиләр, сәдака белән киләләр. Сәдакалар бик төрле була: он-ярма, чәй-шикәр, итмай, тоз-йомырка, ипи-күмәч, тегәрҗеп һәм шуңа охшаган нәрсәләр.

Шушы сәдакаларга каршы мулла абыстай вәгазь сөйли, «Мөхәммәдия» укый. Шул юл белән ул хатын-кызларның күңелләренә үтеп керә.

Оста сәясәт йөртүче абыстайлар «Мөхәммәдия»не (үзендә укый торган) кызлар белән хор булып та укыйлар, аерым кызларның үзләреннән генә дә укыталар. Шуның нәтиҗәсендә абыстай бер яктан күңелгә керүне көчәйтсә, икенче яткан кызларга күзәтү ясый, аларны башкаларның күзенә чагылдыра.

Ничек кенә булмасын, укылган «Мөхәммәдия» хатын-кызларда төрле тәэсир калдыра. Гадәттә, бу тәэсир ике яклы була:

1. Әмма Гайшә бәхетле дә соң, ике кызы, икесе дә сандугач шикелле сайрыйлар. «Мөхәммәдия» укыганда тыңлап туймассың, үзләре матур, үзләре зифа, диләр. Болар – битараф хатыннар.

2. Остабикәгә ни әйтим, Фагыйлә кызларын, түренә мендереп, яшелле-зәңгәрле тавышлары белән «Мөхәммәдия» кычкырткан була. Төсләре дисәң, төсләре юк, бите дисәң, бите юк, мәхәббәтсезләр. Әйтерсең кеше алар чырылдаганны ишетергә бара, ди. Болар инде – үзләренең кызлары «Мөхәммәдия» укый алмаганга көнләүче хатыннар.

«Мөхәммәдия» китабы моннан 400–450 еллар элек Мөхәммәт Чәләби исемле төрек язучысы тарафыннан бик авыр төрек телендә язылган. Әсәр дини нәзымнан гыйбарәт. 344 биттән торган бу китап нинди юл белән татар мәктәпләренә килеп кергәндер дә, ничек итеп татар халкы арасында бу кадәр дан казангандыр?!

Мәктәпләрдә «Мөхәммәдия» китабы башыннан ахырына кадәр тоташтан укылмый, темасына карап, сайлап кына укыла. Абыстайлар арасында яратып укыла торган һәм яратып тыңлана торган бүлегендә шулай язылган:

*Әля и сәрвәре мәхбүб, мин әл-әйни иләл-әйни.*
*Гүзәл йөзеңне чарыз әйлә, кәтер йөздән хиҗабәйни.*
*Йөзең бәнун мәсанидер, яраһе мән яранидер.*
*Вәлякин лән тәранидер, тәхәйярьте биһатәйни.*

Шуның белән бергә, кайсыбер кызлар мәктәбенә, дәреслек булып, «Алты бармак»[1] исемле төрек телендә язылган тарих китабы да килеп кергән.

[1] «Алты бармак» китабы – дини-әхлакый әсәр, авторы – госманлы галиме Мөхәммәт ибне Мөхәммәт Чокрыкчызадә (1623 елда вафат).

Гарәп телендә язылган дәреслекләрне абыстайлар грамматика ягыннан бик артык бозып укыйлар. Ләкин, шуңа карамастан, мәгънәсен дөрес чыгаралар, дөрес бирәләр.

***Абыстайның хезмәт хакы***

Мәктәпләрдә балалар укыту җиңел эш түгел. Муллалар, абыстайлар бу эшне, «Аллаһ ризалыгы өчен» дип әйтсәләр дә, хаксыз эшләмиләр. Борынгы мәктәпләрдә хезмәт хакы «сәдака» иде.

Ир балалар мәктәбендә кече атна сәдакасы акча белән бирелә иде. Кыз балалар мәктәбендә сәдака булып төрле нәрсә кабул ителә. Кыз балалар сәдака итеп төрле нәрсә китерәләр: он, ярма, май, йомырка, күмәч, ипи, бәрәңге, тегәрҗеп, җон җебе һәм акча. Болар бар да сәдака була ала.

Абыстайның ярдәмчеләренә сәдака бирү гадәте юк дәрәҗәсендә сирәк була.

Зур шәһәрләрдә кыз балаларны мулла абыстайлар гына укытып өлгерә алмыйлар. Шунлыктан татарлар күп булган шәһәрләрдә бераз белеме булган хатыннар да кыз балаларны укыталар. Кызлар укытуны үзенә кәсеп итеп алган һәм шәһәр халкы арасында танылган мондый абыстайлар күп була иде. Казан, Уфа, Әстерхан, Оренбург һәм Троицк шикелле шәһәрләрдә мондый кызлар мәктәбен дистәләрчә күрсәтеп була. 1905 елдан соң оештырылган хосусый яңа мәктәпләрнең кайберләре борынгы абыстайлар мәктәбеннән башланып киткән мәктәпләр иде.

***Соңгы сүз***

Ир балалар мәктәбендә дә, кыз балалар мәктәпләрендә дә ана теле яки татар теле дәрес булып укылмады. Төрки тел дигән бер сүз телдә йөрсә дә, төрки тел аерым бер предмет булып түгел, бәлки төрки телдә (чыгтайча, төрекчә, казакъча) язылган дини һәм әхлакый дәреслекләрне укудан гына гыйбарәт булды. Очраклы рәвештә булган бу төрки укуны уку дәресе дип күрсәтү мөмкин түгел иде.

Кайбер ир балалар мәктәпләрендә «цифр сугу» исеме белән атап, 100 гә, 1000 гә кадәр сан өйрәтсәләр дә, кыз укучыларга сан өйрәтелми. Саннар эчендә дүрт гамәл өйрәтү бер мәктәптә дә юк иде.

Ирләр мәктәбендә дә, кызлар мәктәбендә дә тарих, география һәм табигать фәннәре укытылмады. Бу фәннәрне укытучылар үзләре дә белмиләр иде.

# БОРЫНГЫ ТАТАР МӘДРӘСӘЛӘРЕ

### *Мәдрәсәләрне оештыру*

«Мәдрәсә» – гарәп сүзе, исеме мәкам – урын исеме, дәрес бирә торган урын дигән сүз. Безнеңчә әйткәндә, «уку йорты» дигән сүз була.

«Мөдәррис» – дәрес бирүче дигән сүз. Безнеңчә, профессор яки шуңа охшаган югары дәрәҗәле укытучы.

«Мөгаллим» – гади укытучы. Борынгы мәктәпләрдә мөгаллимне «хәлфә» дип атыйлар. Мәдрәсә шәкертләре мөдәррисне хәзрәт һәм дамелла дип атыйлар иде.

Мәдрәсә гади уку йорты гына түгел, ул борынгы заманның югары белем бирә торган югары уку йорты булып исәпләнелә. Шуның өчен дә башлангыч мәктәп бетермәгән кеше мәдрәсә дәресләренә керешә алмый.

Югары уку йорты булуга карамастан, мәдрәсәгә кабул ителү өчен, яшьнең әһәмияте юк. Шунлыктан мәдрәсә шәкертләре яшь ягыннан бик чуар булалар. Мәдрәсәләрдә 11–12 яшендәге балалар белән бергә 25–30 яшендәге абзыйлар һәм 50–60 яшендәге бабайлар да була.

Гадәттә, мәдрәсәләр очраклы оештырылмый. Мәдрәсә барлыкка килер өчен, берникадәрле шартлар кирәк була:

• Мәдрәсә тәрбия итү белән кызыксынган һәм шәкертләр тәрбия итәрлек гыйльми көчкә ия булган бер мулланың булуы.

• Мәдрәсә өчен бина торгызучы һәм мәдрәсәнең агымдагы расходларын күтәрүче бер хәлле кешенең булуы.

• Мөдәрриснең берәр мәхәлләдә рәсми, указлы имам булуы, чөнки патша законы буенча, мәдрәсәләр мәхәллә каршында гына ачыла ала.

Татар мәдрәсәләрен торгызуда да, аларны тәрбияләүдә дә патша хөкүмәте татарларга ярдәмләшмәде. Шуның белән бергә, мәдрәсәләр белән кызыксынмады да. Мәдрәсәләр ачу өчен, хөкүмәттән аерым рөхсәт кирәкми, мәчет каршында булуы җитә иде. Мәчет каршында булмаганда мәдрәсә ачарга бөтенләй рөхсәт ителми.

Милли һәм дини хәрәкәтләргә бик зур итеп караган һәм алардан куркып, өркеп торган хөкүмәт һәм аның түрәләре мәдрәсәләргә дә, шәкертләргә дә ышаныч белән карыйлар. Моның сәбәбе нәрсәдер?

Мулла һәм мөдәррисләрнең хөкүмәт каршында артык ышанычлы булуларымы яки мулла һәм мөдәррисләрнең кулларыннан һичбер нәрсә дә килми дип, ныклы ышануданмы?

Берәр мулла үзендә шәкерт тәрбия итәрлек көч барлыгын сизә, үзе булынган авыл яки шәһәрдә мәдрәсә ачып, шәкерт тәрбияләргә җир-зәмин барлыгын күрә. Мулла материаль мөмкинлекләр эзләп таба. Менә шуннан мәдрәсә барлыкка килә.

Мәдрәсә башында тору кайбер кешеләрдә бик иртә, хәтта шәкерт вакытта ук башлана. Менә мондый кешеләр мәдрәсә ачу турындагы мөмкинлекләрне бик иртә – шәкерт чакларында ук эзли башлыйлар. Болар, җирле мәдрәсәләрдә тырышып укыганнан соң, Бохара шикелле атаклы мәдрәсәләргә баралар. Мәхәлләгә урнашуда да, өйләнүдә дә һаман шул мәдрәсә оештыру расчетын алга сөрәләр. Нәтиҗәдә зур, кечкенә бер мәдрәсәгә хуҗа булалар, мөдәррислек исемен алалар иде.

Татар мәдрәсәләрендә дәрес бирүче мөдәррисләрнең зур күпчелеге Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәсендә укыган кешеләр була. Мисыр, Мәккә, Мәдинә һәм Истанбулда укыган мөдәррисләр дә бар иде. Борынгырак вакытларда Кашгарда укып кайткан мөдәррисләр дә булгалаган.

Элекке Саратов губернасы Хвалын өязе Минһаҗ Кадермәтев[1] дигән бер кеше кече яшьтән үк мөдәррис булу фикеренә төшә. Татар мәдрәсәләренең берсендә хәтме көтеб кылгач[2], нам[3] һәм шөһрәт казану теләге белән, Һиндстанга бара. Һиндстанда берничә ел укыганнан соң, «Һинди Минһаҗ» исеме белән Россиягә кайта (1907–1908 елларда). Хвалын шәһәренә «Мәдрәсәи Галия» ачу фикеренә керә. Шушы уңай белән Россиянең бер очыннан икенче очына кадәр йөреп, байлардан акча туплый. Зур суммалар кулга керткән бу кеше беркемгә дә отчет бирергә теләми. Моңарга халыкның кәефе китә. Бу вакыйга мәрхүм Г. Тукайга да тәэсир итә. Шул уңай белән Тукай:

*Таш ташыйлар. Анда Минһаҗ «Галия» нигезен сала.*
*Туй ясыйлар. Монда Минһаҗ гаилә нигезен сала.*
*Салыныр да, төпләнер дә, бик уңайдыр соңгысы;*
*Шикләнәм мин вә әллә ник: булмас кеби әүвәлгесе,* – ди.

---

[1] Минһаҗетдин Кадермәти (Кадермәтев) (1870–1925) – «Һинди Минһаҗ» тәхәллүсе белән билгеле зат.


[2] Хәтме көтеб кылгач – укуын тәмам иткәч.

[3] Нам – исем.


***Борынгы мәдрәсәләрнең тышкы һәм эчке күренешләре***

Гадәттә, борынгы татар мәдрәсәләре авылларда, шәһәрләрдә оештырыла алалар. Казан шәһәре тирәсендәге мәдрәсәләрдән Әлмәт, Тайсуган, Дәвеш, Түнтәр һәм Кышкар мәдрәсәләре данлыклы авыл мәдрәсәләре иде.

Авыл мәдрәсәләре тышкы күренешләре белән гади авыл өйләреннән аерылмаган шикелле, шәһәр мәдрәсәләре дә тышкы күренештә гади шәһәр өйләреннән аерылмыйлар. Мәдрәсәләрнең тышкы күренешләре белән таныштыру өчен, түбәндә авыл һәм шәһәр мәдрәсәләренең рәсемнәрен урнаштырабыз.



*Шәһәр мәдрәсәсе*



*Авыл мәдрәсәсе*

Мәдрәсәләрнең эчке төзелеше һәм эчке күренеше белән таныштыру өчен, бер-ике мәдрәсәнең эчке төзелеше турында сөйләп узарга туры килә. Моның өчен элекке Сембер губернасы, хәзерге ТАССРның район үзәге булган Буа шәһәрендә Ильяс хәзрәт тарафыннан оештырылган, төзелеш ягыннан бик садә булган Буа мәдрәсәсе белән Казан шәһәрендәге Айтуганов мәдрәсәсен – югарырак төзелешле бер мәдрәсәне алыйк.

**Буа мәдрәсәсе.** Мәдрәсә бионалары киң ишегалдына корылган булып, аерым-аерым салынган дүрт өй һәм бер ашханә-кухнядан тора. Өйләр тышкы күренешләре белән гади Буа өйләреннән аерылмыйлар. Бу дүрт өйнең өчесе агачтан, берсе кызыл кирпечтән эшләнгән.

Урам буена салынган таш бина шактый зур. Урамга алты, ян-янга дүртәр тәрәзә туры килә. Тәрәзәләр зур кулда эшләнгән, тәрәзә аралары да киң калдырылган.

Бу таш бинаның тактадан ясалган өйалдына керү белән, бинаның ишеге күренә. Ишектән керү белән, без үзебезне мәдрәсәнең эчелегендә басып торган кебек күрәбез. Әчелекнең ике ягында котсыз зур ике мич күренә. Күп еллар хезмәт итүгә карамастан, аз ремонт күрү аркасында, мичләрнең авызы җимерелеп, гади тишеккә

әйләнгәннәр, мичнең агарту күрмәвенә ел гына түгел, дистәләрчә еллар булганы ачык күренеп тора. Стена һәм түшәмнәре штукатурланмаган.

Бинаның тәрәзә өсләренә туры китереп, стена әйләнәсе киң шүрлек белән уратылган. Шуның белән бергә, стенада 3 метр чамасы ара калдырып, түшәмгә тагылып, тагын бер шундый шүрлек ясалган. Бер-беренә параллель булган шүрлекләр тәрәзә арасы саен тагын шүрлек белән тоташтырылган.

Бинаның тәрәзә турылары, шүрлек тирәсе чаршау белән әйләндереп алынган. Шулай итеп, чаршау ярдәме белән мәдрәсә берничә бүлмәгә әйләндерелгән. Барлык чаршауларны шүрлеккә күтәреп куйганда, бина зур залга әйләнә. Укучыларның ятак әйберләре, кием-салымнары бүлмәне әйләндереп алган шүрлекләргә куела. Шүрлектәге ямьсезлек һәм тәртипсезлекләр күренмәсен өчен, шүрлек аралары үзенә бертөрле чаршау белән капланган була. Түшәмгә параллель булган горизонталь бу чаршауга шәкертләр «әзәл» диләр.

Чаршау белән уратып ясалган бу бүлмәләрнең һәрберсендә тәрәзә төбендә бер-ике тәбәнәк өстәл була. Гадәттә, бу тәбәнәк шәкерт өстәленең биеклеге ярты метр чамасыннан артмый. Өстәлнең ике ягында ике хәлфә, ә кайбер бүлмәләрдә ике пишкадәм[1] утырган була. Бу ике кеше бүлмәнең төп хуҗалары булып саналалар. Чаршау менә шушы ике кеше тарафыннан куелган була. Шуның белән бергә, бу бүлмәдә хәлфә яки пишкадәмнәрдән тыш, берничә пәскадәм шәкертләр дә була. Күп вакытта бу пәскадәм шәкертләр бүлмә хуҗалары булган хәлфә яки пишкадәмнәрнең якыннары яки кардәшләре булалар.

Мәдрәсәнең атаклы зур һәм карт хәлфәләре бүлмәгә берүзләре генә дә хуҗа була алалар иде. Мондый хәлфәләр, көндәлек хәзмәтләрен үтәү өчен генә, бер-ике пәскадәмне бүлмәләренә алалар иде. Шуның белән бергә, һәр мәдрәсәдә «малайлар бүлмәсе» дип йөртелә торган бер-ике бүлмә була. Бу малайлар бүлмәсе зурлыкта башка бүлмәләр белән тигез булса да, бүлмәдә торучылар искиткеч күп булалар иде. Мондагы тыгызлыкны күз алдына китерер өчен, аларның кич, яткан вакытларын хәтергә китерергә кирәк. Бүлмәдә идәнгә ятучылар таяк шикелле туп-туры ятарга тиешлеләр, бөкләнеп ятуны уйларга да ярамый. Шуның белән бергә, мондагы

[1] Пишкадәм – укуда башкалардан алда баручы шәкерт.

шүрлекләр дә ятучылар белән тулган була, кайберләре җәмәгать сәкесенә дә чыгып ятучан булалар.

Кыска гына итеп әйткәндә, 7–8 квадрат метрлы бу бүлмәдә 10–15 тән артык шәкерт урнашкан була.

Гадәттә, бу бүлмәләрнең хуҗалары мәдрәсәдә укымастан гына дәрәҗә үстереп ятучы надан һәм зур яшьле бер-ике абзый була. Калган шәкертләр авыллардан килгән крестьян-мужик малайлары иде.

***Мәдрәсәнең күренеше***

Хәзер инде мәдрәсәнең урамга караган кечкенәрәк бинасына барыйк. Бу бина уртасы чолан белән аерылган кара-каршы ике өйдән тора. Өйнең һәркайсында тугызар тәрәзә. Бинага ишектән керүгә – «әчелек». Әчелектән тар гына коридор башлана. Коридорның ике ягында өчәр бүлмә. Димәк, һәр бинада алты бүлмә була. Мондагы бүлмәләр таш бинадагы шикелле чаршау белән эшләнмәгән, такта белән әйләндереп алынган. Бүлмәләрнең стеналары да һәм ишекләре дә бик игътибарсыз эшләнгән – рәтләп юнылмаган, шомартылмаган. Бер күз салу белән, бүлмә стеналарына оста кулы тимәгәнлеге күренеп тора. Турысы – бүлмәнең стеналары һәм ишекләре дә шәкертләрнең үз куллары белән генә эшләнгән.

Бүлмәнең эчендә шул ук шүрлекләр, шул ук тәбәнәк өстәл. Бүлмәләрнең эче шактый җыйнак, матур, стеналарына чуар кәгазьләр-обойлар ябыштырылган, түшәме агартылган. Коридорның ике ягында ике мич. Коридорның каршы очында ике катлы шүрлек. Аның берсе – ятак әйберләре, икенчесе китаплар куяр өчен ясалган. Тәрәзә төбендә шул ук тәбәнәк өстәлләр. Менә бу күреneш – коридорда да торганнар булганын күрсәтә торган галәмәтләр.

Бүлмәләрнең такта белән бүленгән булуы, коридорның да шәкертләр торырлык җыйнак һәм чиста булуы бу бинада торучыларның аерым шартларда яшәүче шәкертләр икәнен ачык күрсәтә. Дөресе дә шулай. Бу бинадагы бүлмәләрдә мәдрәсәнең атаклы һәм олы хәлфәләре торалар. Шуның белән бергә, шушы мәдрәсәдә сакалы агарган суфилар да үзләренә бүлмә әзерләгәннәр. Бу бүлмәләрнең иң яхшысында Шәрәфи суфи берүзе генә тора. Мондый бүлмәләрдә берничә мулла улы һәм берничә бай баласы да була. Мәдрәсәләрнең мондый биналарында «малайлар бүлмәсе» була алмый.

Ишегалды (йорт) уртасында кызыл кирпечтән эшләнгән тәбәнәк – ярым подвал бер бина күренә. Бу бина мәдрәсәнең ашханәсе була. Моның ашханә икәне ерактан ук күренеп тора.

Ашханәгә керү белән, безнең күзгә түбәндәгеләр бәреләә:

1. Үз тарихында сөртү, агарту күрмәгән стена.

2. Чистарту һәм ремонт күрмәгән һәм корымланып беткән тәрәзә.

3. Югарыгы ике почмакта ике бүлмә – кабина. Бу бүлмәләрдә шәкертләр тәһарәт яңарталар һәм госел коеналар.

4. Ишектән керүгә сул якта – җимерелеп беткән мич. Бу мич үзенең ягылу сәләтен күптән югалткан инде.

5. Мич белән беррәттән 4–5 казан (учак). Бу казаннарда шәкертләр аш пешерәләр.

6. Уң як стена буйлап озын өстәл куелган. Юнылып, яргаланып беткән бу өстәлдә 2–4 аш самавыры тора.

Тарих буенча пычрак сулар идәнгә түгелү нәтиҗәсендә, ашханәдә бозык һәм авыр һава күтәрелгән. Шуның өстенә күзачкысыз төтен һәм караңгылык басып алган.

Хәзергә әле ашханәдә кеше аз. Озакламый аш пешерү башланачак. Бу вакыт ашханә шәкертләр белән тулып калачак. Әйбер куярга да, аяк басарга да урын калмаячак. Шау-шу күтәреләчәк. Сугышлар кузгалачак. Караңгылыктан файдаланып, урлаулар башланачак.

Ашханәдән чыгып, озын агач бинага күз төшерик. Бу озын бинага мәдрәсә шәкертләре «мойка» диләр.

Мойканың эчке төзелеше дә, эчке күренеше дә бер төсле, бер калыпта. Шул ук шүрлек, шул ук чаршау. Тик мойка таш пулатка караганда зуррак кына.

Мойканың көнбатыш очында зур һәм киң бер бүлмәсе бар. Аерым ишекле бу бүлмә коры, якты, җылы һәм чиста-саф һавалы. Бүлмәнең идәненә, тутырып, соры сукно җәелгән. Урта бер урында – тәбәнәк шәкерт өстәле. Бүлмәдә шуннан башка бер җиһаз да юк. Анда беркем дә тормый, бүлмәне карап торыр өчен, тик бер шәкерт кенә билгеләнгән.

Югарыда сөйләнгән бу бүлмә мәдрәсәнең дәресханәсе – баш аудиториясе була. Монда дамелла-хәзрәт дәрес укыта. Дамелла белән бергә була торган иҗтимаглар[1] да шушы бүлмәдә оештырыла. Шәкертләр җыелышны «иҗтимаг» диләр.

Таш пулатка каршы тагын бер агач бина бар. Бик зур булмаган бу бинаның эчке төзелеше башка биналарның эчке төзелешеннән бертөрле дә аерылмый. Моның башка биналардан аермасы булса,

[1] Иҗтимаг – бер урынга туплану, җыелу.

ул да аның тора торган кешеләрендә. Элек-электән монда «вак-төяк халыклар», әһәмиятсез шәкертләр тора.

Без монда Буа мәдрәсәсе турында сүз алып бардык. Гадәттә, авыл мәдрәсәләре биналарның саны ягыннан бер-берләренә охшамасалар да, эчке һәм тышкы төзелешләре ягыннан берсе икенчесенең копиясе булалар.

Авыл һәм шәһәр мәдрәсәләренең барысында да дәресханәләр була. Кайбер мәдрәсәләрнең дәресханәләрендә дәресханәне карап торучы сыйфатында бер-ике шәкерт тә тора.

Уфа һәм Оренбург шикелле зур шәһәрләрдәге кайбер мәдрәсәләр чаршау белән бүленмәгән була. Мондый мәдрәсәләрдә бүлмәләр бердәм зур күләмдә булалар, икенчедән, такта яки кирпеч белән бүленгән була. Хәлфә һәм пишкадәмнәр өчен булган бүлмәләрдә 15–20 шәкерт, пәскадәмнәр өчен булган бүлмәләрдә 25–30 шәкерт урнаша. Зур шәһәрләрдәге мәдрәсәләргә мисал итеп, Казан шәһәрендәге Айтугановлар – Зәңгәр мәчет мәдрәсәсен күрсәтергә була. Рәсемдә күренгәнчә, бу мәдрәсә ике катлы зур гына таш бинадан тора. Бина коридор системасында булып, аскы катта тигез зурлыкта биш бүлмә, бер зур ашханә һәм хезмәтче бүлмәсе. Өске катта шундый ук зурлыктагы алты бүлмә, киң һәм зур дәресханә-аудитория. Урамга караган парадный ход ябык, эшләми. Зур шәһәрләрдәге мәдрәсәләрнең күпчелеге менә шундый – Айтуганов мәдрәсәсе тибында була.

Айтуганов мәдрәсәсенең башка мәдрәсәләрдә булмаган бер яхшы ягы булса, ул да аның эчке төзелеш ягыннан культуралы булуы һәм кайбер яктан җитеш булуында.

Айтуганов мәдрәсәсе уку-укыту ягыннан башка мәдрәсәләрдән өстен тормаса да, чиста һәм культуралы булуы ягыннан Казан мәдрәсәләренең бөтенесеннән югары тора иде. Бүлмәләр яхшы итеп, майлы буяу белән буялган һәм елдан-ел буялып тора. Өске каттагы бүлмә идәннәренә яшел сукно җәелгән, коридорларга һәм баскычларга бизәкле матур дорожкалар (паласлар) сузылган. Коридорларда капкачлы һәм ак металлдан ясалган чүп савытлары куелган.

Һәр бүлмәдә имәннән ясалган ике зур шкаф – буфет. Бу шкафларда, шәкертләр файдаланыр өчен (берсе зур, берсе кечкенә), ике бакыр кәстрүл, ике зур, ике кечкенә бакыр чәйнек куелган.

Дәресханәсе зур, якты. Тәрәзә төпләре һәм стена буйлары зурлы-кечкенәле гөлләр белән тутырылган. Бу гөлләрне караучы аерым

кеше юк, моны һәрбер шәкерт күз карасы шикелле саклый, чистарта, су сибә.

Дәресханәдә – 4–5 метр озынлыгында пыялалы нәфис шкаф. Бу шкаф шәкертләр өчен кирәкле, кыйммәтле китаплар белән тутырылган. Шкаф ачык – сакчысы юк. Теләгән шәкерт шкафтан китапны ала, укый, яңадан матур итеп урынына куя. Шкаф бервакытта да үз тәртибен бозмый.

Дәресханәнең идәненә яшел сукно җәелгән, аның өстендә – икеөч тәбәнәк өстәл. Башка җиһаз юк.

Ашханәгә водопровод[1] куелган, зурлы-кечкенәле ике плитә янып тора. Аш плитәдә пешерелә. Монда казан һәм аш самавырлары юк. Ике зур кубта тәүлек буенча су кайнап тора. Ике кубның берсе чәй өчен, икенчесе юыныр өчен билгеләнгән.

Бу чорда Казан мәдрәсәләрендә имтихан-сынаулар зур тантана белән үткәрелә иде. Өстен чыгучыларга, яхшы укучыларга киемсалым шикелле кыйммәтле бүләкләр бирелә. Сынау вакытларында дистәләрчә кызыгучы кешеләр катнаша ала.

***Мәдрәсәләрнең идарәсе һәм агымдагы чыгышлары***

Мәдрәсәләрнең хуҗасы мулла-хәзрәт булгач, аның идарәсе дә хәзрәт кулында булуы үз-үзеннән билгеле. Хәзрәт ни әйтсә, мәдрәсәдә шул закон, моңарга каршы чыгарга беркемнең дә хакы юк. Хәзрәтнең рөхсәте белән шәкерт кабул ителә, хәзрәтнең рөхсәте белән шәкерт мәдрәсәне ташлый – мулла була. Шулай ук хәзрәтнең әйтүе белән, тәүфикъсыз шәкертләр мәдрәсәдән куыла.

Шәкертнең йөреш-торышы, кием-салымы хәзрәт теләгәнчә булырга тиеш. Шәкертнең үзенә генә түгел, хәзрәт шәкертнең ата-аналарына да зур һәм көчле тәэсир ясый ала. Мәдрәсәдә тәртип саклауда «Бәддога» һәм «Хәер догасы» (явыз дога-каргыш һәм изге дога) бик зур роль уйный иде. Шәкерт бәддогадан куркып, тетрәп тора.

Югарыда, мәдрәсәләр байлар тарафыннан салына, дигән идек. Шулай булгач, мәдрәсәләрнең ягу-яктырту һәм ремонт шикелле агымдагы чыгымнары да байлар тарафыннан тотыла.

Кайбер кечкенәрәк мәдрәсәнең агымдагы чыгымнары мәчет белән бер суммадан тотылу гадәтләре дә бар иде.

Кайбер мәдрәсәләр берничә бай тарафыннан яки гомуми мәхәллә-приход халкы исеменнән тәрбия ителүчән була. Мондый очракларда, мәдрәсәнең материаль ягын идарә итәр өчен, берничә

[1] Водопровод – сuүткәргеч.

кеше мөтәвәлли-попечитель булып сайлана һәм болар мәдрәсәнең материаль хәлен күзәтеп тора.

Гадәттә, борынгы мәдрәсәләрдә ремонтны бик сирәк ясыйлар. Биналар һәм мичләр бозылып, эшкә яраксыз хәлгә килгәч кенә, ремонт ясала. Шунлыктан мәдрәсәләрдә төзек нәрсә бик аз була.

***Мәдрәсәгә һәм шәкертләргә халыкның-массаның карашы***

Аерым кешеләрне исәпкә алмаганда, халык мәдрәсәгә дә, шәкертләргә дә яхшы күз белән карый иде. Халык алдында мәдрәсә изге йорт булып тора. Шул караштa булган халык шәкертләрне «җир фәрештәсе» дип йөртә.

Мәдрәсәләрдәге кайбер шәкертләр халык теләмәгән юлларга да кергәлиләр. Мондый хәлләр мәдрәсә һәм шәкертләргә начар караш тудырган чаклар да булгалый. Андый вакыйгалар мәдрәсәләрнең соңгы вакытларында шактый көчәйгән иде.

Шәкертләрнең зур күпчелеге намаз укый, руза тота, мәчеткә йөри. Шәкертләрнең күбесе мәчеттә Коръән дә укый, дин кушканча йөри, кием-салымын дин кагыйдәләренә нигезли һәм халыкның дини гореф-гадәтләрен үтәүдә булышлык итә. Шәкерт, укып чыккач, «ил имамы» була, иң кимендә мөәзин була. Бу – бик яхшы эш. Шәкертләрнең бу яклары дин белән чолганып алынган булганга, халыкка җитә кала.

Мәдрәсәдәге шәкертләрнең 70–80 проценты мулла баласы, 10–15 проценты бай һәм мөәзин балалары булып, моннан калган аз гына бер өлеше мәдрәсәгә кыйммәте бик кечкенә булган «мужик» балалары була. Мәдрәсәнең төп элементы булган мулла, мөәзин малайлары (шуларга ияреп, бай малайлары да) крестьян-«мужик», кустарь һәм мещан балаларына бик түбән күз белән карыйлар. Мәдрәсәдә болар «мажик, мыштым, байчура» дип йөртеләләр. Шәкертләр тарафыннан бу төр шәкертләргә карата бәетләр чыгарыла, анекдотлар оештырыла һәм хикәяләр сөйләнә. Кыскасы, көлә алган кадәр көләләр иде.

Мәдрәсәләрдәге кайбер шәкертләр ярамас хәрәкәтләрдә булалар. Шуның аркасында мәдрәсә һәм шәкертләргә начар караш башланган чаклар да булгалый, дигән идек. Шәкертләр тарафыннан эшләнә торган бу эшләргә мисал итеп, түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

Шәкертләр хатын-кызларга гыйшык хатлары язалар. Бу хатлар ата-аналары яки ирләре кулына төшә. Асраулар янына яки аулак өйләргә баралар. Монда да кеше күзенә чалыналар. Мулла, мөдәррис

хатын-кызлары белән элемтә тоткан шәкертләр дә мәдрәсә тарихында юк түгел.

Зур шәһәрдәге кайбер шәкертләр ресторан, сырахanә һәм начар йортларга баргалыйлар. Бу урыннарда халык белән очрашалар. Шуның аркасында халыкта шәкертләргә каршы ачу катнаш нәфрәт кузгала. Шулай итеп, халыкта шәкертләргә каршы бер-беренә капма-каршы ике фикер туа. Шәкерт яхшы да, шәкерт начар да. Халык, бер яктан, шәкерткә «җир фәрештәсе» ди, икенче яктан, «күмер карагы», «үпкә», «хәерче» һәм «саилче»[1] ди.

Гадәттә, шәһәрләрдә байлар шәкертләргә «кулыннан эш килми торган кеше» дип карыйлар, приказчиклары яки эшчеләре берәр эштә ялкаулык күрсәтсәләр, яки ялгыш эшләсәләр, аларга «һәй хәлфә» яки «шәкерт» диләр, «шәкертлегеңә барасың» диләр. Димәк, «хәлфә» һәм «шәкерт» тәгъбире «пешмәгән» дигән сүз урынында кулланыла.

Мәдрәсәдәге килешсез күренешләрнең йөздән берсен булса да күрсәтеп китми мөмкин түгел. Ләкин мәдрәсәләрдә эшләнә торган мондый вакыйгаларны язар өчен, томнар кирәк булыр иде.

1. Мәдрәсә кечкенә генә бер шәһәрдә оештырылган. Бу шәһәрдә руслар да һәм татарлар да бар.

Габделхәй бик тырыш. Ул – хәзер пишкадәм. Шушы елларда хәлфәлеккә күтәрелергә тора. Шуңа карамастан Габделхәй җиңел табигатьле, уйнак. Ул нәфселәмерне[2] дә ярата, хатын-кызлар белән очрашуны да кире какмый. Кыскасы, ул бернәрсәдән дә тартынмый.

Шәһәр урамнарының берсендә Анна Ивановна тора. Анна Ивановнаны шәһәрдә белмәгән кеше сирәк. Анна Ивановна фатирында нәфселәмер дә, сыра да, әче бал да булып тора. Тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә бар, ул кабул итә. Бу фатирда качып утырырга да, ачык утырырга да мөмкинлек бар. Шунлыктан бу фатирга шәкертләр дә баргалыйлар. Анна Ивановнада асрала торган кызлар шәкертләргә аерым мәхәббәтле күренәләр. Анна Ивановнаның шушы яхшы яклары Габделхәйнең уйнак күңелен бөтенләйгә шул якка тартты.

Тахил шәрабе[3] тирәсендә генә очрашканда, Габделхәйнең эше шома үтте. Ләкин кызлар Габделхәй ягына әйләнгәч, аңа көнче егетләр килеп бастылар. Дистәләрчә рус егетләре Габделхәйдән үч алырга әзерләнделәр.

---

[1] Саилче – теләнче.
[2] Нәфселәмерне – асылын, бу очракта: шәраб, исерткеч эчемлек.
[3] Тахил шәрабе – исерткеч эчемлек.

Шул уңай белән Габделхәйгә дистәләрчә һөҗүм булды. Ләкин Габделхәй берүче бу һөҗүмнәрдә җиңеп чыкты. Дөрес, Габделхәйнең күгәреп, канга батып кайткан көннәре дә булды. Бу аңа тәэсир итмәде – Анна Ивановнаны ташламады.

Шулай тырыша торгач, дошманнар Габделхәйгә баш иярга мәҗбүр булдылар. Аңа хөрмәт йөзеннән «кулак, сугыш чукмары» исемен бирделәр. Габделхәйнең Ивановна фатирында алган исеме элек мәдрәсәгә кайтты, аннан шәһәргә таралды. Шулай итеп, Габделхәй катлаулы исемгә ия булды – Кулак Габделхәе булды.

Берничә елдан соң Кулак Габделхәй Уралда «М» шәһәренә мулла булды. Ил имамы хезмәтен үти башлады. Мәдрәсә шәкертләре Кулак Габделхәйне бик озак истә тоттылар.

2. Мәдрәсәнең Сабир исемле бер хәлфәсе дамелла асравы Сабирага гыйшык тота. Сабир Сабирага он җибәрә. Сабира онны, токмачка әйләндереп, кире Сабирга кайтара. Ике кардәш арасында булган он җибәреп, токмач кабул итүдә кемнең эше бар. Малай онны илтә, токмачны барып ала. Он астындагы хатны, токмач арасындагы җавапны малай сизми. Берничә ел дәвамында Сабир дамелланың бик күп кабартма-сумсасын ашады, чиккән чолгаулар сарды, саурыйлы читекләр[1] киде.

«Без капчыкта ятмый», диләр. Көннәрнең берендә Сабираның игезәк баласы булды – Хәсән белән Хөсәен дөньяга килде. Халык арасында шау-шу башланды. Имеш, балаларның атасы – Сабир хәлфә. Балаларны хәзрәтнең үзенә тагучылар да сизелде, күрше авылның Салават ахун дип әйтүчеләр дә бар иде. Никадәр эзләсәләр дә, Хәсән белән Хөсәеннең аталары табылмады, балалар атасыз үсте.

3. Зариф – Җиһанша хәлфәнең яраткан шәкерте. Моны барлык шәкерт тә белә: «Иркәли соң Җиһанша хәлфә Зарифны», – диләр. Җиһанша хәлфә ни өчен яратмасын Зарифны?! «Ике көндә бер кабартма, сумса китерә дә, кечатна сәдакасын эре көмештән генә җибәрә», – диләр шәкертләр. Дөресе дә шулай. Җиһаншаның алдыннан кабартма, каймак өзелми, токмач киселгән. Кайвакыт токмачка дип җибәргән он пилмәнгә әйләнеп кайта. Керләр юылган, тукмакланган – тагын нәрсә кирәк.

Беркөн кичкә таба Зариф мәдрәсәгә килгән. Үзе тиргә баткан: «Хәлфә, – ди, – мин сине Коръән укырга чакырырга килдем, – ди, – ястү намазыннан соң, үзең белеп барырсың», – ди.

[1] Саурыйлы читек – атның бот тиресеннән эшкәртелгән күннән тегелгән читек.

Ястү намазын бик зарыгып көтеп алган Җиһанша хәлфә хәзер инде Зарифларда утыра. Вакыт көз көне, Җиһанша хәлфә ни өчендер кунакта бик озак булды. Таң атканда гына яланаяк (читек-кәвешен калдырып) бүлмә тәрәзәсеннән кайтып керә. Шәкертләр бу хәлне белсәләр дә, эндәшмәделәр, бернәрсә булмаган шикелле калдылар.

Җиһанша хәлфә икенче көнне читек-кәвешен хәзрәттән барып алды һәм шул көннән башлап, Зариф Җиһанша хәлфә тирәсендә күренмәс булды.

4. Нәҗар, Габбас һәм Садри укулары белән дә, үткенлекләре белән дә мәдрәсәдә дан тоталар. Шуның өстенә бу өч шәкерт яхшы ашыйлар, купшы киенәләр дә.

Бу шәкертләр үз гомерләрендә Мәкәрҗәдә булганнары да һәм Мәкәрҗәгә барырга уйлаганнары да юк. Шуңа карамастан мәдрәсәдә бу өч шәкерткә «Мәкәрҗә фәрештәсе» дип йөртәләр. Кайсы Габбас? «Мәкәрҗә фәрештәсе Габбас» диләр.

Мәкәрҗә вакыты булу уңае белән шәһәрдәге кайбер магазиннар ябылган, кайберләре эшчеләрен азайткан, сәүдәсен кыскарткан. Шәһәрдә байлар, сәүдәгәрләр бик аз күренә.

Шәһәрдә хәзер икенче төрле җанлылык. Байбикәләр Мәкәрҗә бәйрәме итәләр, Мәкәрҗә аулагы уздыралар. Капкадан башын күрсәтергә куркып торган байбикәләр ирекка чыкканнар. Аларны хәзер урамда да, бакчада да күреп була.

Н. хаҗи сәүдәне Мәкәрҗәгә күчергән. Магазинда бер генә приказчик калган. Моңа йорт-җиргә күз-колак булырга кушылган.

Бүген Н. хаҗи өендә кызу пешеренү бара. Бүген бу йортта Мәкәрҗә аулагы булачак. Аулакта күп кеше булмый, Гайшәбикә дә, туганым җиңги булачак һәм болар кунып китәчәкләр.

– Туганым җиңгинең кызы үзе генә калган икән, син хәзер аларга бар, иртәгә сәгать җиделәрдә кайтырсың, – диде байбикә үзенең асравына.

Төнге сәгать берләр иде. Н. хаҗи искәрмәстән өйгә кайтып төште. Кинәт эшләнгән бу эштән өйдәгеләр шашып калдылар. Нәҗар белән Габбас качып өлгерде, Садри кулга төште.

Иртәгесен бу хәбәр бөтен шәһәргә таралды. Нәҗар, Габбас, Садрига әллә нәрсә булмады, имеш-мимеш белән бетте. Ләкин байбикә, Гайшәбикә һәм туганым җиңги өйләреннән дә, ирләреннән дә яздылар.

*Нәҗар, Габбас һәм Садри киткәннәр шәфәкъ баткач,*
*Закир хәзрәт шәкерте, дип, җавап биргәннәр тоткач,*

дип башланган бу җыр шушы уңай белән чыгарылган иде.

5. Рябой Сабирның түгәрәк кенә белеме бар. Мәдрәсәдә үзен яхшылык белән таныткан. Аның беркем белән эше юк, кычкырышмый да, талашмый да. Сабирның бер ярамаган ягы булса, ул да – аның төннәрдә югалып торуы. Сабирның җәйгән урыны ике көнгә бер буш тора. Кайбер вакытларда җәйгән урын Сабирны атналарча күрми. Бүлмәдәшләр моны белсәләр дә фаш итмиләр. Урындашлары аны һәр кич, һәр төн искә төшерәләр: «Сабир бүген дә дачада кунамы?» – диләр.

Сабир көн аралаш тәтәйләрдә куна. Сораган кешеләргә, дачада булдым, ди.

Шәһәргә һәр көн диярлек муллалар килеп тора. Болар туп-туры Сабирга төшәләр. Болар Сабирсыз тәтәйләргә бармыйлар. Сабир монда юлбашчылык итә. Сабир мондагы кызларны да, хуҗаларны да баш бармагы шикелле белә.

Көннәрнең берендә Сабирның мәдрәсәдә ризыгы киселә, ул бер авылга мулла була. Сабирга төрле җирдән кыз димлиләр, ләкин Сабир аларның берсе белән дә кызыксынмый, тәтәйләрдәге «Кенәри Хәдичә»не артык күрә. «Кенәри Хәдичә» «Хәдичә абыстай»га әйләнә.

Хәдичә абыстай озак еллар тора алмый, үлә. Мәрхүмәне күп еллар сагынып сөйлиләр. Сабир шул ук йорттан тагын берсен – «Кулукчы Нәфисә»не алып кайта. Ләкин Нәфисә остабикәне халык яратып бетми, һаман Хәдичә абыстайны сагыналар.

6. Җиңгәчи 1905 елда хаҗга барды. Мәккә, Мәдинәне тәваф итте[1], изге җирләрне күрде. Җиңгәчи хаҗ юлында меңнәрчә акча калдырды, корбаннар чалды, сәдакалар таратты. Гөнаһсыз кызларның намусларын сатып, бичараларның каннарын эчеп табылган акчаның харам икәнен җиңгәчи бик яхшы белә иде. Акчаны хәләлләп бирүче дә, хаҗга озатучы да Нәби хәлфә булды. Нәби хәлфә җиңгәчидән ашаган икмәкнең каршылыгын кайтарды.

### *Хәзрәт һәм байларның мәдрәсәдәге рольләре*

Хәзрәт мәдрәсә фәннәре белән яхшы таныш булса, холкы, табигате белән үзен халыкка яхшы күрсәтә алса, шуның белән бергә, Сәмәрканд, Бохара шикелле чит илләрдән укып та кайткан булса, мәдрәсәнең даны еракларга таралучан була. Мондый мәдрәсәләргә шәкертләр күп туплана һәм бик еraклардан киләләр. Мондый мәдрәсәнең шәкертләре яхшы урыннарга урнаша, бай авылларга,

[1] Тәваф итү – изге урында булу, аның тирәли әйләнү.

шәһәрләргә мулла була. Моңа мисал итеп, Курса һәм Кышкар мәдрәсәсен күрсәтеп була. Курсави вакытында Курса мәдрәсәсенең даны бик еракларга тарала. Кышкар мәдрәсәсенең даны соңгы вакытларга кадәр саклана.

Казан, Мәрҗани мәдрәсәсендә Россиянең һәр тарафыннан шәкертләр бар иде. Һәм шулай ук Мәрҗани мәдрәсәсендә укып чыккан муллаларны бик ерак җирләрдә күрергә мөмкин.

Дан казанырлык сыйфатларга ия булмаган хәзрәтләрнең мәдрәсәләре дә данлыклы була алмый иде. Мондый мәдрәсәләрдә шәкерт аз була һәм вак була. Шуның белән бергә, шәкертләр билгеле районнардан гына, якын тирәләрдән генә туплаланалар. Мондый мәдрәсәләргә мисал итеп, Сембер мәдрәсәсен күрсәтергә мөмкин. Бу мәдрәсәгә шәкертләр ике урыннан гына киләләр: Мәләкәс әйләнәсеннән һәм Сембер өязенең кайбер почмакларыннан.

Материаль яктан яхшы тәэмин ителгән мәктәпләрдә шәкертләр күп булучан иде. Мәдрәсәләрнең материаль яхшы тәэмин ителүләре шул мәхәлләнең байлары, сәүдәгәрләре белән бәйле иде. Мәхәлләдә байлар күп булса, шуның өстенә алар киң куллы да булсалар, мәдрәсәнең тәэминаты яхшы була. Байлар мәдрәсәләрне тәэмин итәләр дигәч тә, шәкертләрнең өс-башлары, кием-салымнары бар да байларча була дип аңлашылмасын. Мәдрәсә тарихында мондый эш булганы юк. Байлар мәдрәсәне ягалар, яктырталар, агымдагы ремонтларны эшлиләр, техник хезмәтчеләр бирәләр, зәкят һәм сәдака кертәләр.

Һәрбер байның үзенә караган характеры бар, үзенә күрә дөньяга карашы, динне аңлавы бар. Шул яктан чыгып, һәр бай мәдрәсәгә үзенчә тәэсир итәргә тели, шәкертләрне үзенчә әйләндерергә уйлый.

Гали бай шәкертләрнең сакал-мыекларына бәйләнә, Вәли бай кием-салымнан разый түгел, Гани бай шәкертләрнең намазын, мәчеткә йөрүләрен тикшерә.

Гадәттә, байларның мәдрәсәгә тәэсирләре мәдрәсәнең хәзрәтенә бәйле. Хәзрәт йомшак булса, байларның мәдрәсә һәм шәкертләргә тәэсире зур һәм көчле була. Хәзрәт каты куллы булса, байлар мәдрәсә һәм шәкертләр белән уйный алмый.

Хәзрәтнең йомшаклыгыннан файдаланып, байлар мәдрәсәнең эчке эшләрен кулга алалар, мәдрәсә һәм шәкертләрне үзләре теләгәнчә әйләндерәләр иде. Мондый очракларда хәзрәтләр дәрес укытучы сыйфатында гына кала.

Казанда «Халидия» мәдрәсәсе байлар күп булган мәхәлләдә оештырылган иде. Хәзрәтләрнең йомшаклыгыннан файдаланып, мәдрәсәгә Айтуганов хуҗа була. Шул уңай белән мәдрәсә, электәге «Халидия» исемен югалтып, «Айтуганов мәдрәсәсе» исемен алган.

Айтуганов дөньяга карашта башка байлардан шактый аерылып тора. Ул рус мәктәпләре белән таныш. Айтуганов мәдрәсәне тышкы яктан да, эчке яктан да икенче бер тәртипкә салырга тырышты. Мәдрәсәне культуралы төскә салды, еллык сынау системасы кертте, мәдрәсәне башка байлар тәэсиренә бирмәде.

Мәхәлләнең зур байларыннан Салих Гобәйдуллин – тагын башкарак тип. Аныңча, шәкерт теләсә нинди булсын, аның анда эше юк, тик шәкертләр Гобәйдуллинны хөрмәт итсеннәр, Гобәйдуллинга тәлинкә тотсыннар, аны мактасыннар. Гобәйдуллин килгәндә, шәкертләр аяк өстендә торсыннар, аннан элек кермәсеннәр, аңардан элек чыкмасыннар.

Гобәйдуллин улларына хәлфә сайлаганда да тәлинкә тоту мәсьәләсен үзәк мәсьәлә итеп куйды. Мәдрәсәнең риячы, тәлинкә тотучы хәлфәсен сайлады. Салих бай Гобәйдуллинның ике улы Айтуганов мәдрәсәсендә укый. Малайларның өс-башлары бөтен, тамаклары тук. Байның йорты мәдрәсәдән 2–3 кенә квартал булуга карамастан, малайлар мәдрәсәгә ат белән киләләр, мәдрәсәдән ат белән китәләр, җәяү җиргә басмыйлар. Малайлар хәлфә алдында бик иркәләр һәм назлылар. Хәлфә дә аларның бер алдына, бер артларына төшә, иркәли, юмалый. Шуның белән бергә, бу ике бай малае мәдрәсәдәге шәкертләргә дә, хәлфәләргә дә бик түбән күз белән карыйлар. Коридорда шаяралар, кычкыралар, башка балалардан көләләр, аларны рәнҗетәләр. Бу эш бай малайларының сөеп, яратып эшләгән эшләре була.

Мәдрәсәдәге Зыя хәлфә бу малайларны озак вакытлар өйрәнә, тикшерә, ара-тирә боларга кисәтүләр ясый, тәртипкә чакыра. Малайларга яхшылык итәргә тели. Ләкин уңышлы нәтиҗә бирми, Зыя хәлфәнең үзенә каршы да килешсез мөгамәләдә булалар.

Малайларның тәртипсезлекләреннән кәефе төшкән Зыя хәлфә Газиз Гобәйдуллинга «чиертергә» мәҗбүр була. Зур капризлы бай малайлары Зыяга ачу итеп, елап, җитмәсә тагын җәяү өйләренә кайтып китәләр.

Озак та үтми, шул уңай белән карт хәзрәт мәдрәсәгә килә. Туптуры Зыя хәлфәнең бүлмәсенә керә, кычкырып, түбәндәге хатны укый: «Менә мулла Зыя, син мине нинди хәлгә куйдың, харап иттең», – ди.

*«Сабир хәзрәткә.*

*Сәлам соңында кәлам будыр. Бу көн мәдрәсәгездә Зыя дигән бер шәкерт, минем улларымны кыйнап, мәсхәрә итеп, җәяү кайтарып җибәргән. Мин бу мәсхәрәлекне күтәрә алмыйм. Сүзем бер булыр. Шушы Зыяны, бу көннән башлап, мәдрәсәдән куып җибәрергә тиешсез. Әгәр кумасагыз, мин мәдрәсәгә бирә торган ярдәмемне туктатам һәм үзем сезнең мәхәлләгездән башка мәхәлләгә күчәм. ... сәгатькә кадәр җавап бирелсен».*

Күз яше тулган хәзрәт Зыядан хәзер үк мәдрәсәдән чыгып китүен таләп итә, югыйсә мәдрәсәнең дә, хәзрәтнең үзенең дә хәле начар булачагын сөйли: «Мин синнән меңнән мең бәхил, – ди. – Хәзер кит, – ди. – Мин сиңа һәрвакыт догачы булырмын», – ди. Ялына-ялвара. Зыя хәлфә хәзрәткә, әлбәттә, каршы тора алмый, чыгарга риза була. Тик постоялый дворга барып, авылдашларын табып килгәнчә, әйберләренең бүлмәдә торуын гына хәзрәттән үтенә.

Хәзрәт Зыяга хәер-фатиха бирә һәм ул, тынычланып, мәдрәсәдән чыгып китә.

Берәр сәгатьтән соң көтмәгәндә мәдрәсәгә Айтуганов килеп керә һәм карт хәзрәтне мәдрәсәгә чакыра. Озак та үтми, агарган йөз белән карт хәзрәт мәдрәсәгә керә, Айтугановның борчулы чыраен күреп, «Әгәр Зыяны мәдрәсәдән чыгарга мәҗбүр итәсең икән, менә йозак, хәзер мәдрәсәне биклим дә алам, мәдрәсә минеке», – ди. Хәзрәт ут белән су арасында кала: «Алай булгач, мулла Зыя мәдрәсәдә калыр инде», – ди.

Берничә көннән соң Гобәйдуллин Зәңгәр мәчет мәхәлләсеннән башка мәхәлләгә күчеп китә. Хәлфәгә шәһәрдән өй сатып ала, аны шунда күчерә. Малайларны хәлфә шул өйдә укыта башлый. Газизнең капризы аркасында, хәлфә йортлы-җирле булып кала.

***Борынгы мәдрәсәләрнең эчке тәртип кагыйдәләре***

Борынгы мәдрәсәнең эчке тәртип кагыйдәләре бар иде. Кайбер мәдрәсәләрдә бу кагыйдәләр язылып, стеналарга да тагылган була. Кайбер мәдрәсәләрдә бу кагыйдәләр язып куелмый, фәкать телдән телгә, укучыдан укучыга күчеп кенә йөри. Шулай булса да, шәкертләр бу кагыйдәләрне бик ачык беләләр. Бу кагыйдәләр шәкертләрдә инстинкт рәвешендә урнашкан була иде.

Мәдрәсәләрдәге эчке тәртип кагыйдәләренең дин һәм дини гореф-гадәтләр белән бәйләнгән бер өлеше бөтен мәдрәсәләр арасында бертөсле уртак була. Ә моннан калган һәм һәр мәдрәсәнең үзенә

хас булган бер өлеше, мәдрәсәләрнең шартларына карап, үзгәрүчән була, мәдрәсә хәленә карап үзгәрә. Үрнәк өчен түбәндә бер мәдрәсәнең эчке тәртип кагыйдәләрен күрсәтәбез. Эчке тәртип кагыйдәсен мәдрәсә телендә «тәнзыймат» диләр.

***Тәнзыймат.***

*Әгузү билләһи миннәш-шәйтанир-ражиим. Бисмилләһир-рәхмани-р рәхиим. Әлхәмдү лилләһи раббил-галәмин. Вәл-гакыйбәте лил-мәттәкыйн, вәссаләте вәссәламе галә хайри хәлкыйһи Мөхәммәдин вә әсхабиһи әҗмәгыйн. Әмма бәгъдә, бу әфкярел-гыйбат мелла Габделгани бине мелла Габдулла ахун хәзрәтнең кәнди ишарәләре илә шушы тәнзыйматны язмакка җөрьәт әйләдем. Вә мин-Аллаһи әт-тәүфикъ.*

*1. Мәдрәсәбездәге тәлямиз гавамнарыбыз[1] Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгаләнең әмере шәрифләренә муафикъ вә пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең ризалыгына мотабикъ[2] сиярәттә әһле ислам вә әһле тарикать юлына мөмасил булсалар[3] иде.*

*2. Тәлямизның мөраһикъ[4] һәм дә балигъ улганнары саляты хәмсәне[5] калдырмагайлар, җәмәгать белән мәчеттә әда кылулары[6] мәҗбүридер. Мөраһикълар мәчеткә дәва кылсалар, бик хуштыр. Мәдрәсәдә әда килсәләр дә, җәзага дучар кылынмаслар. Сабыйларны намазга өндәү һәрбер тәлямизнең зиммәсенә[7] ваҗиб вә лаземдер.*

*3. Һәрбер мөраһикъ һәм балигъ булган тәлямиз сабак илән сәгать 5 тә ятак урыннарыннан торып, тәһарәт алгайлар һәм әдәп илән мәчеткә баргайлар.*

*4. Сабак намаздан кайткач, тәгамланганнан соңра, хәлфә вә остазлар үз шәкертләренә дәрес бирә башларлар. Пишкадәмнәр дәрес уку вә дәрес өйрәтү илән мәшгуль булырлар. Шәһәр балалары өйлә намазына кадәр сабак укырлар, моннан соң өйләренә китәрләр.*

*5. Өйлә намазыннан соң җәмгы тәлямиз тәгамланырлар вә кирәкле эшләре илән шәһәргә чыгарлар. Кардәш-ыругларга зиярәт кылырлар. Моннан соң хәлфәләр үзләренең шәкертләренә сабак бирү белән мәшгуль булырлар.*

*6. Һәр көн сәгать сигездә ахун хәзрәт дәрескә керәчәктер. Кич ахшам намазыннан соң яшь хәзрәт дәрескә керәчәктер.*

[1] Тәлямиз гавамнарыбыз – шәкерт халкы.
[2] Мотабикъ – туры килгән.
[3] Мөмасил – охшаган, бу очракта: лаеклы.
[4] Мөраһикъ – яшүсмер.
[5] Саляты хәмсә – биш вакыт намаз.
[6] Әда кылу – үтәү, башкару.
[7] Зиммәсенә – вазифасына, өстенә.

*7. Мәдрәсәдә шәригате исламиягә могайир[1] эшләр һәм сирка[2] катгый мәнгы кылынадыр, гакесе[3] хәлдә шәригать боерганга җәза бирeләчәктер.*

*8. Мәдрәсә эчендәге яумия[4] мәсьәләләр олуг казый Гали бине Вәли тарафыннан хәл вә иҗраэ кылыначактыр[5]. Казый хәл кыла алмаган олуг мәсьәләләрне ахун хәзрәт биззат[6] үзләре хәл кылачаклардыр.*

*9. Мәдрәсәдәге барлык тәлямиз үзләреннән олуг булганнарга хөрмәт вә итагать күрсәтерләр.*

*10. Кечекләр олугларны аяк өстендә торып каршы алмаклары тиештер, ягъни олуглар хөҗрәләргә кергәндә кечекләр аяк өсте торып каршы алырлар. Озатканда һакәза[7] аяк өсте озатырлар.*

*11. Кечекләр олугларны берәр нәрсә сораганда тез чүгеп, ягъни тезләнгән хәлдә сорарлар.*

*12. Тәлямиз әлбисәләрен[8] әһле ислам хуш күргәнчә тектерерләр. Шапка кию, зөннар[9] баглау зәнадика[10] гадәте булганлыгы өчен, каты рәвештә мәнгы кылынадыр. Әлгаязе биллаһ.*

*13. Хәтем вә хәмелгә бару һәм могтәбәран вә әһле һиммәткә мәҗлескә бару казый күрсәткән тәртипкә муафикъ дәрәҗәсенә мөнасиб тарикы илә улыр.*

*14. Мәдрәсәгә әһле ингам[11] һәм ихсан тарафыннан булган сәдакаи хәйрия вә зәкят тәлямизнең дәрәҗәсенә игътибар илә тәкъсим ителер[12]. Тәммәт.[13]*

*Кәминә[14] имам хатыйп вә мөдәррис Габделгани бине мелла Габдулла.*

Мәдрәсәләрнең эчке тәртип кагыйдәләре буенча торыш, ашау-эчү мәсьәләләре түбәндәгечә башкарыла иде:

1. Укучылар билгеле бүлмәләргә беркетелгән булалар. Бүлмәләрдәге шәкертләр саны, аларның уку дәрәҗәләренә яки сыйнфый хәлләренә карап була. Уку дәрәҗәләре югары булган шәкертләрнең

[1] Могайир – бу урында: каршы.
[2] Сирка – урлау.
[3] Гакесе – киресе.
[4] Яумия – көндәлек.
[5] Иҗраэ кылыначак – башкарылачак.
[6] Биззат – турыдан-туры үзе.
[7] Һакәза – шулай ук.
[8] Әлбисәләрен – киемнәрен.
[9] Зөннар – билбау.
[10] Зәнадика – динсезләр.
[11] Әһле ингам – иганәчеләр.
[12] Тәкъсим ителер – бүленер.
[13] Тәммәт – тәмам.
[14] Кәминә – кечелекле, түбәнчелекле.

бүлмәләре иркен була. Бүлмәдә кеше саны аз була. Уку дәрәҗәләре түбән булган саен, аларның бүлмәләре тыгыз була, кеше саны күп була. Мәдрәсәгә яңа килгән һәм мәдрәсәдә кардәш-ыруы булмаган яки дәрәҗә алып өлгермәгән шәкертләр, бигрәк тә «мужик малайлары» дип йөртелә торган крестьян балалары бүлмәләргә тыңгычлап тутырыла иде.

Күп мәдрәсәләрдә «мужик малайлары», килү белән үк, бүлмәләргә куелмыйлар, җәмәгать сәкеләрендә генә калдырылалар.

Кайбер мәдрәсәләрдә биналар уку дәрәҗәсенә карап билгеләнгән була. Шунлыктан мондый мәдрәсәләрдә шәкертләр дәрәҗә күтәрелү аркасында бер бинадан икенче бинага яки аскы каттан өске катка күчеп йөриләр иде. Гадәттә, зур шәһәрләрдәге мәдрәсәләрнең күпчелеге ике катлы була. Мондый биналарның өске катлары уку дәрәҗәләре күтәренке булган шәкертләр өчен, аскы катлары түбән дәрәҗәле укучылар өчен билгеләнә иде.

Уку дәрәҗәләре башкаларга караганда югары булган шәкертләр шул бүлмәнең төп хуҗасы булып саналалар. Алар бүлмәдәге тәбәнәк өстәлләрнең ике ягына урнаша. Болар бүлмәдә күп булмыйлар, ике-өч, бик күп булса, 3–4 кеше булалар һәм бүлмәдә болар әйткән сүз закон санала иде. Бүлмәдәге башка шәкертләр бу кешеләргә бүлеп беркетелгән була.

Уку дәрәҗәләре түбән булган шәкертләр бүлмәдә була торган барлык көндәлек хезмәтне берсүзсез үтиләр. Бу гадәт – мәдрәсәләрдә тарих буенча килгән бер хәл. Бу хәл мәдрәсәдә төп законга әйләнгән. Моны бозарга беркемнең дә хакы юк. Әлеге закон буенча, бүлмәдәге пишкадәмнәр барлык хезмәтләрдән читтә торалар. Болар фәкать хезмәтнең барышын һәм үтәлешен генә күзәтәләр.

Бүлмәләрдә көндәлек хезмәт бик күп табыла. Аларның кайберләре түбәндә күрсәтелә: 1) бүлмәләрне чистарту-тазарту, 2) идән себерү, 3) идән юу, 4) самавыр кайнату, 5) аш пешерү, 6) табак-савытлар чистарту, 7) пишкадәмнәр йомышы белән базарга һәм кибетләргә чыгу һ. б.

Бүлмәдәге көндәлек эшне үтәүче шәкертләрнең уку дәрәҗәләре төрлечә булганга, аларга йөкләнгән эш тә бик төрле була. Болар үзләренә нинди эш йөкләнгәнен бик ачык беләләр. Гадәттә, эшнең авыр дәрәҗәсе түбән булганнарга, бигрәк тә яклаучысы булмаган йомшак шәкертләр өстенә төшүчән була иде.

Мәдрәсәләрнең бу законы буенча, җилкәсендә зур авырлыклар алып барган яшь шәкерт бер-ике елдан соң эшнең авыр бер

өлешеннән котыла. Дүрт-биш елдан соң өстәлгә хуҗа булып, башкаларга үзе эш куша башлый. «Мән хадәмә хадимә» («Кем хезмәт итсә, үзе дә хезмәт күрер») дип, башкаларга боерык бирү хокукына ия була.

Борынгы мәдрәсә шәкертләре ашау-эчү һәм кием-салым мәсьәләсендә турыдан-туры беркем тарафыннан да тәэмин ителмәде. Мәдрәсә тарихы моны күргәне юк. Мәдрәсә шәкертләренең зур күпчелеге ата-аналары яки кардәш-ырулары тарафыннан тәэмин ителделәр. Шәкертләрнең бу рәвешле тәэмин ителүләре тәрбиячеләрнең материаль хәлләренә яки аларның һиммәтләренә[1] карап була иде. Шуның нәтиҗәсендә кайбер шәкертләр бал-май эчендә йөзсәләр, кайберләре исә икмәк белән суга канәгатьләнә иде. Шуның белән бергә, кайбер шәкертләрнең тәрбиячеләре булмый, болар тәрбиядән читкә ыргытылган булалар иде. Мондый шәкертләр, корыда калган балык шикелле, арлы-бирле сикергәләргә, төрле түбәнчелекләргә төшәргә мәҗбүр булалар.

Гадәттә, шәкертләрнең тәрбиячеләре тарафыннан тәэмин ителүләре ике төрле юл белән була: 1) акча белән яки 2) азык белән. Ерак җирләрдән килгән шәкертләр ярдәмне акчалата алалар. Мәдрәсәгә якын-тирәдән булган шәкертләр ярдәмне азыклата алалар иде. Азык әйберләре ит-май, он-ярма, икмәк-күмәч шикелле нәрсәләрдән тора.

Мәдрәсәләрдә көндәлек ашау-эчү эшләре коллектив рәвештә оештырыла. Коллектив әгъзаларының саны бүлмәдәге шәкертләрнең күплек һәм азлыгына карый. Гадәттә, чәй коллективлары даими булса да, аш коллективлары даими була алмый. Һәр бүлмәгә берничә чәй коллективлары туры килә.

Һәрбер шәкерт көн саен аш пешерә алмаганга, даими аш коллективлары бик сирәк була. Күп вакыт аш коллектив әгъзалары берничә бүлмәдәге шәкертләрдән төзелә. Гадәттә, аш коллективлары аш материалларының сыйфатына нигезләнеп оештырыла. Өйдән килгән әйберләрдән аш пешерү коллективлары һәм аш өчен кирәк-ярак сатып алып пешерү коллективлары беренче чиратта коллектив әгъзалары кулларында булган ит, он, ярма, бәрәңге шикелле продуктларны биреп кушылалар. Икенче очракта акча салышалар.

---

[1] Һиммәтләренә – тырышлыкларына.

Кайбер мәдрәсәләрдә 5–6 кардәш бергә торалар. Мондый кардәшләр үзләренә бер коллектив булып яшиләр, башка шәкертләргә мохтаҗ да булмыйлар.

Борынгы мәдрәсәләрнең берендә бер атадан сигез туган укыйлар. Бере-береннән яшь булган бу шәкертләрне аш табынында күрүчеләр шактый уйга калалар иде.

Гадәттә, аш коллективлары 5–6 кешедән тора. Кайбер очракларда 7–8 кешедән дә була.

Аш бәясе ашның сыйфатына карап була. Аш арзан ясалса, кеше башына 3–4 тиенгә, кыйммәтрәк ясалса, 5–6 тиенгә төшә. Аш бер генә төрле – токмач яки өйрә була. Шуның белән бергә, түләнгән акчага кеше башына 2–3 тәлинкә тәмле аш туры килә. Итсез, коры аш пешерү гадәте булмый.

Алты әгъзалы коллектив өчен якынча аш сметасы:

1. Ит – 1,5 кадак. 100 г. нан – 15 тиен.
2. Он – 2 кадак. 200 г. нан – 10 тиен.
3. Әшья. 1 порция – 5 тиен.
Барлыгы 30 тиен.

Димәк, бу смета белән пешерелгән аш кеше башына 5 тиенгә төшә.

Борынгы мәдрәсәләрдә ашлар бер генә төрдән әзерләнә. Шуның белән бергә, ашның төре дә күп булмый. Зур игътибар белән пешерелгәнгә, шәкерт ашы шактый тәмле һәм туклыклы була. Шәкерт салмасы мәдрәсәдә генә түгел, шәһәр кешеләре арасында да дан казанган иде.

Шәкертләр итнең бик симезен һәм билдәмәсен сайлыйлар. Итне бик вак итеп турап салалар. Сөякләрне кеше саен туры китерергә тырышалар.

Шәкертләр күбесенчә салма пешерәләр. Өйрә, токмач, ботка һәм пилмән шикелле ашлар бик сирәк пешерелә. Ботка ярлылар ашы санала иде.

Шәкертләр ашка яшелчәнең төрлесен салырга тырышалар. Шунлыктан шәкерт ашында суган, кәбестә, кишер, шалкан, чөгендер һәм башка шуның шикелле әйберләр була.

Рамазанда ашның сыйфаты яхшыландырыла һәм ит, бәрәңге ашала, ите, бәрәңгесе сәхәргә калдырыла. Кайбер мәдрәсәләрдә калган ашны башкаларга сату гадәте дә була. Калган ашны аш пешерә алмаган шәкертләргә дә ашаталар. Калдык аш ашаучы шәкерт

табык-савытлар тазартуны үзенең бурычы дип белә. Мәдрәсәләрдә калдык аш белән файдаланучылар шактый була.

Коллектив эчендә пылау бик сирәк пешерелә. Аны, гадәттә, кунаклар булганда яки аерым мәҗлесләр-хозурлар уңае белән генә пешерәләр. Шәкертнең пылавы да данлыклы була.

Шәкертләр арасында бавырсак, коймак, талкан, әлбә шикелле әйберләр дә пешерелә.

Шәһәр мәдрәсәләре янында мәдрәсәгә караган продукт кибете була торган иде. Бу кибетләр шәкерткә кирәкле әйберләр сату шарты белән аерым кешеләргә арендага бирелә.

Шарт нигезендә, кибетче аш өчен кирәк әйберләрнең һәр төрен тотарга мәҗбүр.

Кибеттә булган ит, он, ярма шикелле ашның төп материаллары үз исемнәре белән атала һәм һәркайсы аерым сатыла. Ашның өстәмә материалы булган тоз, борыч, бәрәңге һәм яшелчәләр үз исемнәре белән аталмыйлар да һәм аерым сатылмыйлар да. Бу материалның барына бердән «әшья», диләр. Әшья, гадәттә, порция белән сатыла. Бер порция әшьяда 5–6 кеше ашына җитәрлек тоз, борыч, бәрәңге һәм төрле яшелчәләр була. Шәкерт, 15 тиен акчасын тотып, кибеткә керә дә: «Гыйльман абзый, биш тиенлек ит, дүрт тиенлек он, бер тиенлек әшья», – ди. Гыйльман кибетче шул сүзгә карата эш күрә.

Мәдрәсә кибетләре ышанычлы шәкертләргә әйберне бурычка да бирә, моның өчен аерым дәфтәр тота.

Шәкертләр дә, хәлфәләр дә аш һәм чәй урынын идәнгә әзерлиләр. Бер-ике генә кеше булганда аш-су урыны тәбәнәк шәкерт өстәленә дә әзерләнә.

Зур шәһәрләрдә аш материалларын һәм әшьяны күпләп алып кую гадәте юк иде. Авылларда һәм кечкенә шәһәрләрдә продуктны базар арасына җитәрлек итеп әзерлиләр.

Чәй коллективларында су белән чәй генә уртак була, ашау әйберләрен һәркем аерым куллана. Шунлыктан бер үк коллектив табынында төрле шәкерт төрле нәрсә ашый. Берәүләр май белән күмәч ашаса, икенчеләре коры икмәк белән канәгатьләнә, өченчеләренең икмәге дә булмый, алар, шәкертчә әйткәндә, «суган суырып утыралар...».

Шәкертләр арасында тәэминат мәсьәләсе төрлечә була. Чынлыкта аларның ашау-эчүләре дә сыйфат ягыннан төрлечә була. Шәкертләр арасында ашау-эчү мәсьәләсендә бик авыр хәлдә булганнары да күп очрый.

Көнкүреше шактый яхшы булган бер мулла карт хатыннан булган өч баласын мәдрәсәгә китереп ташлаган. Шул көннән бирле, ничә еллар үтүгә карамастан, өч балага өч тиен дә акча һәм өч грамм продукт та җибәрмәгән. Киресенчә, ул балаларның үзләреннән көтә иде: «Хәлфә булырлар да, үземә ярдәм итәрләр», – ди иде.

Бу өч туганның берсе – зурысы – хәлфә булып алганга кадәр бик күп еллар үтте. Өч кардәш җылы ашны айга бер мәртәбә дә күрмәделәр һәм көнгә бер мәртәбә туйганчы кара икмәк тә ашый алмадылар.

Нурәхмәтне атасы ерак бер мәдрәсәгә олактырган. Нурәхмәт мәдрәсәдә күп еллар уздырган, хәлфә дәрәҗәсенә җиткән. Ләкин шул дәвер эчендә ул атасыннан фәкать 20 тиен акча ала алган. Менә шундый хәлдә шәкертләр мәдрәсәдә шактый булалар.

Кайбер мәдрәсәләрдә, бигрәк тә зуррак шәһәрләрдә шәкертләр өчен өстәмә тәэминат чыганаклары була торган иде. Мондый «төшем»не шәкерт телендә «хасыйл» һәм «хасыйлат» дип йөртәләр. Хасыйлаты күп булган мәдрәсәгә шәкертләр күп җыелучан була.

Мәдрәсә шәкертләре хасыйлатның нәрсәдән килгәнен бик ачык беләләр, хәзерге совет яшүсмерләренә бу мәсьәлә караңгы булып тора. Шунлыктан бу мәсьәлә өстендә аерым тукталып китсәк, файдасыз булмас дип уйлыйм. Хасыйлат түбәндәгеләрдән тора:

1. Хәтем: мәдрәсә булган мәхәлләдә берәр кеше авырый. Авыруны Коръән чыгып өшкерергә *(авыруның йөзенә өрү, тын җибәрүне өшкерү диләр)* дип табыла. Мәхәлләдә берәр хәлле кеше үлә, аның җаны Аллаһка юнәлгәндә Коръән чыгарга, Коръән тутырырга кирәк табыла *(Коръәнне башыннан ахырына кадәр укып чыгуны халык телендә «Коръән чыгу» яки «Коръән тутыру» диләр)*. Коръәнне тиз чыгарга кирәк булганда, 10 кеше яки 30 кеше укый, моны шәкерт телендә «хәтем», диләр.

Халык шәкертләрне «җир фәрештәсе» дип таный, шәкертләр яхшы кеше дип санала. Шәкертләр Коръәнне дә яхшы һәм туры итеп укыйлар. Шуның белән бергә, Коръән укыган өчен түләнгән акча шәкертләрнең – җир фәрештәләренең кирәк-яракларына тотыла. Менә шул якларны уйлап, кайда гына хәтем булмасын, анда шәкертләр чакырыла.

Хәтем, әлбәттә, көн саен булып тормый. Ул – очраклы бер эш. Күп булса, атнага бер яки айга бер-ике туры килә.

Мәдрәсәләрдә казый тарафыннан төзелгән хәтем исемлеге була һәм бу исемлеккә фәкать пишкадәмнәр – зур шәкертләр генә

кертелгән. Хәтемгә шәкертләр шул исемлек буенча баралар һәм шәкертләр үз нәүбәтләрен алдан белеп торалар. Хәтем хакы төрлечә була. Ул хәтем чыгартучының хәленә һәм һиммәтенә карый. Хәтем хакы сорап алынмый. Гадәттә, хәтем чыккан өчен 15 тиеннән алып, бер яки ике сумга кадәр бирәләр. Бер-ике сумлык хәтемнәр бик сирәк туры килә.

2. Хәмел. Мәхәлләдә берәр кеше үлә, үлекне юганда һәм кабергә илткәндә дә начар кулларга тоттырырга ярамый. Шунлыктан мәдрәсә булган урыннарда үлекне зиярәткә илтү шәкертләргә тапшырыла. Шәкертләр бу хезмәтне «хәмел» диләр. Гарәпчә «күтәрү» дигән мәгънәгә ия. Менә шундый вакытларда «җир фәрештәләре» йөкче һәм арзанлы транспортка әйләнә.

Хәмелгә гадәттә 15–20 шәкерт катнаша. Хәмел хакы да сатулашып алынмый, хуҗа үзе белеп бирә. Бу да хуҗаның хәленә һәм һиммәтенә карап була. Үленең гаиләдә тоткан урыны да игътибарга алына. Уртача алганда, хәмел хакы, «җир фәрештәсе»нең бәхетенә каршы, 5–10 сум да булып куйган чаклары була. Ләкин мондый хәл шәкертнең гомеренә бер генә килә, шәкерт исә моны гомере буе сөйли.

Үлеккә ясалган хәтем белән хәмелнең тагын бер яхшы һәм файдалы ягы бар. Ул да булса, хәтемчеләр дә, хәмелчеләр дә үленең өчесенә һәм җидесенә ашка-мәҗлескә чакырылалар. Монда «җир фәрештәләре» тагын бер кабат 10–15 тиен эләктерәләр. Шуның өстенә туйганчы ашыйлар да.

3. Мәҗлес һәм ифтар. Мәҗлес, гади кунак сыйлау. Монда дусиш була да, мулла, мөәзин була. Ифтар – рамазанда руза тоткан вакытларда Аллаһ ризалыгы өчен ясала торган дини сыйлау. Бу мәҗлескә гадәттә мулла-мөәзин, галим-голяма, гомумән, дини һәм рухани кешеләр, шул җөмләдән шәкертләр дә чакырыла. Чакырылган кешеләрнең саны шул ук хуҗаның теләгенә карап була. Бу мәҗлесләрнең һәр икесендә дә мулла Коръән укый, Коръәннән соң сәдака бирелә. Гадәттә, шәкертләргә бирелә торган сәдаканың чамасы 15–20 тиен яки 40–50 тиен була.

4. Зәкят. Ислам шәригате буенча, йорт-җир, эш коралларыннан тыш, оборотта-сәүдәдә йөри торган суммасы булган (иң азы 200 сум) мөселман – бай, ул елда бер мәртәбә зәкят бирергә мәҗбүр. Шәригать буенча зәкят сумманың кырык сумга бер сум исәбеннән билгеләнгән. Шул ук шәригать күрсәтүе буенча зәкятны акчалата бирергә дә мөмкин. Нинди дә булса берәр төрле әйбер-товар белән дә бирергә мөмкин. Монда хуҗага тулы ирек бирелә. Зәкят кабул булсын өчен,

аны ярлы кешеләргә, ярлыларның да яхшыларына, дини йолаларны үти торганнарына бирергә кирәк. Җир фәрештәләре нәкъ менә шул шартларга, шәригать күрсәткән кешеләргә туры килә. Шәригатьнең ачык күрсәтүенә карамастан һәм бай булуларына игътибар итмәстән, зәкятны мулла-мөәзиннәр дә бик яратып алалар. Муллалар бу турыда үз файдаларына шәригатьчә юл да тапканнар: «Гыйлем әһленең бусагасы алтын булса да, зәкят, сәдака алырга хаклары бар», – диләр. Зәкятны акчалата бирергә дә рөхсәт ителә, әйберләтә дә бирергә мөмкин. Әйберләтә биргәндә, байлар өчен файдалырак була. Бу юл белән зәкят биргәндә үтмәгән маллардан да котылып була, малны кыйбатрак бәядән куеп та була.

Гадәттә мәдрәсәгә кертелә торган зәкятлар – ит, май, он-ярма, чәй-шикәр һәм мануфактура шикелле әйберләр була. Димәк, натура белән үтәлгән була.

Мәдрәсәгә кергән зәкят шәкертләр арасында тигез бүленми, уку дәрәҗәсенә карап, пропорциональ бүленә. Шунлыктан зәкят бүлгәндә пишкадәмнәр капчыклап алсалар, малайларга исә граммлап кына тия.

5. Сәдака. Борынгы мәдрәсәләрнең һәрберсендә диярлек өшкерү-төкерү шикелле эшләр белән шөгыльләнә торган шәкертләр дә була. Андыйлар авыруларны дини юл белән дарулаган булып, надан халыкның акчаларын алалар. Менә бу дарулау, бөти язу, тәлинкә язу, өшкерү өчен бирелгән акчаны «сәдака» диләр. Сәдаканың, әлбәттә, башка төрләре дә була иде.

6. Мәкәрҗә төшеме. Шәкертләр пешергән ашның тәмле булуы һәм аны байларның сөеп-яратып ашаулары югарыда язылды. Шушы яктан чыгып булса кирәк, татар байлары, Мәкәрҗәгә сәүдә белән барганда, үзләре белән бер-ике шәкерт алып баралар. Ай ярым, ике ай чамасы дәвам иткән бу ярминкә сезонында шәкерт байларның түбәндәге хезмәтләрен башкара:

1) Байларның торакларын юа, себерә, сөртә.
2) Урын-җирләрен җыя һәм җәя.
3) Өс-баш һәм аяк киемнәрен тазарта.
4) Барлык йомышларын үти.
5) Торакның гомуми ашханәсендә байлар өчен аш пешерә, чәй һәм кофе әзерли.
6) Табак-савытларын җыя һәм чистарта.
7) Кирәк булганда кибеткә яки канторга чыгып ярдәм итә һәм башка бик күп төрле хезмәтләр үти.

Шәкерт шушы хезмәтен билгеле бер хезмәт хакы нигезендә үтәми. Шәкертнең хезмәт хакы торактагы кешеләрнең күплек-азлыгына һәм торакның төп хуҗасы булган байның һиммәтенә карап була. Гадәттә, бу хезмәте өчен шәкерт, аз булганда, 25–30 сум, уртача булганда 60–70 сум, күп булганда 100–125 сум акча ала. Төшемнең күплеге шәкертнең үз осталыгына да бәйләнгән. Шәкерт күндәм булса, үзен яраттыра белсә, төшем күбрәк була ала.

Шәкертләрнең Мәкәрҗәдәге хезмәтләре бик җиңел түгел иде. 10–15 кеше тора торган торакны чистарту, себерү, урын җирләрен карау, 10–15 кешегә көндәлек продуктны җилкәдә ташу, табак-савытларны юу җиңел эш түгел. Шуның белән бергә, җәйнең кызу көннәрендә җәһәннәм шикелле кызу ашханәдә көн буенча эш итүне җиңел эш дип кем әйтә алыр?!

Бай гади һәм йомшак табигатьле булса, бик зур бәхет. Әгәр дорфа, усал табигатьле булса, күтәрә алмаслык каты таләпләр куйса, җитешмәгән җирләреңне битеңә бәреп торса, «алай ярамый, болай да ярамый» дисә, «җир фәрештәсе» өчен бик куанычлы булмый.

Төшем һәм килер белән кызыксынган һәрбер шәкерт тә, Мәкәрҗәгә бару теләге булса да, хезмәтнең авыр якларын күз алдына китереп, Мәкәрҗәгә барырга батырчылык итә алмый. Моның өчен әрсезлек һәм зур чыдамлык кирәк, ә бу сыйфатлар һәр шәкерттә булмый.

Мәкәрҗәгә шәһәр шәкертләре күбрәк баручан иде. Шуның белән бергә, Мәкәрҗәгә баручы шәкертләрнең 50–60% ы – Казан шәкертләре. Төркестан, Себер байлары да Казаннан шәкерт алалар иде.

7. Казакъка чыгу. Кыргыз-казакъ халкы кышны бик авыр шартларда үткәрә иде. Кышлау дип йөртелә торган землянка тыгыз, юеш, караңгы була. Малның саны бар, ләкин азык аз. Шунлыктан мал тәрбиясе чиктән тыш авыр. Менә шундый авыр шартлар эчендә кыш көнендә бала укыту казакъның башына да керә алмый. Шуннан чыгып, казакъ-кыргыз халкы балаларын җәйләүгә чыккач, җәй көнендә укыта иде. Бу хәл кыргыз-казакъ өчен үзгәрми торган гадәт булып калган.

Очсыз-кырыйсыз сахрага, киң далага сибелгән кыргыз-казакъ халкы өчен далада мәктәп торгызып, балаларны бергә туплап укыту мөмкин түгел иде. Шунлыктан бер я берничә гаилә берләшеп, бер укытучы тоталар. Казакъ-кыргыз халкы арасындагы шушы хезмәтне тарих буенча татар шәкертләре үтәп килде. Кыргыз-казакъ халкы мондый сезонлы укытучыларны «мулдәк» (мулла әкә, мулла абзый) дип йөртәләр. Киң казакъ сахрасында җәй көннәрендә мон-

дый мулдәкләрне меңнәрчә табып була. Мулдәге булмаган борынгы татар мәдрәсәләре бик аз булгандыр.

Яз кереп, су юллары ачылгач, мәдрәсәләрдә дәресләр тукталыр вакыт җитү белән, шәкертләр казакъ арасына чыгу хәзерлеген күрә башлыйлар, май ахырларында алар кыргыз-казакъ җирендә була.

Казакъ арасында чыккан мулдәкләрнең хезмәтләре түбәндәгеләрдән тора иде:

• Хуҗа кеше, гаилә башы динле-намазган булса, шәкерт, имам торып, биш вакыт намаз укыту.

• Йортка-өйгә килгән кунакларның теләге буенча Коръән уку. Казакъ гадәтенчә, көн саен кунак килми калмый. Көнгә берничә дә булып куя. Үле чыккан йортка көн дә дистәләрчә кеше килә. Боларның һәркайсына Коръән укырга кирәк.

• Казакъның дини сорауларына җавап һәм фәтва биреп тору.

• Указлы муллалары ерак булу сәбәпле, бу авылга килә алмаса, туган балага исем кушу, үле күмү һ. б.

• Хуҗа һәм аның якыннарының балаларын укыту.

• Хуҗа кашында тиешле игътибарны казана алмаган мулдәкләр мал караучы һәм көтүчегә булышлык күрсәтәләр.

Мулдәкнең шушы хезмәтләре өчен хуҗа шәкертне бушлай ашата. Сөт, кымыз эчертә, көз көнендә шәкертне бүләкли. Бүләк акча белән дә, хайван белән дә, ашлык белән дә булырга мөмкин. Ничек кенә булмасын, шәкерт үзенең хезмәте өчен аз дигәндә 20–30 сум, күп булганда 80–90 сум төшем ала.

8. Сату итү. Кулында азмы-күпме акчасы булган шәкертләрнең кайберләре, бигрәк тә шәһәр шәкертләре җәйге сәүдә башлыйлар. Мондый шәкертләрнең сәүдә төрләре итеп түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

• Күтәреп йөрү яки почмакларда утыру юлы белән яшелчә яки җиләк-җимеш сату.

• Вокзал һәм пристаньнарда ашау-эчү нәрсәләре, галантерия яки уенчык шикелле товарлар белән кәрзин сәүдәсе.

• Базар һәм ярминкәләргә йөреп, беренче кирәк әйберләр белән кулдан сату итү.

• Бай сәүдәгәрләргә, җәйге сезонга ялланып, базар һәм ярминкәләргә йөрү.

• Урам һәм бакчаларда суыткыч эчемлекләр белән сату итү һ. б.

Сату-алу эшен башкару өчен, кулда сумма булу гына җитеп бетми. Моның өчен сәүдә юлларын белергә һәм товар сыйфатларын

аңларга кирәк. Шунлыктан шәкертләр арасында сәүдә итүчеләр күп булмый иде. Шул рәвешле кечкенә генә сәүдә башлап, ахырында зур капиталистка әйләнеп киткән шәкертләрне татар байлары арасында бик күп табарга мөмкин. Казан шәһәрендәге зур сәүдәгәрләрдән нәшрият һәм типография хуҗалары Мөхәммәдҗан һәм Шәрифҗан Кәримовлар[1] – шундый сәүдәгәрләрдән.

9. Җәй көннәрендә производствода эшләү. Кайбер мәдрәсә шәкертләре җәй көннәрендә производствога, фабрик-заводларга һәм складларга эшкә керәләр. Шуның белән үзләренә кышкы тормыш өчен хәзерлек күрәләр. Соңгы елларда Сембер, Самара һәм Мәләкәс шикелле шәһәр шәкертләре производство эшенә өйрәнгәннәр иде.

Борынгы мәдрәсә шәкертләреннән күпчелек, югарыда саналган авырлыкларны һәм мәсхәрәлекләрне күргәннән соң гына, үзләренең теләкләренә ирешәләр.

***Борынгы мәдрәсәдә кием мәсьәләсе***

Борынгы мәдрәсәләрдә кием-салымга караш хәзерге шикелле ирекле булган дип уйланмасын. Әле күптән түгел генә – Бөек Октябрь революциясе алдыннан гына «Хөсәения», «Галия» һәм «Мөхәммәдия» шикелле реформа кертелгән мәдрәсәләрдә дә Европача киемнәр кулланырга мөмкин булмый. Бу мәдрәсәләрнең шәкертләренә генә түгел, хәлфәләренә дә казаки кию мәҗбүри иде.

Мәдрәсәләрдә бик начар тәэмин ителүчеләр белән беррәттән, бик нык тәэмин ителгән шәкертләр дә шактый була иде. Гадәттә, кайбер начар тәэмин ителгән шәкертләр яхшы тәэмин ителгән шәкертләр тирәсенә җыелышучан була – бай балаларының көндәлек эшләрен үтиләр, сабакларын өйрәтәләр, язуларын язалар. Шуның бәрабәренә фәкыйрь шәкертләр тамакларын туйдыралар.

Борынгы мәдрәсә шәкертләренең киемнәре артык дәрәҗәдә гади иде. Шәкертләрнең кием-салым мәсьәләләренә хәзрәтләр дә, хәлфәләр дә, халык массасы да контрольлек итә. Киемгә нинди дә булса яңалык кертү зур шау-шуларга сәбәп була.

Бик борынгы вакытларда шәкертләр кызыл кештәкле[2] ак җирлекле күлмәк кияләр иде. Күлмәккә төймә һәм сәдәп урынына тасма кулланыла. Соңгы вакытларда кызыл кештәкле күлмәк ташланып,

[1] Кәримовларның китап сату фирмасы – татар китапчылыгы тарихында беренче китап сату ширкәте. «Бертуган Кәримовларның сәүдә йорты» исемендә Казанда 1897 елда ачыла.

[2] Кештәкле – кыек (күлмәк итәге турында).

аның урынына үрнәкле ситсы күлмәк, читек яки оектан гыйбарәт була торган иде. Күлмәк ак әйбердән (бүз, киндер шикелле) яки ак җирлеккә вак бизәк төшкән ситсыдан эшләнә. Күлмәк киң, озын итеп әзерләнә. Ыштан озын һәм киң итеп тегелә, ул киң төпле, ычкыр үткәзер өчен бөрмәле була.

*Ап-ак күлмәк, ак штан – егетләрнең сөйгәне,*
*Мыек борып, каш сикертсә, шул – кызларның сөйгәне.*

Хәлфәләр һәм пишкадәмнәр аякларына зәңгәр савырлы[1] читек кияләр, пәскадәмнәр оек яки оекбаш кияләр, ыштан балагын читек яки оекка тыгалар, шулай ук салындырып та кияләр.

*Читек*. Ясалган материалына карап, ике төрле була: опойка – сарык читек, кәҗүл – кәҗә читек. Кәҗүл читек, кыйммәт булганга күрә, күп шәкерткә насыйп булмый.

*Егетләрне без сөябез,*
*Кәҗүл читек кигәнен.*
*Кәҗүл читек киеп килеп,*
*«Сине сөям» дигәнен.* (Халык җыры)

Хәлфәләр, пишкадәмнәр, гомумән, зур һәм хәлле шәкертләр күлмәк өстеннән камзул (җиңсез казаки) кия торганнар иде. Камзул җиңсез һәм ярты җиңле буларак ике төрле була. Кыска җиңле камзулны тәкъварак суфилар һәм картрак шәкертләр кияләр, җиңсез камзулны яшь һәм купшырак шәкертләр кия. Камзул металл тимер төймәле һәм йомры була. Ак пыяла төймә кызыл төймәгә караганда мода ягыннан өстен санала. Яланбаш йөрү – зур гаеп. Шунлыктан шәкертләр һәрвакыт кәләпүш белән йөриләр. Яланбаш хәлдә ашау яки берәр нәрсә эчү бик зур кабахәтлектән санала.

Шәкертләрнең җәйге өске киемнәре: казаки, җилән, чикмән һәм чапан. Мисыр һәм Төркия тәэсирендә булса кирәк, соңгы вакытларда шәкертләр арасында җөббә[2] кию дә башлана. Соңгы вакытларда чыккан кайтарма якалы җиләнне купшы шәкертләр генә кияләр. Хәтфә якалы трико җилән шәкертләр арасында аерым мактаулы кием була.

Шәкертләр арасында баш киеме бер генә, ул да булса, бүрек иде. Бүрек күптөрле була, ак та, надар[3] бүрек, кама һәм камчат бүрек, бәрән яки каракүл бүрек. Иң күп кулланылганы сукнодан эшләнгән,

[1] Савыр – атның янбашы, савырлы – атның шул урындагы тиресеннән тегелгән.
[2] Җөббә – ефәк тукымадан тегелгән халат, җилән яки чапан.
[3] Надар – данадар – каракүлдән эшләнгән яссы түбәле бүрек.

тире эчле «тәвәккәл бүрек» иде. Вак һәм ярлы шәкертләр тәвәккәл бүрек кулланалар.

Шәкертләрнең кышкы киемнәре бишмәт, тун, толып, киез итек, киез катадан гыйбарәт була.

Җилән, чапан һәм җөббә дини мәрасимнәрдә кия торган киемнәрдән санала.

Борынгы мәдрәсәләрдә чалбар кию гаеп санала. Шунлыктан мәдрәсәләрдә чалбар кию шәкертләр арасында озак вакытлар зур гаеп булып торды. Шәкертләр арасында чалбар кию шәригатькә туры килми торган эш дип каралды.

Мәдрәсә эчендә, мәчет тирәсендә шәкертләр күн һәм агач башмак, юкә башмак, юкә галош кулланалар. Пишкадәмнәр бу аяк киемен шәһәр урамнарында да кия торганнар иде.

**Мостафа һәм чалбар.**

Мостафа төскә дә матур. Матур һәм көяз киенергә дә ярата. Шуның белән бергә, Мостафа мәдрәсәдән читтә торучы кешеләр белән дә элемтә тота, чит кешеләргә йөри. Кая барганын, кемнәр белән очрашканын беркемгә дә әйтми, сөйләми. Мостафаның мондый табигате башкаларга бик ошап бетми. Шунлыктан аңа чит хәлфә шәкертләре дә чит күз белән карыйлар иде.

Көннәрнең берендә мәдрәсәдә «Мостафаның чалбары бар икән» дигән сүз таралды. Башта колактан колакка сер булып йөргән бу хәбәр бара-тора Мостафага һөҗүм төсен алды. Имештер, беркөн Мостафаны урамда чалбар белән күргәннәр. Имештер, Мостафа чалбарын шәһәрдә үзенең якыннарында саклый. Мәдрәсәдән чалбарсыз чыкса да, урамда чалбар белән йөри. Хәбәрләр көчәйгәннән-көчәя, сүз зурайганнан-зурая, ахырында Мостафаның чалбары мәдрәсәдә үк сакланганлыгы сөйләнә башлый. Озак та үтми, Мостафаның чалбары булганы, аның урамда чалбар белән йөргәнлеге хәзрәткә-дамеллага җиткезелә.

Көннәрнең берендә хәзрәт Мостафаны чакырып үгетли, халык арасында йөз карасы булып йөрмәскә, мәдрәсәнең исемен сатмаска киңәш бирә. Мөселманнарга чалбар киюнең дөрес булмаганын бик күп дәлилләр белән төшендерә. Хәзрәт бу мәсьәлә турында берничә мәртәбә кузгатса да, Мостафадан рәтле җавап ала алмый, ул һаман «минем чалбарым юк» кына ди.

Беркөн, дәресханәдә шаулап дәрес барганда, ишектән бер шәкерт кереп, Мостафаның чалбар белән кайтып кергәнен хәбәр итә. Аллаһ

белән ант итеп, хәбәрнең дөреслеген ныгыта. Хәзрәткә дә, дәрестә утыручы шәкертләргә дә бу хәбәр яшен тизлеге белән тәэсир итә.

Мостафага бүлмәсенә керергә дә юл куелмады, ул туп-туры хәзрәт алдына китереп бастырылды. Хәзрәт сүзне озайтып, матурлап тормады, шунда ук чалбарын салырга кушты. Мостафа хәзрәткә каршы килмәде һәм килергә дә мөмкин түгел иде. Мостафаның чалбарын салганын шәкертләр зур кызыксыну белән карап тордылар. Озак үтмәде – мәсьәлә ачылды. Көтелгән әйбер чалбар булып чыкмады, җиңен балак итеп киелгән җилән булып чыкты. Моны күргән хәзрәт: «Ахмак, сафсата, әһле исламны тәшвишкә төшереп йөрисең», – диде. Башка сүз әйтә алмады.

Борынгы мәдрәсәдә чалбарга нәфрәт күзе белән каралса да, тормыш мәшәкатьләре үз эзеннән барырга мәҗбүр итте. Җилән җиңеннән башланган чалбар шәкертләр арасында кирәкле һәм файдалы бер кием булып танылды. Хәзер инде халык чалбарның үзенә түгел, аның балагына бәйләнә башлады. Чалбарның балагы тездән аз гына түбән, тубыктан шактый югары булса, бу чалбар шәригать чалбары булып танылды. Мәдрәсәләрдә озын балаклы чалбарларга салкын кан белән карала алмады. Мондый чалбарлар шәригать һәм әхлакка капма-каршы куелды. Чалбар киючеләргә «Озын балак» исеме бирелде. «Озын балак»ларга халыкның карашы түбән иде. Шуңа карамастан чалбар балагы тик тормады, һаман үсте, озынайды. Мәдрәсәләрдә чалбарны «брюки» дип атаучылар күренә башлады. Бу вакыт инде XIX йөзнең ахырлары иде.

Мәдрәсә тарихында чалбардан башка киемнәр дә: камзул, бишмәт, казакилар да шактый зур шау-шуларга тарыды. Бишмәт, казаки үз тарихында шактый зур үзгәрешләргә очрады. Элек бишмәт бавы күн төймәгә, күн төймә йомры тояк яки пыяла төймәгә әйләнде. Озак та үтмәде, йомры төймәләр сәдәп төймәләр белән алмаштырылды. Менә шушы үзгәрешләр берсе дә тәнкыйтьсез, шау-шусыз кала алмадылар.

Бишмәт, казакиларның билләре, чабулары һәм якалары да тик тормадылар, акрынлап үзгәрә бардылар. Бу үзгәреш тә тып-тын гына үтә алмады. Шау-шуга очрады. 1905 еллар тирәсендә генә әле мәдрәсәләрдә штиблетны «чирбик», «марҗа башмагы» дип атыйлар иде. Бу вакытларда марҗа башмагы белән йөрүгә халык бик өркеп карады.

XX йөз башларында мәдрәсәләрдә кием мәсьәләсе шактый йомшарды. Эшләпә, фуражка, зөннар-поястан башка барлык киемнәрне

кулланырга мөмкинлек ачылды. Шушы хәлдән файдаланып, мәдрәсәләрдә матур һәм җыйнак киенүче шәкертләрнең саны шактый арткан иде. Шушы чорда Казан шәкертләре арасында «Матур Бари», «Нури Хәбиб»ләр телләрдә дастан булып йөри иде. Дөрестән дә, Бари белән Нурилар матур һәм кеше кызыгырлык итеп киенәләр. Башта – бәзәнке (ясалма каракүл) бүрек. Өстә – сукно казаки. Казакиның кесәсе туры, якасы китекле, билсез һәм ак сәдәп төймәле. Муенда – ак (кәгазь) яка. Аякта – үкчәле читек, читек өстеннән чамбыр кәвеш. Тубыкка җитәрлек брюка-чалбар. Кулда – тимер таяк. Барилар һәм Нуриларның киенүләре менә шулай. Мондый киенүчеләр әле Казанда бармак белән санарлык иде.

***Мәдрәсәләрдә укучылар составы***

Татар халкының трмыш итү чыганагы булып авыл хуҗалыгы тора. Шуның белән бергә, кайбер авылларның кустарьчылыгы да була иде. Кустарьчылык, кыр эшләреннән бушагач, кыш көннәрендә эшләнә. Крестьян үзенең кыр эшендә дә, кустарьлык эшендә дә белемнең кирәклеген сизми иде. Шунлыктан крестьян баласы авыл мәктәбе белән канәгатьләнә. Баланы шәһәргә, мәдрәсәләргә җибәреп укыту белән кызыксынмый. Крестьяннар арасында: «Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала» дигән мәкаль хөкем сөрде. Шуның өчен мәдрәсәләрдә крестьян балалары бик аз була торган иде. Мәдрәсә гадәтенчә, мәдрәсәдә крестьян балаларына «мажик малае» яки турыдан-туры «мажик» дип йөртәләр. Мәдрәсәдә мажик балаларын шактый кимсетәләр. Крестьян балалары өчен мәдрәсәнең башлангыч еллары шактый күңелсез иде. Заманасынча төпле генә белемгә ия булган хәлфәләр дә, аталары крестьян булу аркасында, тиешле дәрәҗәгә күтәрелә алмадылар.

Борынгы мәдрәсәләрдә күпчелек мулла баласы, аннан кала мөәзин һәм бай балалары була, крестьян-мажик балалары бик аз иде. Мәдрәсә шәкертләрен чыгыш ягыннан процентка салып караганда түбәндәгечә күрергә була иде:

Мулла балалары 60–70%
Бай балалары 10–15%
Мөәзин балалары 5–10%
Крестьян балалары 4–5%.

Мәдрәсәләрдә мулла балалары белән мөәзин балалары арасында да тулы дуслык юк: мулла балалары үзләрен югары сыйныфтан дип саныйлар, мөәзин балаларын бу сыйныф тирәсенә җибәргә теләмиләр.

Мәдрәсәдәге бай балаларының зур күпчелеге мулла булу теләгендә булмаганга, бай балалары беркем тарафыннан да читләтелми.

Баласын мәдрәсәгә биргән һәрбер ата-ана баласының мулла булуы белән кызыксына, баласының мулла булуын тели. Шуннан чыгып, мәдрәсә шәкертләрен бүгеннең укучысы, иртәгенең мулласы дип аңларга туры килә.

Мәдрәсәдәге крестьян балаларына шәкертләр генә түгел, хәтта хәлфә һәм хәзрәтләр дә тулы бәя бирмиләр.

Мәдрәсә – мулла, мөәзин әзерли торган махсус уку йорты. Мәдрәсәнең төзелеше дә, программасы да һәм дәреслекләре дә шул максатка юнәлдерелгән. Мәдрәсә үз тарихында бик күп мулла, бик күп мөәзин чыгарды, шулай ук башка һөнәрдәге кешеләр дә тәрбияләде. Мәдрәсә тарихында бу төр сыйныфның да саны шактый зур. Боларны түбәндәгечә күрсәтергә була: приказчиклар, сәүдә доверенныйлары, сәүдәгәрләр, наширләр-издательләр, язучылар, редакторлар, техниклар-һөнәрчеләр, драматурглар, матбагачылар, боцман һәм капитаннар, ресторанчылар-буфетчылар, официантлар, ишан һәм карилар, өшкерүчеләр, чукынчык Гәрәйләр, бәдәлчеләр – сорыкортлар һ. б.

Мәдрәсәләрдә сау-сәламәт шәкертләр белән беррәттән, табигать тарафыннан җәберләнгән сукырлар, чулаклар һәм аяксызлар да була иде. Тумыштан гарип булып туган бу шәкертләр мәдрәсә телендә «суфи» дип аталалар. Суфисыз мәдрәсә бик аз булгандыр яки бөтенләй булмагандыр. Гадәттә, суфилар мәдрәсәдә үсәләр, мәдрәсәдә картаялар, мәдрәсәдә үләләр иде.

Мәдрәсә тарихында мәдрәсәдән чыгып гаилә төзегән, бала-чага иясе булган суфилар да шактый. Суфилар мәдрәсә программасындагы фәннәр белән кызыксынмыйлар, чөнки аларга алда бу фәннәрнең кирәге булмаячагы билгеле иде.

Гадәттә, суфилар Коръән ятлыйлар, догалар өйрәнәләр һәм мәкам (Коръән уку көе) үзләштерәләр.

Мәдрәсәдә суфиларга яхшы күз белән карала. Ятлау эшендә һәрбер шәкерт ярдәм итәргә тырыша. Шуның белән бергә, суфиларны халык та истән чыгармый: ашата, эчертә, киендерә. Шуның аркасында суфилар ач тормыйлар, ялангач булмыйлар.

Кайбер суфилар шәкертләр арасында да, халык арасында да киң авторитет белән файдаланалар. Мондый суфилар материаль яктан бик яхшы тәэмин ителәләр. Мәдрәсә тарихында суфилар турында шактый күп һәм төрле истәлекләр дә бар. Шушы йөзләгән истәлекләрнең берничәсен түбәндә язабыз.

**Ильяс суфиның өйләнүе.**

Ильяс суфи, ак сакаллы карт булуга карамастан, шушы көнгә кадәр өйләнмәгән. Ул үзенең бөтен гомерен өйләнү турында уйлап үткәргән. Аның әле дә өйләнү фикерен ташлаганы юк. Юк кына түгел, әле бу фикер анда көчәйгәннән-көчәя бара. Суфиның бу фикерен хәлфәләр дә, зуррак шәкертләр дә беләләр, аңлыйлар. Суфи үз бүлмәсендә аулак утырырга, аулак сөйләшергә ярата. Аулак сүзләрнең күбесе суфиның өйләнүе турында була. Бу турыдагы сүзне башлау суфиның самавыры кузгалуга сәбәп була. Шуның өчен суфи бүлмәсенә аулаклап кергән кеше сүзне өйләнүдән башлап җибәрә.

Ильяс суфи шәһәр кызларының күбесен белә. Аның көнделендә бөтен бер исемлек бар. Көнделдәге бу исемлекне суфи кабат-кабат тикшергән. Арадан кайберләренең астына сызып та куйган. Исемлеккә кергән Әмәй кызы Зөһрә турысына ике сызык куйган. Моны хәлфәләр дә, кайбер шәкертләр дә беләләр. Суфи белән аулак утырганда самавырны тизрәк кузгатасы килгән шәкерт сүзне Зөһрәдән башлап җибәрә.

Ильяс суфи Әмәйләрдә бик еш була. Моны ул зур бәхет саный. Бу бәхетнең киләчәктә тагын да киңәячәгенә чын-чыннан ышана.

Ильяс суфи – 50–55 яшендә, Зөһрә – 35–40 яшьләрендә кияү күрмәгән сазау кыз. Шушы яктан чыгып, суфи Зөһрәне үзенә тиң таба.

«Корчаңгы мулла, мөәзиннән укытсаң да шул савап, суфидан укытсаң да шул ук савап. Суфидан укытканда арзангарак төшә», – ди Әмәй карт. Шул план буенча суфига хәбәр ителә һәм ярты сәгатьтән соң суфи Әмәйләр түрендә була. Коръән укып, дога кылу белән сүз башлана. Сүздән сүз чыгып, мәдрәсә телгә алына. Мәдрәсә сере белән кызыксынган Әмәй карт суфига бер-бер артлы дистәләрчә сорау бирә. Зөһрә уе белән үзеннән югалган суфи Әмәй картка ярарга, шулай итеп, бер адым булса да, Зөһрәгә якынаерга тели. Шәкертләр һәм кайбер хәлфәләр турында үлчәүсезрәк сүзләр ычкындыра. Мәдрәсә һәм шәкертләргә якын торган Мостафа бай да өлешсез калмый. Аңа да шактый тел тидерәләр.

Суфиның бу сүзләре Әмәйләр гаиләсе аркылы бик тиз арада бөтен шәһәргә таралып өлгерә. Шәһәр эчендә чайкалган шушы гайбәт дулкыны хәлфәләргә дә, Мостафа байга да әйләнеп кайта.

Суфиның шушы хәрәкәте мәдрәсәдә шактый зур шау-шуга сәбәп була һәм аңа каршы начар караш тудыра. Нәтиҗәдә хәлфәләр суфидан үч алу фикеренә киләләр. Бу көнделсез хәлне суфи үзе дә белә,

ләкин хатасын кайтарып ала алмый. «Басылыр әле, онытылыр, бәлки», – дип, үзен тынычландырырга тырыша.

Бу шау-шу озак сузылмый, акрынлап, үзенең көчен киметә бара. Ахырында бөтенләй онытыла. Суфи белән шәкертләр арасында яңадан нормаль мөнәсәбәт башлана. Суфи бүлмәсендә яңадан аулак сөйләшүләр башлана. Яңадан самавырлар хәрәкәткә килә башлый. Ләкин бу тынычлану чын тынычлану булмый. Шәкертләрнең йөрәгендә суфидан ачу алу фикере бик нык урнашкан була. Тик бу ачу алуның формасы гына анык билгеләнеп җитә алмый.

Көннәрнең берендә һич көтмәгәндә суфиның бүлмәсенә бер бала кереп, суфига хат тапшыра: «Зөһрә апа бирде, – ди. – Иртәгә шушы вакытка җавабын алырга килермен», – ди дә чыгып китә. Озак сөйләшеп тормый. Бу хәл башта зур шатлык тудыра, ләкин шатлык озакка сузылмый, тирән уйлануга әйләнә. Хатны кемнән булса да берәүдән укытырга кирәк. Бу беренче сер сынату булачак. Хатка каршы җавап хаты кирәк. Бу тагын бер кат сер сынату булачак. Хатны укытмасаң, җавап язмасаң, кулга төшкән бәхет кошын ычкындыру булачак. Бу турыда суфи күп уйланды, күп эзләнде. Башка төрле чара таба алмады. Серне Мирза хәлфәгә чишәргә карар бирде. Мирза – борыны күтәренке зур хәлфә дә түгел, шуның белән бергә, сергә каты һәм күндәм егет.

Мирза хатны укыганда, суфи дөньядан югалып утырды. Хаты укылып беткәч кенә, суфи исенә килде. Хат Аллаһ исеме белән башлана. Суфига бик сагынып, бик саргаеп, бер күрергә зар-интизар булып, бик күптин-күп сәламнәр укый. Оялып кына булса да, суфи белән кавышырга исәбе барын белдерә, аннан тизлектә җавап көткәнлеген әйтә.

Чәйнең башында хат укылды, чәй арасында хатка анализ ясалды, чәй ахырында Зөһрәгә җавап хаты язылды.

Шушы көннән башлап, хат артыннан хат, җавап артыннан җавап өзелеп тормады. Бүләкләр җибәрелде, бүләкләр алынды. Кыш башында кузгалган бу вакыйга җәй уртасына кадәр сузылды.

Тәбәнәк өстәл өстенә бик мул итеп тәмле, татлы әйберләр тезелгән. Самавырдан боргаланып пар чыгып тора. Өстәл әйләнәсендә Мирзадан башка янәдән өч хәлфә утыра. Сүз суфины өйләндерү турында бара. Туй тәртипләре, туй расходлары турында сүз бара, фикерләр җиткерелә. Мәҗлеснең ахырында Зөһрәгә яучы җибәрергә һәм яучы булып баруны Мостафа байдан сорарга булалар. Мостафа

бай җавап кайтарганга кадәр, бу мәсьәләне сер итеп сакларга дип карар ителә.

Июль ахырлары, мәдрәсәдә шәкертләр бик аз калган. Барлыгы 15–20 шәкерт бар. Бу шәкертләрнең бары да туй турында беләләр. Мәсьәләне мәдрәсәдән читкә чыгарырга ярамаганлыгы һәрбер шәкерткә аңлатылган. Туйга кызу хәзерлек бара, суфи бүлмәсенә зур, тимерле сандык та кереп утыра, бирнә, бүләк өчен асыллар, йоннар әзерләнә. «Алдым-бирдем ясалганнан соң, бу нәрсәләр Әмәйләр өенә күчәчәк», – дип тора суфи. Алар урынына суфига кияү күлмәк-ыштаны, чиккән һәм укалы кәләпүш, хәтфә якалы чикмән, «Американский» читек һәм тәмле пешкән чәкчәк киләчәк.

Яучылык эшен Мостафа бай башкаргач, никах мәҗлесенә суфидан вәкил булып бару да Мостафага тапшырыла. Димәк, вәкил булып, туйга Мостафа бай барачак.

Гадәттә, өйләнгән шәкертләр мәдрәсәдә сыйлау мәҗлесен хозур ясарга тиешләр. Бу эш мәдрәсәдә закон төсен алган. Моннан суфи да читтә кала алмый, калырга теләми дә.

Мәдрәсәдә хәзер шәкертләр бик аз. Шунлыктан хозур ясарга мөмкинлек юк. Моның өчен суфи ярыйсы ук борчыла да. Хозурын шәкертләр җыелып беткәч, көз көнендә ясарга карар бирелде. Шуның белән суфи тынычланды. Моны сүз белән Әмәйләргә дә аңлатырга карар кылынды.

Бүген мәдрәсәдә җанлылык, таш пулат гөж килә, бар да суфи абзый тирәсендә әйләнәләр, суфины киендерәләр, ясандыралар. Суфиның чәчен кырып ташладылар, сакал-мыекларын төзәттеләр. Хуш исләр – гатырша[1], канәфер майлары сөрттеләр. Бүлмәдә әчкелтем-төчкелтем ис.

Караңгы төшкән иде инде, шаулатып, пар ат белән кияү егетләре килеп төште. Алар хәзер суфи бүлмәсендә сыйланып утыралар. Бер сәгать, сәгать ярымнан алар суфины Зөһрә катына алып китәчәкләр. Суфи ягыннан да егетләр билгеләнгән, алар суфины Зөһрәгә илтеп тапшырачаклар.

Кич матур, һава яхшы. Ачык тәрәзә аркылы чаң һәм шалдыравык тавышлары ишетелеп тора. Бу тавышлар суфины шатландырганнан шатландыралар.

Көтелгән вакыт җитте. Хәзерлек эшләре тәгалләнде. Суфины озату башланды: аңа бәхет телиләр, яхшы тормыш сорыйлар.

---

[1] Гатырша – хушбуй.

Шәкертләрнең барысы да шартларга җитеп көлү белән тулганнар. Күз елмайтып, бармак күрсәтү шәкертләрне каһкаһә белән көлдерү дәрәҗәсенә китергән. Суфи тарантаска утырам дигәндә, Мостафа бай чыдый алмады, пырхылдап җибәрде. Аңа ияреп, тагын берничә шәкерт пырхылдады. Бу хәлдән суфи сискәнеп китте һәм шөбһәгә калды. Эш ярты юлда кала дигәндә Гатаулла хәлфә эшне төзәтеп җибәрде – суфи тынычланды.

Шалтыравыклар шалтырап, чаңнар яңгырап китте. Атлар кузгалды. Бер шәкерт азан кычкырды.

Атлар кузгалып, 10–15 минут үтүгә карамастан, суфи утырган арба-тарантас мәдрәсә капкасыннан чыкканы юк иде һәм чыгарга уйламый да иде.

Шәкертләр көлүдән тиргә баттылар. Элек елмаюдан башланган бу көлү каһкаһәгә әйләнде. Тавышка урамнан да кешеләр кергәләде. Шул арада: «Бу нинди ахмаклык, карт кеше белән шулай уйныйлармыни, хәзер таралыгыз», – дип, Ногман хәлфә калын тавыш белән кычкырып җибәрде.

Ногман хәлфә сүзен әйтеп тә бетермәгән иде, тарантаска җигелгән шәкертләр дә, карап торучылар да качып беттеләр. Арбада фәкать Ильяс суфи үзе генә утырып калды. Үксеп елаган хәлдә суфины Самат хәлфә ташпулатка кертеп җибәрде. Ильяс суфиның өйләнүе шуның белән тәмам булды.

**Әхмәтҗан кари.**

Тумыштан гарип булып туган Әхмәтҗан кари хәзер инде алтмыш яшьтә. Сакал-мыекларына чал кергән. Ул ата-анадан бик яшьли ятим калган. Тәрбия итүдән авырсынган кардәш-ырулары аны шул тирәдәге бер мәдрәсәгә китереп ташлаганнар. Мәдрәсәгә килгәндә, аңа 10–11 яшь кенә булган. Димәк, Әхмәтҗан кари бу мәдрәсәдә илле еллар вакыт уздырган.

Әхмәтҗан хәлфә хәзер мәдрәсәдә пишкадәм санала. Ул зәкят һәм шуңа охшаган сәдакаларны пишкадәмнәр белән беррәттән ала. Шуның белән бергә, карига зәкят һәм сәдакаларны үзенә атап та җибәрәләр.

Әхмәтҗан карины мулла, мөәзин булу хокукыннан шәригать мәхрүм иткән. Үзенең бу хокуклардан мәхрүм икәнен ул яшь чагында ук белгән. Шуңа күрә ул муллалар өчен кирәк була торган фәннәрне өйрәнү белән кызыксынмаган. Мулла, мөәзин булмыйча гына яхшы тормыш кору юлында файда бирерлек белемнәр белән

кызыксынган. Һәм шуны тапкан да. Аның бу юлда тапкан һәм үзләштергән бик күп һөнәрләре бар, ул Коръәнне баштанаяк ятлап чыккан, Коръәнхафиз булган. Коръәнне Мисыр мәкаме һәм тәҗвидләп укый белә. Шул һөнәрләр аркасында ул Әхмәтҗан кари исемен алган. Әхмәтҗан кари хатын-кызларны өшкерә, зәгъфран белән тәлинкәләр яза, бүсер сыннары ясый, бала тапмаган хатыннарны имли, сөйдергеч, боздыргыч бөтиләр яза, дарулар әзерли.

Әхмәтҗан кариның иң зур килере «төш кую» белән бәйләнгән. Төш куйдыру өчен, аңа ирләр дә, хатын-кызлар да киләләр. Бу эше белән карины шәһәр халкы гына түгел, тирә-як та белә. Кайбер кешеләр карины бик ераклардан эзләп киләләр. Әхмәтҗан кариның шушы хезмәте аны төне-көне урын өстендә, юрган астында ятарга мәҗбүр итә. Ничә карама Әхмәтҗан кари юрган астында була, төш күрергә тырыша.

Әхмәтҗан кари яту белән йокыга китә. Төшне бик тиз һәм матур күрә. Күргән төшен бик матур һәм туры китереп юрый да. Ул бу турыда атаклы борынгы гарәп төш юраучысы Җәгъфәр Садыйктан бер дә ким түгел.

*Әхмәтҗан кари турында шәкертләр авызыннан*

1. Тәһарәтләнеп торган җирдән Әхмәтҗан кари комганымны тартып алды да бүлмәсенә йөгерде: «Хәзер китерәм, көтеп тор», – диде. Дүрт-биш минут көтеп тордым, комганны китермәде. Ахырда комган сорап бүлмәсенә барып кердем. Бүлмәдә мин белмәгән бер кеше утыра. «Кари кайда?» – дим. Егет: «Тавышланма, хәзер тора», – ди. Яхшылап карасам, юрган астында төш күреп ята. «Комган кайда?» – дим, җавап юк. Ташлап чыгып киттем. Намаз вакыты үтеп бара. Әле минем һаман тәһарәт юк. Җан түзмәде, тагын кари бүлмәсенә киттем. Бу юлы кари уянган, теге кешегә төш сөйләп, төш юрап утыра. «Үземне, – ди,– Истанбулда, Әйя-Суфия мәчете янында күрдем, – ди. – Шәм шикелле сузылып торган манараларга күзем төште. Бер манарада син, икенчесендә бер ак киемле кыз тора, – ди, – кыз сиңа кул сузгач, син дә аңа кул суздың, шулай итеп, кулны кулга тотыштыгыз, – ди. Әлбәттә, кыз синеке булачак», – ди.

Хезмәт хакын биреп, егет чыгып китте. Мин кари янында калдым. «Кари, – дим, – ямьсез булып тора, урыныңны җыештырып куярга кирәк, – дим. Кари, минем бу сүземә җавап итеп: «Юк, ул җыела торган урын түгел, тагын берәрсе килер әле, тагын йоклыйсы булыр», – дип әйтеп бетермәгән иде, ишектән бер кеше килеп керде. Бу кешенең төш куйдырырга килгәнлеге беренче караштта күренеп тора иде.

2. Мин кергәндә, бүлмәдә бер кечкенә кыз бала утыра иде. Кулына зәгъфран белән язылган тәлинкәсе бар. Әхмәтҗан кари өстәл янында икенче тәлинкәгә нәрсәдер язып утыра. Тәлинкә язылып беткәч, минем аркылы тәлинкәне кызга сузды. Тәлинкәгә ике рәсем – бүсер рәсеме ясалган иде.

Тәлинкә кызның кулына керү белән, кари: «Кара, кызым, тәлинкәдәге рәсемне, ишек тоткасы юган су белән изегез, шуңарга ике кашык бал, ике кашык ком салыгыз. Шул су белән барысын берьюлы эчсен», – диде. Кыз: «Ярый, әйтермен», – дип чыгып китте.

Искәрмә: халык телендә «бүсер» дигән бер җанвар бар. Бу җанвар адәмнәрнең эчәк һәм ашказаннарында очып йөри. Ярканатка охшаган бу җанвар аяк һәм канат очларындагы тырнаклары белән ашказаны һәм эчәкләрнең стеналарын кыра, ерта. Шуның нәтиҗәсендә кешенең эчендә авырту башлана. Авыртуны туктату өчен, бүсерне егып, түбәнгә төшерергә кирәк. Моның өчен өшкергән су белән изеп, ком белән бал ашарга киңәш бирелә. Ком бүсернең канатына утырып, бүсерне оча алмас хәлгә китерә һәм, егылып, бүсер касыкка төшеп утыра. Бүсер ике төрле була: ата һәм ана бүсер.

3. Кариның бүлмәсендә ике хатын утыра, берсе сазау – 40–45 яшьләрендә, икенчесе – чәчрәп тора торган яшь хатын. Әхмәтҗан кариның әйтүенә караганда, бу ике хатынның берсе – яше – Себердән килгән. Болар атна-ун көннән бирле һәр көн диярлек кариның бүлмәсендә булмый калганнары юк. Кешеләрнең әйтүләренә караганда, болар карига зур төшемнәр ясаганнар, имеш. Андый-мондый эш уңайга булса, карины Себергә дә алдырырга булганнар, имеш.

Сазау хатын кари булган шәһәрнеке, кари бу хатынны, хатын карины яхшы белә. Дөрес итеп әйткәндә, ул хатын – кариның хатын-кызлар арасында яучы-посредник. Ул карига, кари аңа икмәк ашата.

Яшь хатын – Себернең бер бай кызы, бай килене – Мәфтуха. Мәфтуханың тормышка чыгуына өч-дүрт ел булса да, бала күрә алганы юк. Хәле матур түгел. Моның өчен Мәфтуханың ата-ана ягы да, кияве һәм кайнана да бик борчылалар. Бала булмаганга, ире ташларга йөри икән дигән сүз чыккач, Мәфтуханың рухы тагын да төшкән, ярдәмне әйләнә-тирәдән түгел, ераклардан эзли башлаган. Ерак булган кардәшләреннән Әхмәтҗан кари турында язган хатларын алгач, ул N. шәһәренә килеп чыккан иде. Бу шәһәргә килгәч, Мәфтуха яхшы ук тынычланды. Кариның эшчәнлеге турында бик күп сорашкан һәм бик күп нәрсәләр белгән иде. Имештер, бала

табудан өмет өзгән хатыннар да, кари өшкергәннән соң, бала тапканнар. Имештер, бер хатын камчылы ишанга ничә ел йөрсә дә, бернәрсә дә чыкмаган. Әхмәтҗан карига бер-ике бару белән буйга узган. Имештер, бер хатын, ыграк тәэсир итсен өчен, кариның даруын нормадан артык эчкән. Шуның нәтиҗәсендә Ходаның рәхмәте белән, бердән ике игезәк бала тапкан, ди. Йосыф белән Зөләйха матур булып чәчрәп үсеп киләләр, ди.

Бүген Мәфтуха кари бүлмәсендә актык көн утыра, соңгы процедураны ала. Кари аңа 40–50 көнбагыш орлыгы өшкереп бирде дә, бик җитди карап: «Сеңлем, аң бул, карап кап, куш орлык була күрмәсен. Бердән икене каба күрмә», – диде. Икене бердән кабу һәм куш орлык кабуның ике бала – игезәк бала табуга сәбәп булганын аңлатты. Бу сүз Мәфтуханың ышанычын тагын да арттырды.

Мәфтуханы озатып кергәч, мин: «Ай-хай, кари әфәнде, орлыгың көчле дә икән соң», – дигән идем, кари, бер дә каушамыйча: «Орлык көчле, тик аның бер шарты бар, күршедә таза, матур егетнең булуы шарт», – диде.

4. Таҗи кари ике катлы, тимер түбәле өйдә тора. Бу өй – аның үз өе. Таҗи кариның өе күршесе Садыйк бай өеннән бер дә ким түгел. Өй зур-зур дүрт кварталдан тора. Парадный ход кариның үз фатирына керә, кариның үз аты, үз сыеры. Капкага сыймаслык зур сыерның сөтен өч кешедән торган кари гаиләсе кая куйсын. Хикмәт анда түгел, кари элек-электән каймаклы катык ярата. Шәкерт чагында ул: «Каймак – Аксак Тимернең сөйгән ашы», – ди торган иде. Шуның артыннан ук: «Җәйнең эссе көнендә салкын каймак белән яңа баздан чыккан катык болгатып ашаудан да ләззәтле нәрсә бармы икән», – ди торган иде.

Кариның ишеге ябылып тормый, аның залында берөзлексез кеше булып тора. Өстәлдән самавыр алынмый. Шуның нәтиҗәсендә кичкә таба кариның бер кесәсе бакыр һәм көмеш акча белән, икенче кесәсе кәгазь акча белән тулып кала иде.

Кари, сукыр булу өстенә, чәчәк бозгыны, шадра гына түгел, бите яргаланып беткән һәм таракан ашаган читек төсенә кергән иде. Кариның хатыны, киресенчә, искиткеч матур, мөлаем, җан җылымлы иде. Шуңа күрә мәхәллә хатын-кызлары арасында зур игътибар белән файдалана иде.

Син Коръәнгә ышанма, мәгънәсен дә белмә, хәтта дингә һәм Коръәнгә дошман да бул, ләкин Таҗи кари Мисыр мәкаме белән Коръән укыганда, тыңламый булдыра алмыйсың, чайкалып

утырырга мәҗбүр буласың. Халык теле белән әйткәндә, Таҗи кари да сандугач, сандугач та Таҗи кари иде.

Таҗи кари бу дәрәҗәгә ирешү юлында аз көч куймады, аз мәшәкать күрмәде. Таҗи җиде-сигез яшендә чакта анасы үлеп, яшь ана кулына калды. Яшь анасы беренче көннән алып Таҗины яратмады: «Мин бу җен алыштырган малайны чәнчелдерермен, дөмектерермен әле», – дип, үзенә вәгъдә биреп куйды. Таҗи начар малай түгел иде, ләкин нишләп тә булмый бит, аны табигать бик нык җәберләгән. Икенче төрле әйткәндә, табигать Таҗиның маңгаена төрткән, «менә сиңа», дигән.

Яшь ананың җәберләвенә Таҗи да йончыды, атасы да борчылып эштән чыкты. Бу хәлдән котылу өчен бердәнбер юл Таҗины ерак шәһәргә, мәдрәсәгә илтеп олактыру иде. Һәм шулай булды да. Көннәрнең берендә Таҗины мәдрәсәгә илтеп куйдылар. Яшь ана Таҗидан, Таҗи яшь анадан котылды. Озак үтмәде, Таҗиның өйдән алып килгән азыгы да, акчасы да бетте, Таҗига берничә көннәр ач торырга туры килде. Нәтиҗәдә ун яшендәге Таҗи, урамга-почмакка утырып, сәдака сорарга мәҗбүр булды. Таҗиның мәдрәсәдәге исеме «Таҗи сукыр», урамдагы исеме «хәерче малай»га, «сукыр хәерче»гә әйләнде.

Ничектер, Таҗиның күңеленә бик иртә Мисырга бару, Мисырдан зур кеше булып кайту уе урнашты. Бу исәп Таҗи үскән саен үсә барды. Таҗи, Мисырга бару өчен, акча кирәклеген, Мисырдан зур кеше булып әйләнеп кайтыр өчен, монда ук Коръәнне ятлап, тәмамлап куюның кирәклеген яхшы төшенде. Шул көннән башлап, Коръән ятлый, акча туплый башлады.

Шәһәрнең кайбер байлары хаҗга бару хәзерлеге күрә башладылар. Бәдәлчеләрдә[1] дә шактый җанлылык сизелә. Таҗи суфи да тик ятмый, кечкенә генә – 500 сумлык бәдәл эләктерде. Үзенең дә 2–3 йөз сум туплаган акчасы бар иде. Байлар Таҗины үзләре белән бергә алырга вәгъдә биргәннәр. Бәдәлчеләр дә юлда ярдәмләшергә булганнар. Димәк, Таҗи суфи элек Мәккәгә барачак, хаҗ кылачак. Аннан соң Мисырга – Каһирәгә барачак. Анда берничә елга укырга калачак.

Шактый еллар үтеп китте. Таҗи онытылды. Таҗины мәдрәсәдә дә, шәһәрдә дә телгә алмый башладылар. Таҗи Каһирәдә искиткеч тырышлык күрсәтте: ашамады, эчмәде – шау уку өстендә булды. Нәтиҗәдә Коръәнне бик нык үзләде, дистәләрчә матур-матур

[1] Бәдәлче – кеше урынына ялланып хаҗга баручы.

көйләр отып алды. Шуның өстенә чибәр генә гарәпчә дә сөйли башлады. Ачлы-туклы торуга карамастан, суфиның кесәсе такырайды. Суфи, теләсә-теләмәсә дә, иленә кайтырга мәҗбүр булды. Каһирәне ташлады.

Кинәт шәһәрдә Таҗи суфиның кайту хәбәре таралды. Суфи турында төрле сүзләр таралды: имеш, суфи җиде төрле кыйраәт үткән, бик күп кешеләрдән иҗазәт[1] алган һ. б.

Хәзрәтнең тәкъдиме нигезендә, Таҗи суфи җомгадан соң мәчеттә Коръән укыды. Коръән укуда искиткеч осталык күрсәтте. Күңеле нечкәрми, күзеннән яшь чыгармый калган кеше мәчеттә я булгандыр, я юк. Суфиның бу чыгышы шәһәр халкын шау китерде. Суфи хөрмәтенә зур мәҗлесләр башланды. Хәзер инде Таҗи суфиның элекке исеме телгә алынмый иде, хәзер ул «Хаҗи әфәнде», «Кари хәзрәт» иде.

Мәдрәсәләрдәге суфилар арасыннан шундый кешеләр дә житеште.

***Мәдрәсәләрдә хәлфәләр һәм шәкертләр***

Мәдрәсәгә яңа килгән шәкертләр башлап бер билгеле хәлфәгә беркетеләләр. Әле бу шәкертләр берничә ел буена хәлфәдән генә сабак алалар. Хәзрәт һәм дамелла белән боларның эшләре булмый. Хәтта бу шәкертләрнең бик күбесен хәзрәтләр белмиләр дә, танымыйлар да. Бу шәкертләр хәлфәләрдән берничә ел укыганнан соң, «Шәрхе мулла» хан[2] булгач кына, хәзрәт дәресенә катнаша башлый. Бу вакытта инде бу шәкертләр хәлфәдән дә һәм хәзрәттән дә сабак-дәрес алалар. Берничә ел үтеп, билгеле фәннәр укылгач, шәкертләр хәлфәдән дәрес укуны туктаталар. Хәзрәт белән генә эш итәләр. Бу хәл хәлфәнең гыйльми көченә карап була. Кайбер хәлфәләр шәкертләрне кулларында озак тоталар, кайберләре иртәрәк рөхсәт бирәләр.

Программа буенча үтелергә тиеш фәннәр тәмам булгач, хәтме көтеб – тәмамлау мәҗлесе ясала. Бу мәҗлестә Коръән укыла. Моннан соң хәзрәт шәкертләргә фатиха бирә. Кич белән хәтме көтеб хозуры оештырыла. Моның чыгымы шушы бетерүче шәкертләр кесәсеннән тотыла. Бу хозурга (сыйлау) хәзрәт тә, хәлфәләр дә һәм кайбер аталар, кардәш-ырулар да катнашалар. Шушы көннән башлап, хәтме көтеб итүчеләргә хәзрәт дәресенә катнашу ихтыяри

[1] Иҗазәт – рөхсәт язуы. Коръәнне башкаларга өйрәтә алу хакындагы документ.

[2] Шәрхе мулла хан – «Шәрхе мулла» китабын уку, өйрәнү вакытында шәкертләргә бирелгән исем.

була. Шуның белән дә бу шәкертләргә: «мөстәкыйль – самостоятельный» яки «мөстәгъни – ненуждающийся к помощи» исеме бирелә. Шушы көннән башлап, шәкерткә ике ишек ачыла: 1) мулла булып, мәдрәсәне ташлау, 2) хәлфәлек юлына кереп, дәрес әйтү эшенә керешү.

Бер мәдрәсәне ташлап, икенче мәдрәсәгә күчү бик сирәк һәм аерым очракларда гына була. Бу хәл һәр ике мәдрәсәдә зур шау-шуга сәбәп була. Элекке мәдрәсәдә бу шәкерткә нәфрәт белән карала, дошман тотыла. Икенче мәдрәсә үзенә кабул итсә дә, шактый вакыт ышаныч күзе белән карый алмый, һаман читләштерелә.

Мулла булу да, хәлфә булу да җиңел эш түгел. Мулла булыр өчен, авылдан приговор-тамга җыярга кирәк. Тамга җыю өчен, авыл куштаннарын сыйларга кирәк. Приговорны эшкә җибәрү өчен, түрәләргә взятка бирергә кирәк. Урын өчен тартыш булганда, сый һәм взятка тагын да катлаулана, үлчәве зурая бара иде.

Хәлфә булу да шәкертнең үз кулында гына түгел. Моның өчен дә бик озын һәм бормалы юллардан үтәргә кирәк. Мулланың-хәзрәтнең ышанычын, халыкның игътибарын казана алмасаң, хәлфә булуны уйлама да. Хәлфә исемен алгач та, кинәт үсеп, күтәрелеп булмый. Баштарак вак-төяк белән эш итәргә туры килә. Шулар өстендә сыналгач кына, күтәрелүгә йөз тотасың. Шактый гына шәкертләр бу юлда баш ваталар, көч куялар, чәч-сакал агарталар, ләкин теләккә ирешә алмыйлар.

Мәдрәсәгә башлап баласын китергән кеше турыдан-туры хәлфә белән эш итә алмый. Шәкертләрне хәлфәләргә беркетү – хәзрәт эше. Хәлфәнең кардәш-ырулары, якыннары гына турыдан-туры хәлфә белән эш итә алалар.

Яшь хәлфәләргә иң элек йөреп укучы шәһәр (шәһәрдә булса) балалары яки авыл (авылда булса) балалары беркетелә. Йөреп укучы балаларның да файдалыраклары яшь хәлфәләргә беркетелми әле.

Мәдрәсәдә хәлфә булу җиңел түгел. Хәлфәлектә атказану – тагын да авыр эш. Бу һәрбер хәлфәгә насыйп була алмый. Кайбер хәлфәләр мәдрәсәдә бик зур авторитет белән файдаланалар. Мондый хәлфәләр тирәсенә бик күп шәкерт туплана. Гадәттә, мондый хәлфәләр мәдрәсәдә озак калалар. Аларның исемнәре дә мәдрәсәләрдә озак вакытларга кадәр саклана.

Хәлфәгә беркетелгән шәкерт үзе беркетелгән хәлфәдән генә дәрес укый ала. Мәдрәсә законы буенча, бу шәкертнең икенче бер хәлфәдә укырга хакы булмый.

Бер мәдрәсә эчендә шәкертләр бер хәлфәдән икенче хәлфәгә күчә алмыйлар. Моңа һич тә юл куелмый.

Мәдрәсәдәге хәлфәләр тышкы күренештә бер-берләренә дус һәм теләктәш булып күренәләр. Ләкин, нигездә, бер-беренә зәһәрле конкурентлык саклыйлар. Хәлфәләр арасында сакланган бу көндәшлек шәкертләргә дә йогынты ясамый кала алмый. Шунлыктан бу көндәшлек шәкертләр арасында да нык тамыр җәйгән була. Шуның нәтиҗәсендә шәкертләр үз хәлфәләренә охшарга тырышалар, аларга тәкълид итәргә[1] бөтен көчләрен куялар иде. Нәтиҗәдә тормыш һәм дөньяга караштa шәкертләр бер-беренә капма-каршы гөруһларга[2] бүленәләр иде. Мәдрәсәдә бер хәлфә тәсаувыфка-суфилыкка бирелгән булса, аның шәкертләре дә шул юлга керәләр. Хәлфә риячылылагай булса, аның шәкертләре дә шул юлда була.

Борынгы хәлфәләр белем дәрәҗәләре ягыннан төрле булган шикелле, мәдрәсәләрдә үтелә торган фәннәргә караш ягыннан да чуар булалар иде. Нәтиҗәдә бер хәлфә мантыйкчы булса, икенчесе нәхүче, өченчесе хикмәтче, дүртенчесе динче була. Хәлфәләр йогынтысында шәкертләр дә шундый бер юлга керәләр. Ачык итеп әйткәндә, шәкертләр хәлфәләренең копияләре булып әвереләләр иде.

***Борынгы мәдрәсәләрдә уку елы һәм уку сәгатьләре***

Борынгы мәдрәсәләрдәге уку материаллары программа буенча елларга бүлеп күрсәтелгән булса да, программа материалларын тулысынча шул ел эчендә үтү мәҗбүри түгел иде. Шуның белән бергә, программада фәннәр буенча темалар бүлеп һәм аерып күрсәтелми, бәлки программага карата дәреслек кенә күрсәтелә иде.

Түбәндә Бохара мәдрәсәләренең программасын куябыз. Бу программа – Төркестан, Харәзем, Мәвараэннәһер мәктәпләре өчен якынча уртак программа.

Бохара мәдрәсәләреннән үрнәк алып барлыкка китерелгән борынгы татар мәдрәсәләрендәге программалар беркадәр үзгәрешле. Шуның белән бергә, татар мәдрәсәләре программа ягыннан үзара да үзгәрешле иде. Бер мәдрәсәнең программасы икенче мәдрәсә программасына туры килеп бетми. Бохара мәдрәсәләрендә гарәп сарыфы ике ел, гарәп нәхүе җиде ел укытылса, борынгы татар мәдрәсәләрендә гарәп сарыфы бер ел, гарәп нәхүе 2–3 ел гына укытыла иде. Шуның өчен дә татар мәдрәсәләренең уку срогы кыскарак иде.

[1] Тәкълид итәргә – ияреpгә.
[2] Гөруһларга – төркемнәргә.

Бохара мәдрәсәләрендә дә, татар мәдрәсәләрендә дә программа материаллары тулысы белән үтәлми. Хәтта кайбер фәннәр башланып кына куела. Кайбер фәннәрнең төп үз мәсьәләләренә күз дә салынмый. Мөкаддимәгә – кереш сүзгә анализ ясала да, эш беткәнгә хисаплана. Моннан соң ул фәнне тулысы белән эшләп чыгу шәкертнең үз ихтыярына куела. Ләкин шәкерт бу эш өстендә утырамы-юкмы, аңа контроль ясалмый иде.

Борынгы татар мәдрәсәләренең күбесендә тәфсир һәм хәдис укылмый. Күп мәдрәсәләрдә хәлфәләр һәм хәзрәтләр дә үз программаларына фикъһ дәресләре куялар иде.

Шәкертләр, программа материалын үтү-тәмамлау белән, мәдрәсәне тәмамлыйлар. Җайлы вакыт килгәнгә кадәр мәдрәсәдә тора бирәләр. Шуның белән бергә, кайбер шәкертләр программа материалын тәмамлауны көтмиләр дә иде. Мәдрәсәне ташлап, бер хезмәткә керәләр. Мәдрәсә программасын тәмамлаучылар белән тәмамламаучылар арасында бертөрле дә аерма булмый. Ничек кенә булмасын, татар мәдрәсәләренең уку срогы егерме елга сузыла алмый иде.

***Бохара мәдрәсәләренең дәрес программалары***

Борынгы татар мәдрәсәләренең уку-укыту эшләре шушы программага нигезләнә.

| Уку саны | Дәреслек исеме | Фән исеме | Фәннәр буенча үтеләчәк темалар |
|---|---|---|---|
| I | Бидан | Гарәп сарыфы | Баштан ахырга кадәр |
| II | «Мөгаззи» | Гарәп сарыфы | Баштан ахырга кадәр |
| III | «Кафия» | Гарәп нәхүе | Баштан ахырга кадәр |
| IV | «Мелла Җами» («Шәрхе Мулла») | Гарәп нәхүе | «әл-Мәрфугат» бүлеге |
| V | «Мелла Җами» («Шәрхе Мулла») | Гарәп нәхүе | «әл-Мәҗүрат» бүлеге |
| VI | «Мелла Җами» («Шәрхе Мулла») | Гарәп нәхүе | «әл-Мәнсүбат» бүлеге |
| VII | «Мелла Җами» («Шәрхе Мулла») | Гарәп нәхүе | «әл-Мәбният» бүлеге |
| VIII | «Мелла Җами» («Шәрхе Мулла») | Гарәп нәхүе | Хәмед һәм исем бәхәсе[1] |

[1] Бәхәс – берәр мәсьәлә турында ныклап тикшерү, фикер алышу.

| | | | |
|---|---|---|---|
| IX | «Шәмсия» | Мантыйк | Кереш сүздәге «вәрәттәбтеһе галә мөкаддимәтин вә сәласә мә кәлатин» бәхәсе |
| X | «Гакаиде Нәсәфи» | Кәлям | Хәмед бәхәсе (кереш сүз) |
| XI | «Гакаиде Нәсәфи» | Кәлям | Бәгыйс бәхәсе (төп мәсьәлә) |
| XII | «Гакаиде Нәсәфи» | Кәлям | Сәма бәхәсе (төп мәсьәлә) |
| XIII | «Гакаиде Нәсәфи» | Кәлям | Хакыйкател әшья сабитәтен бәхәсе (төп мәсьәлә) |
| XIV | «Тәһзиб әл-мантыйк вә Кәлям» | Мантыйк, Кәлям | Хәмед бәхәсе (кереш сүз) |
| XV | «Тәһзиб әл-мантыйк вә Кәлям» | Мантыйк, Кәлям | Гыйлем бәхәсе (төп мәсьәлә) |
| XVI | «Хикмәт әл-гайн» | Хикмәт | Әл-хикмәте ишкален нәфес бәхәсе (кереш сүз) |
| XVII | «Хикмәт әл-гайн» | Хикмәт | әл-Мәүҗиде бәдиһин бәхәсе (төп мәсьәлә) |
| XVIII | «Мулла Җәлал» | Ысуле фикъһ | Я мән вәффәканә бәхәсе (кереш сүз) |
| XIX | «Мулла Җәлал» | Ысуле фикъһ | Сәтәфтәрикы өммәти бәхсе (төп мәсьәлә) |
| XX | «Сахихе Бохари» | Хәдис | Иннәма әгъмал бин нияти хәдисе – бер хәдис |
| | «Тәфсире Бәйдави» | Тәфсир | Мөгаувизәтәйин – Коръәннән кыска ике сүрә |

Программа нигезендә фәннәр буенча егерме ел эчендә үтелгән материалга йомгак ясалса, түбәндәгечә булып чыга:

1. Ике ел вакыт эчендә гарәп сарыфы шактый тулы үтелә, сарыф тулысы белән күрсәтелә. Шуның белән бергә, сарыф белән бәйләп, шактый гына кирәксез әйберләр дә күрсәтелә, кирәксез бәхәсләргә керешелә.

2. Алты айлык уку дәверендә гарәп нәхүе шактый гына киң үтелә. Гарәп нәхүе буенча шул вакытта билгеле булган мәтен[1], шәрех, хашияләрнең күбесе күздән кичерелә. Шуның нәтиҗәсендә шәкерт гарәп телендә язылган әйберләрне дөрес итеп укый ала торган һәм укыганын ачык аңлый ала торган була. Дәрес бирүләр фарсы телендә булганга, шәкертләрдә гарәпчә сөйләү теле үсеп җитми.

3. Мантыйк фәненнән «Шәмсия» исемле дәреслек кулланыла һәм «Шәмсия»нең кереш сүзе буенча «вәрәттәбтәһ галә мөкаддимәтин

[1] Мәтен – төп текст.

вә сәламә мәкаләтин» дип башлап киткән кереш сүз эшләнә. Төп мәсьәләгә бик аз кагыла.

4. Мантыйк һәм Кәлямгә карата язылган бу китап буенча ике тема үтелә: а) мантыйкка карата «хәмед бәхәсе» – кереш сүз, б) Кәлямгә карата «гыйлем бәхәсе».

5. Кәлям буенча өч тема үтелә: а) хәмед бәхәсе, кереш сүз, б) бәгыйс бәхәсе, төп мәсьәлә, в) сәма бәхәсе, төп мәсьәлә.

6. Хикмәт буенча ике тема: а) «әл-хикмәте ишкаляи нәфес» җөмләсе өстендә кереш сүз, б) «әл-Мәүҗид бәдиһин» дигән тема, төп мәсьәлә.

7. Ысуле фикъһ буенча ике тема.

8. Хәдис буенча бер хәдис.

9. Тәфсир буенча Корьәннең ахырындагы ике кыска сүрә үтелә. Менә шулар белән шәкертләрнең егерме ел вакытлары үтеп китә. 12–15 яшендә шәкерт мәдрәсәгә кергән булса, хәзер аңа инде 30–35 яшь тулган була. Шуңа карамастан фәннәр буенча мөдәррисләр белән эшләгән әйберләр 10–15% ка җитми. Шулай булгач, фәннәр буенча эшләнми калган 80–90% материал нишли соң? Болар кайчан һәм нинди юл белән үзләштерелә соң? Бу сорауга түбәндәгечә җавап җирергә мөмкин:

Хәлфә, мөдәррис фәннәр буенча эшләп чыккан бер-ике темасында берничә максат күзәтә: а) фәннең эчтәлеге белән таныштыру, ә) үзлегеңнән укуның юллары һәм методлары белән таныштыру, б) шул фәнне эшләгәндә файда бирерлек өстәмә материаллар күрсәтү, в) өстәмә материаллардан файдалану методы белән таныштыру.

Мөдәрриснең шушы рәвешчә юл ачуыннан соң, шәкерткә үзлегеннән уку ишеге ачыла. Шома гына гарәпчә аңлый ала торган шәкерткә үзлегеннән укырга мөмкинлек туа. Үзлегеннән уку вакытында шәкерт шул ук мөдәррисләрдән консультация ала ала.

Гадәттә программа материалын үзлегеннән уку юлы белән шәкерт түгәрәк кенә бер белемгә ия була ала иде. Мөдәрристән алган дәрескә канәгатьләнеп, үзлегеннән укымаган шәкерт эшкә ашмаган надан бер кеше булып кала.

Казан дәүләт университетының гыйльми китапханәсендә татар укымышлыларының шактый күп санда китап һәм кульязмалары саклана. Салих хәзрәт, Курсави, Болгари, Мәрҗаниләр көтепханәсеннән чыккан китаплар, аларның хисап, һәндәсә[1], алгебра,

[1] Һәндәсә – геометрия.

тригонометрия, табигать, география, тарих һәм астрономия шикелле фәннәр белән яхшы таныш булганлыклары аңлашыла. Галимнәрнең кулъязмаларын тикшерү шуны күрсәтә. Хәлбуки Бохара мәдрәсәләренең программаларында бу фәннәр күренмәделәр дә һәм булмады да. Шуңа карамастан Шәрык галимнәре арасыннан атаклы математик, астроном, географ, тарихчы, врачлар бар иде. Боларны мәдрәсә чыгармады, бәлки шәкертләрнең үз тырышлыклары моңа сәбәп булды. Бу дәвердә дөньяви яңа фәннәр белән таныш галимнәр шактый күп иде. Галимнәр тарафыннан дөньяви фәннәргә карата язылган китапларны да һәр җирдә очратырга мөмкин. Дөньяви фәннәр белән танышасы килгән кеше шул галимнәрдән һәм алар тарафыннан язылган китаплардан файдаланды. Курсавилар, Мәрҗаниләр шуларның берсе иде.

Борынгы татар мәдрәсәләренең программалары Бохара мәдрәсәләренең программасына нигезләнеп эшләнгән. Шуның белән бергә, бу ике программа арасында тармакларда үзгәреш тә бар иде. Бу үзгәреш программаны кечерәйтү-йомшарту ягына яки зурайту-көчәйтү ягына карата була. Бохара мәдрәсәләрендә нәхү буенча булган темалар тулысы белән үтелсәләр дә, татар мәдрәсәләрендә бик күп темалар төшереп калдырыла. Фәннәр буенча темаларны ташлау, төшереп калдыру бер фән – нәхү[1] буенча гына түгел, барлык фәннәр буенча да шулай иде.

Мәдрәсәләрдә фәннәр буенча темаларны тулы үтмәстән сайлап кына эш итүнең сәбәбе нәрсә иде икән? Мөдәррисләр моның сәбәбен түбәндәгечә күрсәтәләр иде:

1. Фәннәр буенча барлык темаларны тулы үтәр өчен, 20 еллык уку срогы җитеп бетми.

2. Шәкертләрне үзлегеннән укуга юнәлдерү.

Программа буенча укып, мәдрәсәне бетергән – хәтме көтеб кылган шәкерт мәдрәсәне ташламый, мәдрәсәдән китми. Ул әле җайлы урын, файдалы бер хезмәт табылганга күрә, мәдрәсәдә тора бирә. Шунлыктан мәдрәсәдә 30–40 яшьлек шәкертләр шактый күп була. Хәтта кайбер шәкертләрнең җеназасы мәдрәсәдән чыккан вакытлар да булгалый.

Мәдрәсәләрдә күпчелек үзлегеннән укый. Шуның белән бергә, шәкертләрнең шактый өлеше хәлфә һәм хәзрәтләрдән алган белеме белән канәгатьләнәләр, үзлекләреннән укымыйлар. Пишкадәм

[1] Нәхү – синтаксис.

исемен алып, тик яталар. Мәдрәсәнең барлык мөмкинлекләреннән тигез файдаланалар.

*Төрле тип шәкерт.* Хөсни белән Кәбир икесе дә бер яшьтә, мәдрәсәгә икесе дә бер вакытта, бер елда килгәннәр. Шулай ук бу ике шәкерт бер хәлфәгә туры килгәннәр, бер бүлмәдә үскәннәр. Кәбир – хәзер мәдрәсәдә атаклы хәлфә. Аңа 30–40 шәкерт бирелгән. Хөсни хәлфә була алмаган, булырга да теләмәгән, пишкадәм генә булып калган. Кәбир хәлфәләргә һәм хәзрәтләргә генә карап тормаган, тырышкан, тырмашкан. Нәтиҗәдә мәдрәсә фәннәрен изеп эчкән. Хөсни үзенең күп вакытын йөрүдә, ашау-эчүдә уздырган. Ул мәдрәсә фәннәренең исемнәрен генә белә, эчтәлегеннән хәбәре юк. Ул моны кирәк дип тә тапмый.

Гали белән Вәли рус теле белән кызыксынганнар. Болар рус хәрефе белән танышуны кибет вывескаларыннан башлап киткәннәр. Сабын кәгазе, конфет, шырпы тартмалары боларның уку китабы булып хезмәт иткән. Гали хәзер мәдрәсәдә тора, мәдрәсәдә ашап эчә, ләкин аның төп укуы хәзер «Учительская школа»да. Тагын бер елдан ул учитель булып чыгачак. Вәли дә шулай ук мәдрәсәдә тора. Ул укуны бухгалтерия курсларында дәвам иттерә, озакламый берәр сәүдә фирмасында бухгалтер булып эшләргә уйлый.

Саттар, хәтме көтеб кылу белән, казакъ арасына чыккан. Казанның үзендә сәүдә итеп тә караган. Эш чыкмаган. Хәзер ул яңадан мәдрәсәгә әйләнеп кайткан. Бер-ике елдан бирле мәдрәсәдә тора.

Зариф – пишкадәм, мәдрәсә программасын тәмам иткән. Шуңа карамастан ул Кодуридан башка нәрсә белми. Белмәвенә үкенми дә. Ул бик зур йомышы булса гына мәдрәсәдән чыга. Зур йомыш булмаганда ишек янына да килеп карамый. Шәкертләр шаулатып ашка-мәҗлескә барганда, Зариф берүзе мәдрәсәдә утырып кала. Зариф, рамазан керү белән, урынын җәеп ята, иртәгә Гает дигәндә генә торып, урын-җирен җыя. Рамазан буена ашау-эчүе урын өстендә була. Зариф рамазанда үзенә тигән аш мәҗлесләрен сата. «Сәдакасын кайтарып бирерсез, ашаган өчен биш тиен», – ди.

Мәдрәсәдәге хәлфәләрдә ике төрле шәкерт була: а) йөреп укучы шәһәр яки авыл балалары, б) кунып укучы читтән килгән шәкертләр. Йөреп укучы балалар хәлфәнең тормыш чыганагы булып тора. Болар хәлфәгә шактый гына сәдака бирәләр, ашка чакыралар, бүләкләр китерәләр. Кайбер балалар тәмле-татлы нәрсәләр китерәләр. Кунып укучы шәкертләрнең хәлфә өчен материаль файдалары аз була. Ләкин боларның мәгънәви файдалары бар. Кунып укучы шәкерт

ничаклы күп булса, хәлфәнең шөһрәте-даны шулчаклы зур була. Дан хәлфәнең киләчәге өчен зур капитал булып исәпләнә. Гадәттә, атаклы хәлфәләр шәһәргә яки бай авылга мулла булалар. Мондый хәлфәләргә югары һәм бай урыннардан кыз димлиләр.

Хәлфәләргә беркетелгән бу ике төр шәкертләрнең эш сәгатьләре ике вакытта – иртә һәм кич белән була.

Иртәнге аш-чәй урынын җыеп бетерер-бетермәс йөреп, укучы шәкертләр мәдрәсәгә туплана башлый. Чама белән әйткәндә, бу вакыт сәгать 8–9 ларга туры килә. Йөреп укучыларның укулары көндезге сәгать 12–13 ләргә кадәр сузыла. 12–13 сәгатьләрдә хәлфәләр бүлмәсе тынып кала, шау-шу басыла.

Хәлфәләр йөреп укучылар белән эш алып барганда, бүлмәдәге башка шәкертләр түбәндәге эшләрне башкаралар:

1) Шул бүлмәдәге пишкадәмнәр һәм зуррак шәкертләр укыйлар, язалар, дәрес хәзерлиләр һәм үзләреннән түбән шәкертләргә сабак өйрәтәләр. Шәһәргә, урамга чыгалар. Белеш-таныш, кардәшыруларына баралар.

2) Бүлмәдәге пәскадәмнәр төшке аш әзерлиләр. Аш пешерәләр, чәй кайнаталар. Йомыш белән барасы урыннарына баралар. Мөмкинлеге булган кайбер шәкертләр сабак хәзерлиләр һ. б.

Мәдрәсәләрдә шәкертләр өчен аш пешерү, аш әзерләү шактый катлаулы эш булып санала. Аш әзерләү, бердән, бик күп вакыт ала. Икенчедән, шактый борчулы эш. Кибеткә чыгып продукт аласы бар. Бу вакыт кибет тыгын була, шау-шулы була. Савыт-сабалар әзерләргә, аларны тазаларга кирәк. Ит турыйсы, бәрәңге әрчисе, әшья әзерлисе, камыр басасы бар. Сугышмасаң, талашмасаң, казан һәм плитәдән дә яхшы урын алып булмый. Кухнядан чыгып йөрсәң, ашның өресен урлыйлар, күмерне сыптыралар, әшьясына кул сузалар. Кайчакларда турамый салган итләр бөтене белән юкка чыга. Шулай итеп, иртә сәгать 8–9 ларда башланган эш төш белән сәгать 12–13 ләргә кадәр сузыла. Кайбер бүлмәләрдә пишкадәмнәр аш-су урыннарын да әзерләмиләр. Мондый бүлмәләрдә аш-су урыны әзерләү дә пәскадәмнәр өстенә төшә.

Аштан соң мәдрәсәдә ял вакыты башлана. Мәдрәсәдә тынлык. Зур шәкертләрнең кайберләре шәһәргә чыга, белеш-танышларына бара. Кайберләре ял йокысына талалар – кайлүлә[1] итәләр. Пәскадәмнәр әле һаман эштән бушамыйлар. Аш урынын җыю,

[1] Кайлүлә – кояш чыгып, төш вакытына кадәрге вакытта йоклап алу.

табак-савытлар тазарту һ. б. шактый вакыт ала. Шулай итә торгач, икенде, ахшам килеп җитә. Шул вакытка кадәр пәскадәмгә ял итәргә дә, кулга сабак тотарга да ара булмый.

Мөдәррисләрнең иртәнге дәресләре шәһәр балалары белән бер вакытка туры килә. Хәзрәтләр дәресе мәдрәсәнең дәресханәсендә уздырыла. Дәресе булган пәскадәмнәр шул көнге эштән азат ителәләр. Хәзрәтләрнең күпчелеге бер кергәндә ике дәрес укыта. Кайбер хәзрәтләр бер дәрес белән канәгатьләнә. Чәенә карап, ике сәгатькә дә сузыла. Дәрес бирүдә минутлар исәпкә алынмый.

Кайбер мәдрәсәләрдә ике мөдәррис була. Мондый мәдрәсәләрдә шәкертләр ике хәзрәттән дә сабак алалар. Мөдәррисләрне «яшь хәзрәт», «карт хәзрәт» дип йөртәләр. Карт хәзрәт белән яшь хәзрәт фәннәрне үзара бүлешеп алалар. Үзләренә аерым вакыт билгелиләр.

Кыш көннәрендә кич булып, караңгы төшү белән, мәдрәсә тагын җанлана. Хәзер мәдрәсәнең төп шәкертләре эш башлыйлар. Хәзер һәр шәкерт үзенә билгеләнгән урында. Һәр шәкертнең кулында китабы, каләме, кәгазе. Тырышлык белән дәрес хәзерләнә. Шәкертләрнең кайберләре аерым хәзерли. Шунда ук шәрикләр бергәләп тә дәрес хәзерлиләр, шул ук вакытта бүлмәдә кызып дәрес хәзерләгән бер вакытта, тәмләп чәй эчеп утырган шәкертләр дә, юрган астында төш күреп ятканнары да булмый түгел. Андыйлар да була.

Бүлмә гөрләп торган бер вакытта бүлмәнең ишеге ачыла. «Шәмсия ханнар, Кәбир хәлфәгә, дәрескә» дигән бер белдерү ясала. Бу беренче белдерү хәлфәләрнең дәрескә керешкәнлекләрен аңлата. Хәзер бүлмәдәгеләр башка хәлфәләрнең белдерүләрен көтәләр. Озак та үтми, бер-бер артлы белдерүләр башлана. Шәкертләр дәрескә юнәлә. Бүлмәдә тагын тынлык башлана.

Хәзер мәдрәсәдәге хәлфәләр бүлмәсендә дәрес бара. Шәкертләр текст укыйлар, хәлфәләр мәгънә бирәләр. Шунда ук шәкертләр кызып, моназарәгә[1] керешеп китәләр. Хәлфәләр моназарәнең судьясы булып утыралар.

Хәлфәләр һәр көн группага-шәрикләргә берәр сәгать исәбеннән 2–3 сәгать дәрес укыталар. Хәлфәләрнең дәресе сәгатьләп булмый. Теманың әһәмиятенә карап, озын һәм кыска була.

Хәлфәләр белән бер үк вакытта дәресханәдә хәзрәтләр дә дәрес алып бара. Хәлфәдән дәрес алып чыккан шәкертләр хәзер кичке аш хәзерлегенә керешәләр. Бер-ике сәгатькә тагын кухняда җанлылык

[1] Моназарә – фикер алышу.

башлана. Ләкин бу юлы казан-кәстрүл түгел, чәйнек, самавыр хәрәкәткә килә.

Кичке аш ашалу белән, төрле шәкерттә төрле уй башлана. Берсе ятарга әзерләнә, кайберләре ныклап дәрес хәзерләргә утыра. Шул ук вакытта кайбер шәкертләр бик осталык белән каядыр ычкынырга чамалыйлар һәм, озак та үтми, берничә шәкерт мәдрәсәдән югалган була.

Бүлмәләрдәге югалган шәкертләрнең саны билгеле. Моны бүлмәдәге барлык шәкертләр белә. Ләкин һәркем белмәгәнгә салына. Ул турыда сорау-фәлән булса, «белмим»нән башка сүз әйтелми.

Урамга чыккан шәкертләрнең кайберләре төнге 11–12 ләрдә кайтсалар да, кайберләре ул кич кайтмый да кала. Аларның урыннары буш. Иртә белән сәгать 5 ләрдә кайтып керәләр – кайдадыр кунып кайткан булалар.

Кичке аштан соң дәрес хәзерләргә башлаган кайбер шәкертләр төнге сәгать 2–3 кә кадәр утыралар. Мәтен[1] әйләнәсенә шәрехләр, шәрех әйләнәсенә (дәреслек-китапның полясына) хашияләр язалар. Игътиразлар[2], игътиразга җаваплар әзерлиләр. Сарыф һәм нәхү кагыйдәсенә туры китереп, гыйбарә һәм текстны укып чыгалар.

***Борынгы мәдрәсәләрдә шәкертләрнең эш төрләре һәм аның вакыты***

| Эш вакыты | Пәскадәмнәр эше | Пишкадәмнәр эше | Хәлфәләрнең эш төре |
|---|---|---|---|
| 6–9 сәгатькә кадәр | Урын-җирне җыйнау, юыну, ашау-эчүгә хәзерлек, ашау-эчү | Урын-җирне җыйнау, юыну, ашау-эчү | Юыну, киенү, ашау-эчү |
| 9–12 сәгатькә кадәр | Төшке ашка хәзерлек, төшке аш, аш урыны, савыт-саба җыйнау | Дәрес карау: уку-язу, дәрес өйрәтү һәм башкалар. Хәзрәттән дәрес алу | Авыл яки шәһәрдән йөреп укучы шәкертләргә сабак бирү |
| 12–16 сәгатькә кадәр | Төшке аш, аш урыны җыйнау, савыт-саба чистарту һәм ял итү | Төшке аш ашау, ятып ял итү, чыгып йөрү | Төшке аш ашау, ятып ял итү, чыгып йөрү |
| 16–17 сәгатькә кадәр | Мәтен ятлау, күңел сабакларын өйрәнү | Һәркем үзе теләгән эшне эшли | Дәрескә хәзерлек, китап карау |
| 17–20 сәгатькә кадәр | Дәрескә хәзерлек, дәрес алу һәм уку-язу | Моталәгә, хәзрәттән дәрес алу | Кунып укучы шәкертләргә дәрес бирү һ. б. |

[1] Мәтен – китапның төп тексты.
[2] Игътиразлар – бер фикер, карашка каршы чыгу.

Хәлфәләр көн дә 2–3 сәгать дәрес укыталар дигән идек. Ләкин кечкенә генә сәбәпнең дәрескә өзеклек бирүен хәтердән чыгарырга ярамый. Кызып дәрес барганда, ишектән кунак килеп керә, хәлфә кашын сикертә: «Бар, чыгыгыз, иртәгә укырбыз», – ди. Бүген дәрес булмый кала. Иртәгәнең үзенең эше бар. Хәлфә яңа гына дәрес башлый, шул арада ишектән бер бала кереп, хәлфәгә бер язу бирә. Бала хәлфәне чәйгә чакырырга килгән. Бүген тагын дәрес була алмый. Хәлфәнең кәефе булмаса, тагын дәрес булмый кала. Менә болар бар да дәрескә өзеклек китерә. Шуның нәтиҗәсендә кайбер шәкертләргә атнага бер дәрес тә булмый кала.

***Шәкертләрнең укулары буенча дәрәҗәгә бүленүләре***

Борынгы мәдрәсәдә класс бүлмәләре дә, класс системасы да юк. Шуның белән бергә, шәкертләрне берәм-берәм укыту да юк. Мәдрәсәләрдә укыган дәреслекләренә карап, шәкертләрне группаларга бүләләр. Бу группаларны «шәрикләр» дип атыйлар. Шәрикләр 5–10 укучыдан да, 15–20 укучыдан да тора. Шулай итеп, бер хәлфәдә яки бер хәзрәттә берничә шәрик булырга мөмкин.

Шәкертләрнең мәдрәсәдә файдалы мөмкинлекләре бар. Бу мөмкинлекләрдән файдалану турында шәкертләр тигез хокукта була алмыйлар. Бу мөмкин түгел. Шул уңай белән шәкертләр, укыган фәннәренә карап, төрле дәрәҗәләргә бүленәләр. Дәрәҗәләргә бүленү төрле мәдрәсәдә баскычлы була. Кайбер мәдрәсәләрдә артык вакланмаган була. Түбәндә дәрәҗә бүленешенең өч формасын күрсәтәбез:

I – 1) Шәрхе Габдулла хан – «Шәрхе Габдулла»[1] укучылар
II – 2) Шәрхе мулла хан – «Шәрхе мулла»[2] укучылар
3) Шәмсия хан – «Шәмсия»[3] укучылар
4) Гакаид хан – «Гакаид»[4] укучылар
5) Мулла Җәлал хан – «Мулла Җәлал»[5] укучылар

[1] «Шәрхе Габдулла» – гарәп морфологиясенә фарсы телендә аңлатмалар биргән грамматика дәреслеге.

[2] «Шәрхе мулла» – гарәп теле морфологиясе буенча фарсы телендә язылган трактат.

[3] «Шәмсия» – XIII гасыр галиме Нәҗметдин Гали бине Гомәр әл-Казвининең мантыйк буенча гарәп телендә язган «Әр-рисаләтеш-шәмсия фил-кавагыйделмантыйкыя» исемле хезмәте.

[4] «Гакаид» – Нәҗметдин Әбү Хафса Гомәр Нәсәфинең (1068–1142) – кәлям гыйлеменә багышланган гарәп телендәге әсәре.

[5] «Мулла Җәлал» – Җәлалетдин Дәввәнинең (1426–1501) «Гакаидел-гыйздия» исемле хезмәтен шәрехләп, гарәп телендә язылган мантыйк китабы.

III – 1) Сарыф хан – сарыф[1] укучылар
2) Әнмүзәҗ хан – «Әнмүзәҗ»[2] укучылар
3) Шәрхе мулла хан – «Шәрхе мулла» укучылар
4) Шәмсия хан – «Шәмсия» укучылар
5) Сөлләм хан – «Сөлләм»[3] укучылар
6) Гакаид хан – «Гакаид» укучылар
7) Мулла Җәлал хан – «Мулла Җәлал» укучылар

IV – 1) Шәрхе Габдулла хан
2) Тәркиб хан
3) Әнмүзәҗ хан
4) Кафия[4] хан
5) Шәрхе мулла хан
6) Исагуҗи[5] хан
7) Шәмсия хан
8) Сөлләм хан
9) Тәһзиб[6] хан
10 ) Хикмәт хан
11) Гакаид хан
12) Мулла Җәлал хан

Мәдрәсә шәкертләренең дәрәҗәләргә бүленешендә түбәндәге файдалар күзәтелә:

1) Шәкертләрнең белем дәрәҗәләрен билгеләү.

2) Шәкертләрнең мәдрәсә эчендәге хокукларын билгеләү.

3) Мәдрәсәгә килгән тәсаддыйк-сәдакаларны пропорциональ бүлүдә уңайлык тудыру.

Мәдрәсәләр дини булгач, шәкертләрне дәрәҗәләргә бүлгәндә, дини яктан чыгып бүләргә тиеш иде. Ләкин бу эштә дини принцип кулланылмады.

---

[1] Сарыф – морфология.

[2] «Әнмүзәҗ» – Мәхмүд бине Гомәр әз-Зәмәхшәринең (1075–1144) «Китабел-әнмүзәҗ» исемле гарәп теле грамматикасы.

[3] «Сөлләм» – Габдешшөкүр әл-Бихари (1707 елда вафат булган) тарафыннан мантыйк буенча гарәп телендә язылган «Әс-сөлләмел-голүм» трактаты.

[4] «Кафия» – Ибне әл-Хаҗибнең (1249 елда вафат булган) гарәп телендәге әсәре.

[5] «Исагуҗи» – XIII гасыр галиме Әсиреддин бине Гомәр әл-Әбһәри тарафыннан грек телендәге әсәрне эшкәртеп, гарәп телендә язылган «Китабел-Исагуҗи» исемле мантыйк буенча хезмәт.

[6] «Тәһзиб» – Сәгъдетдин Мәсгуд бине Гомәр Тәфтазанинең (1322–1390) «Тәһзибел-мантыйк» әсәре.

***Мәдрәсәләрнең программалары, уку планнары һәм дәреслекләре***

Борынгы мәдрәсәләрнең үзләренә ярашлы программалары бар иде. Ләкин бу программа үз тарихында беркем тарафыннан расланмады да, беркем тарафыннан контрольгә дә алынмады. Программа мәдрәсәләрдә язма рәвештә сакланмады. Шуның белән бергә, бу программа татар мәдрәсәләре өчен уртак бер программа булып торды. Телдән телгә, буыннан буынга күчеп йөри торган бу программа үз тарихында бертөрле рәсми үзгәрешкә дә очрамады.

Борынгы мәдрәсәләрдә квартал һәм чирекләргә бүлеп төзелгән эш планы булмый иде. Хәлфәләр дә, хәзрәтләр дә дәреслек һәм аларның эчтәлекләре белән канәгатьләнә.

Борынгы татар мәдрәсәләре программа нигезендә фәннәр буенча түбәндәге дәреслекләрне кулланалар иде:

| Нинди фәннән | № | Дәреслекнең исеме | Теле | Дәреслек авторы | Авторның үлгән елы (милади ел белән) |
|---|---|---|---|---|---|
| Гарәп сарыфы | 1 | «Бидан» (тәсриф) | фарсыча | Авторы билгеле түгел | Билгеле түгел |
| | 2 | «Шәрхе Габдулла» | фарсыча | Габдулла бине Ак-Мөхәммәд | 1273 милади |
| Гарәп нәхүе | 1 | «Әнмүзәҗ» | гарәпчә | Зәмәхшәри, Мәхмүд бине Гомәр | 1143 милади |
| | 2 | «Шәрхе Әнмүзәҗ» | гарәпчә | Ардебили Мөхәммәд бине Габделгани | 1151 милади |
| | 3 | «Кафия» | гарәпчә | Ибне Хаҗиб, Госман бине Гомәр | 1248 милади |
| | 4 | «Шәрхе мулла» | гарәпчә | Әл Җами, Габдрахман бине Әхмәд | 1492 милади |
| Мантыйк | 1 | «Исагуҗи» | гарәпчә | Әл-Әбһәри, Мофәззал бине Гомәр | 1300 милади |
| | 2 | «Шәрхе Исагуҗи» | гарәпчә | Әл-Кати, Хисамеддин, Хәсән Әл-Казвини | 1358 милади |
| | 3 | «Шәмсия»[1] | гарәпчә | Гомәр бине Гали | 1089 милади |

[1] «Шәмсия» – XIII гасыр галиме Нәҗмеддин Гали бине Гомәр әл-Казвининең мантыйк буенча гарәп телендә язган «әр-рисаләтеш-шәмсия фил-кавагыйдел-мантыйкыя» исемле хезмәте.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 4<br><br><br>5 | «Сөлләме әл-голүм»<br><br>«Шәрхе Шәмсия» | гарәпчә<br><br><br>гарәпчә | Әл-Бәһари, Мөхибулла бине Габдешшәкүр<br>Әл-Әүзи, Мәхмүд бине Мөхәммәд | 1119 милади<br><br>1364 милади |
| Кәлям | 1 | «Гакаиде Нәсәфи»[1] | гарәпчә | Ән-Нәсәфи, Гомәр бине Мөхәммәд | 1142 милади |
| Мантыйк, Кәлям | | «Тәһзибе мантыйк вә кәлям»[2] | гарәпчә | Тәфтазани, Мәсгуд бине Гомәр | 1346 милади |
| Ысуле фикъһ | 1 | «Тәүзыйх»3 | гарәпчә | Әл-Мәхбүби, Гобәйдулла бине Мәсгуд | 1346 милади |
| Кәлям | 1 | «Мулла Җәлал» | гарәпчә | Дәвվәни, Җәлалетдин | 1502 милади |
| Ысуле фикъһ | 1 | «Әл Мәнаф» | гарәпчә | Ән-Нәсәфи, Габдулла бине Әхмәд | 1310 милади |
| Хәдис | 1 | «Мишкяте мәсабих»[4] | гарәпчә | Әт-Тәбризи, Мөхәммәд бине Габдулла | 1414 милади |
| Тәфсир | 1 | «Тәфсире казый Бәйдави»[5] | гарәпчә | Әл-Бәйдави, Габдулла бине Гомәр | 1291 милади |

Борынгы мәдрәсәләрнең бик аз бер өлешендә генә хәдис һәм тәфсир канәгатьләнерлек укыла иде. Бик күп мәдрәсәләрдә хәдис, тәфсир укылса да, бик аз һәм кыска укыла. Кайбер мәктәпләрдә хәдис, тәфсир бөтенләй укылмый.

Мәдрәсәләрдә, югарыда күрсәтелгән фән һәм дәреслекләрдән тыш, түбәндә күрсәтелгән дәреслекләр дә укыла. Фикъһ фәненә караган бу дәреслекләр төрле мәдрәсәдә төрле вакытта үтелә. Бу

[1] «Гакаиде Нәсәфи» – Нәҗмеддин Әбү Хафса Гомәр Нәсәфинең (1068–1142) кәлям гыйлеменә багышланган гарәп телендәге әсәре.

[2] «Тәһзиб» – Сәгъдетдин Мәсгуд бине Гомәр Тәфтазанинең (1322–1390) «Тәһзибел-мантыйк» әсәре.

[3] «Тәүзыйх» – «Тәүзыйхел-ысул» исемле фикъһ буенча гарәп телендә язылган әсәр.

[4] «Мишкяте мәсабих» – XIV гасыр галиме Вәлиеддин Мөхәммәд бине Габдулла әл-Хатыйб әт-Тәбризинең «Мишкятел-мәсабих» исемле хәдисләргә аңлатмалар җыентыгы.

[5] «Казый Бәйдави» – фарсы дин галиме, казый. Коръән тәфсирчесе Наширеддин әл-Бәйдавинең (1319 елда вафат) «Тәфсире Казый Бәйдави» хезмәте.

дәреслекләр кайбер мәдрәсәдә башка фәннәр белән беррәттән бервакытта укылса, икенче бер мәдрәсәдә җәй көне (башка дәресләр туктагач) яки рамазан аенда укыла иде.

Түбәндә күрсәтелгән дүрт төрле фикъһ дәреслекләре кайбер мәдрәсәләрдә дүртесе дә укыла, кайбер мәдрәсәләрдә бер яки икесе генә укытыла.

| № | Дәреслек исеме | Дәреслекнең авторлары | Авторның үлгән елы |
|---|---|---|---|
| 1. | «Кодури» | Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Багдади әл-Кодури | 1036 ел |
| 2. | «Мохтәсар»[1] | Гобәйдулла бине Мәсгуд әл-Мәхбүби, Садрешшәрига | 1344 ел |
| 3. | «Җәмиг әр-рөмуз» | Шәмсетдин Мөхәммәд әл-Кәһстани | 1552 ел |
| 4. | «Һидая»[2] | Гали бине Әбү Бәкер әл-Мәргыйнани | 1196 ел |

Мәдрәсәгә яңа килгән укучыга башлап «Як хикәят» яки «Хәмде би хәд»[3] китабы укыталар. Фарсы телендә язылган бу тәсаувыф китапларын уку, сарыф, нәхү фәннәрен укуга хәзерлек дип карала.

***Мәтен, шәрех һәм хашияләр***

Борынгы мәдрәсәләрдә кулланыла торган китап һәм дәреслекләр өч типта язылган була иде. Бу өч типта язылган китаплар мәтен, шәрех һәм хашия дип атала. Нинди дә булса бер фәнгә карата бик кыска итеп язылган китап «мәтен» дип атала. Мәтенгә тулы аңлатма бирү юлы белән озынайтылган-киңәйтелгән әсәр «шәрех» дип атала. Шәрех эчендәге мәтеннәр җәя эченә алынган яки сызык астына язылган була. Мәтен яки шәрехнең кайбер билгеле урыннан аерып алып, шул урыннарда гына аңлатма бирелгән булса, бу әсәргә «хашия» диләр.

Борынгы мәдрәсәләр гадәтенчә, укылган дәреслекнең тексты ятланырга тиеш. Мәдрәсә кагыйдәсе буенча ятлау үзләү дип таныла. Ятланмаган дәрескә бәя дә бирелми. Шунлыктан шәкертләр аңлы укуга караганда ятлауны өстен күрәләр.

[1] «Мохтәсар» – Гобәйдулла бине Мәсгуд бине Таҗешшәриганың «Мөхтәсарелвикаят фи мәсаилел-һидая» исемле фикъһ буенча гарәп телендәге әсәре.

[2] «Һидая» – Борһанетдин әл-Мәргыйнанинең (1197 елда вафат булган) фикъһ буенча гарәп телендәге хезмәте.

[3] «Хәмде би хәдд» – мәшһүр әдип Фәридетдин Гаттарның «Пәнднамә» исемле фарсы телендәге шигъри нәсыйхәтләр китабы.

Ятлау өчен дәреслекнең тексты кыска булырга тиеш. Аңлы уку өчен, текстның тулы һәм озын булганы яхшы. Алынган белемне тирәнәйтү һәм киңәйтү өчен, тагын да тулырак, тагын да яңарак әсәр кирәк. Сөйләнгән шушы принцип мәдрәсәдә кулланыла торган китапларның өч типта булуын таләп итә.

Гарәп нәхүе – шактый киң, шактый катлаулы бер фән. Гарәп нәхүе буенча «Кафия» иң атаклы дәреслек булып санала. Татарстан, Төркестан, Һиндстан, Мавәраэннәһер, Гарәпстан, Сүрия, Мисыр һәм Төркия мәдрәсәләренең һәрберендә «Кафия» дәреслек булып торды. «Кафия», бик кыска – 16–17 битле бер әсәр булуга карамастан, бөтен нәхү кагыйдәләрен эченә ала. Шуның өчен дә «Кафия» мәтен булып санала. «Кафия»нең берничә шәрхе һәм берничә хашиясе бар. Шәрехнең шәрхе, хашиянең хашиясе дә була.

Мәтеннең шәрхен яки хашиясен мәтен авторы үзе дә яза ала, икенче бер автор да эшли ала. Ибне Хаҗиб тарафыннан язылган «Кафия»нең шәрхе булган «Фәваиде зыяия» мулла Җами тарафыннан язылган. Кафиянең хашиясе Габделхәким Сиялькүти тарафыннан язылган.

Мәтен белән шәрех һәр икесе дәреслек була алалар. Хашия өстәмә материал булып кына санала, дәреслек була алмый. Борынгы мәдрәсәләрнең кайберләрендә элек «Кафия», моннан соң «Фәваиде зыяия шәрхе мулла» укыла иде. Ә кайбер мәдрәсәләрдә турыдантуры «Фәваиде зыяия» укыла иде.

Нәзым-шигырь белән язылган әсәрләр һәм мәтеннәр «ятлау өчен җиңел» ди торганнар иде. Шушы педагогик караштан чыгып, мәтеннәрнең кайберләре нәзым юлы белән языла.

Шәрык мәдрәсәләрендә укыла торган барлык фәннәр буенча нәзым белән язылган мәтеннәрне күрсәтергә мөмкин. Шәрех һәм хашияләр нәзым белән була алмый. Нәзым белән язылган мәтеннәргә мисал итеп, нәхү фәне буенча «Әлфия»не, игътикадка карата «Әмали»не күрсәтергә мөмкин. Нәзым юлы белән язылган математика, тарих, география, мантыйк һәм хикмәт китаплары да шактый күп.

Суфи Аллаһияр тарафыннан язылган «Сөбател-гаҗизин»гә[1] Таҗетдин Ялчыгол улы төрки шәрех язды. Аны кызы исеменә атап, «Шәрхе Газизә» дип исем бирде. Шул ук «Сөбател-гаҗизин»гә Утыз Имәни гарәпчә шәрех язды. Димәк, мәтен белән шәрех һәм хашия бер-беренә башка булган төрле телләрдә дә була алалар.

[1] «Сөбател-гаҗизин» – XVII гасыр төрки шагыйре Аллаһияр Суфиның шигъри-әхлакый әсәре.

Борынгы татар мәдрәсәләрендә татар телендә татарча бер генә дәреслек кулланылмады. Татар галимнәре, шәкертләр өчен дәреслек һәм өстәмә материаллар язганда да, гарәп телендә язалар иде. Мәдрәсәләрнең соңгы көннәрендә тәрҗемә юлы белән язылган кайбер дәреслекләр кулланса да, бу хәл бик соң эшләнде. Фарсы телендә язылган шәрех һәм хашияләрдән өстәмә материал рәвешендә шактый файдалана иде.

***Мәдрәсәләрдә уку һәм укыту методлары***

Борынгы мәдрәсәләрдә кулланыла торган дәреслекләр дә һәм өстәмә дәреслекләр дә язма иде. Һәркем үзенә кирәк була торган китапны күчереп ала яки берәр кешедән күчерттерә. Унбиш-егерме битле бер китап язу артык бер көч таләп итмәсә дә, 2–3 йөз битле китапларны язып чыгу шактый вакыт ала. Мәдрәсәләрдә китап язу эшен үзенә кәсеп итеп алган шәкертләр дә була. Мондый язучылар бик тиз язалар һәм язган әйберләре шактый матур чыга.

Гыйльми көтепханәләрдә саклана торган кульъязмалар Татарстанда язылган китапларның нәфислек һәм нечкәлек ягыннан түбән торганын күрсәтәләр. Татар шәкертләре арасында оста язучылар аз иде дияргә мөмкин.

Борынгы татар мәдрәсәләрендә (кайбер фәннәр буенча) ташбасма китаплар бик иртә күренгән булса да, наборлы басмалар 17 нче еллардан соң гына кулланыла башлады.

Казан шәһәрендә беренче мәртәбә Шәрык типографиясендә «Иман шарты»[1], икенче булып «Һәфтияк»[2] басыла.

Мәдрәсәләрдәге хәлфә дәресләре хәлфәләрнең үз бүлмәләрендә укыла, хәзрәт дәресләре мәдрәсәнең дәресханәсендә укыла иде. Шәкертләр дәрес бирүчене уртадарак калдырып, идәнгә ярым түгәрәк булып утыралар.

Хәлфәләр дәресе дә һәм хәзрәтләр дәресе дә хәзерге шикелле билгеле сәгать, кискен бер минут белән алып барылмый. Эшнең характерына карап, озын да, кыска да була.

Мәдрәсә кагыйдәсе буенча, бер фән тәмам булмый торып, икенче фән башланмый. Бер үк вакытта ике төрле фән уку гадәте юк. Мәсәлән, сарыф тәмам булмый торып, нәхү башлау, нәхү тәмам булмый торып, мантыйк башлау гадәте юк. Шуның белән бергә,

[1] «Иман шарты» – гарәп әлифбасын һәм ислам дине нигезләрен өйрәтү дәреслеге.

[2] «Һәфтияк» – Коръәннең җидедән бер өлешеннән торган китап.

төп дәрес белән өстәмә дәресләр бер вакытта параллель рәвештә баруы да мөмкин. Мәсәлән, «Шәрхе мулла» белән «Мохтәсар» бер вакытта, бер ел эчендә укылырга мөмкин.

Хәлфәләр шәкертләрне билгеле бер вакытка, билгеле бер дәрәҗәгә кадәр генә укыталар. Шушы билгеле вакыт җитеп, билгеле дәреслекләр укылгач, шәкерт бөтене белән хәзрәт карамагына күчә. Менә бу чикле вакыт төрле мәдрәсәдә төрлечә була.

Шәкертләр башта хәлфәләрдән генә укыйлар. Билгеле бер вакыт килгәч, хәзрәтләрдән дә дәрес башлыйлар. Димәк, бу вакыт шәкертләр ике кешенең дәресеннән файдалана һәм билгеле вакытка кадәр бер үк заманда бер-беренә башка булган ике фәннән дәрес ала. Ләкин бу хәл озак сузылмый, хәлфәләрдән дәрес тукталу белән, иске хәленә кайта.

Хәлфәләр мәдрәсәгә югары саналган һәм катлаулырак булган фәннәр укытудан тартынган шикелле, хәзрәтләр дә түбәнрәк фәннәрне укытудан сакланалар. Шуның өчен дә шәкертләрнең хәзрәттән башлаган беренче дәресләре иң киме «Шәрхе мулла» яки «Шәмсия» була. Шуның белән бергә, хәзрәттән башланган дәреснең берникадәр темалары хәлфәләрдән үтелә. Шуңа карамастан хәзрәтләр ул фәнне башыннан алып китәләр.

Хәзерге мәктәпләрдәгечә, шәкертләр көнгә берничә дәрес ала алмыйлар. Хәлфәләр көн саен берничә дәрес бирсәләр дә, шәкерткә атнага бер яки ике дәрес кенә туры килә. Димәк, шәкерт атнага бер яки ике сәгать дәрес белән вакыт уздыра. Мәдрәсәләрнең еллык уку көне 230–235 көн булса, һәр шәкерткә 30–35 сәгате дәрес туры килә була.

Хәлфәләрнең дә, хәзрәтләрнең дә атналык язма расписаниеләре булмый. Шуңа карамастан шәкертләр нинди дәрес, нинди көн булачагын беләләр. Күңелдә генә саклана торган бу расписаниене язмага әйләндерсәк, түбәндәгечә булыр иде.

*Хәлфә дәресе өчен*

| Көннәр | Беренче дәрес | | Икенче дәрес | |
|---|---|---|---|---|
| Шимбә | Фикъһ | «Мохтәсар» | Гарәп сарыфы | «Бидан» |
| Якшәмбе | Сарыф | «Шәрхе Габдулла» | Нәхү | «Кафия» |
| Дүшәмбе | Нәхү | «Шәрхе мулла» | Мантыйк | «Исагуҗи» |
| Сишәмбе | Мантыйк | «Шәмсия» | Сарыф | «Бидан» |
| Чәршәмбе | Сарыф | «Шәрхе Габдулла» | Кафия | «Нәхү» |
| Пәнҗешәмбе | Нәхү | «Шәрхе мулла | Мантыйк | «Исагуҗи» |
| | | | Мантыйк | «Шәмсия» |

*Хәзрәтләр дәресе*

| Көннәр | Беренче дәрес | | Икенче дәрес | |
|---|---|---|---|---|
| Шимбә | Гарәп нәхүе | «Шәрхе мулла» | Мантыйк | «Шәмсия» |
| Якшәмбе | Мантыйк | «Сөлләм» | Хикмәт | «Хикмәтел-гаен» |
| Дүшәмбе | «Кәлям» | «Гакаиде Нәсәфи» | «Ысуле фикъһ» | «Тәүзыйх» |
| Сишәмбе | Мантыйк | «Мулла Җәлал» | Нәхү | «Шәмсе мулла» |
| Чәршәмбе | Кәлям | «Шәмсия» | Мантыйк | «Сөлләм» |
| Пәнҗешәмбе | | «Гакаиде Нәсафи» | Ысуле фикъһ | «Тәүзыйх» |

Гадәттә, күп мәдрәсәләрдә фикъһ, тәфсир һәм хәдис шикелле фәннәр өстәмә дәрес булып керә. Өстәмә дәресләр барлык мәдрәсәләрдә дә кич белән генә укытыла.

Борынгы мәдрәсәләрдә хәзрәтләрнең дәрес бирү методлары белән хәлфәләрнең дәрес бирү методлары арасында бертөрле дә аерма юк. Дәрес бирү методлары бер-беренең копиясе генә булды. Шуның белән бергә, мәдрәсәләрдәге дәрес бирү методы барлык мәдрәсәләр арасында уртак метод иде.

Хәзрәтләрнең дәрес башлаулары һәм дәресне дәвам иттерүләре түбәндәгечә эшләнә:

1) Бүген дәресханәдә кешеләргә һәм нинди дәрес булачагы бөтен мәдрәсә шәкертләренә билгеле. Моны барлык шәкерт белә. Шул уңай белән шәкертләрдән берсе хәзрәткә иртә үк дәрес урыны әзерләп куя. Хәзрәт утыра торган урынга киез яки көрпә сала. Өстәлне үз урынына хәзрәт алдына төзәтеп куя, идәннәрне себерә, дәресханәне тәртипкә китерә.

2) Кем дә булса хәзрәтнең кергәнен күреп кала яки хәзрәтнең дәресханәдә утырганын күрә. Гадәт буенча, бу кеше хәзрәтнең дәрескә керүе турында шәкертләргә белдерү ясый, хәбәр итә.

3) Белдерү ирешү белән, дәрес булган шәкертләр дәресханәгә туплана башлый. Бу туплану 5–10 минутка тартыла.

4) Хәзрәтне уртадарак калдырып, шәкертләр хәзрәтнең әйләнәсенә түгәрәкләнеп утыралар. Утыру тезләнү юлы белән була. Башкача утыру әдәпсезлек, хәзрәткә хөрмәтсезлек булып санала. Тез кадап утыру арттагы сафларда гына, хәзрәт күзе төшми торган урында гына мөмкин була.

5) Шәкертләрнең керүләре туктагач, хәзрәт күзе белән йөртеп, шәкертләрне тикшереп чыга һәм берәр шәкертнең юклыгын сизсә, сәбәбен сорый.

6) Шәкертләр туплангач, хәзрәт кулындагы дәреслеген ача һәм шәкертләргә дә китапларын ачарга куша. Китаплар ачылган хәлдә идәнгә куела. Шунлыктан дәреслекне бөгелеп укырга, бөгелеп күзәтергә туры килә.

7) Хәзрәт бер шәкерткә китапның гарәпчә текстын укырга куша. Шәкерт текстны иптәшләре ишетерлек итеп кычкырып укый башлый. Грамматика кагыйдәләренә бик нык игътибар ителә.

8) Хәзрәт тә, шәкертләр дә текст укучының дөрес уку-укымавын күзәтеп баралар. Текст укучы бертөрле хата ясаса, шәкертләр шунда ук төзәтә. Шәкертләр сизми калган хаталар турында хәзрәт укучыга яки гомум шәкертләргә сорау бирә.

9) Текст укучы берничә җөмлә укыгач та, хәзрәт «әва»[1] ди. Бу инде укучыга туктарга кушу була. Укучы туктый, шәкертләр тураялар һәм күзләре белән хәзрәткә юнәләләр.

10) Хәзрәт шәкертләргә бер мәртәбә күз йөртеп алгач, укылган текстка татарча мәгънә бирә һәм шул текстка карата аңлатма ясарга керешә, чагыштырмалар ясый, мисаллар күрсәтә һәм шәкерткә тагын укырга куша. Кайбер дәресләрдә текстны буйдан-буйга бер генә шәкерт укый. Кайбер дәрестә текстны бүлеп, берничә шәкерт укый. Бу – хәзрәт ихтыярында. Шушы рәвешле дәрес ахырына кадәр дәвам итә һәм бер, бер ярым сәгатькә сузыла.

Мәдрәсәләрдә үткәрелә торган хәлфә дәресләре дә шул юл белән алып барыла.

***Рамазан, рамазан дәресләре һәм мәтен ятлау***

Мәдрәсәләр өчен рамазан ае аерым бер чор булып тора. Бу ай башлану белән, көндәлек тормышларында зур үзгәреш ясала. Бу үзгәрешкә хәлфәләр дә, шәкертләр дә алдан ук әзерләнәләр.

Рамазан керү белән, шәкертләрнең яту-тору вакытлары үзгәрә, ашау-эчүләре башкара, дәресләр өчен яңа расписаниеләр кертелә.

Рамазан – шәкертләр өчен туклык ае. Рамазанда бер генә шәкерт тә кайнар ашсыз калмый, тәмле һәм туклыклы ашлар ашала. Рамазан хәлфә һәм пишкадәмнәр өчен ял ае булып саналса да, пәскадәмнәр өчен шактый борчулы ай була. Пәскадәмнәргә күп эшләргә, аз йокларга туры килә. Рамазандагы шәкерт тормышын расписаниегә салганда, түбәндәге якынча расписание килеп чыгар иде:

[1] Әва (ава) – «әйе, шулай» мәгънәсендә.

| № | Якынча вакыт | Көндәлек эшнең төрләре |
|---|---|---|
| 1. | 9 сәгать | Иртәнге йокыдан тору |
| 2. | 9–10 с. | Юыну, урыннарны җыештыру һ. б. |
| 3. | 10–12 с. | Дәрес хәзерләү һәм дәрес алу |
| 4. | 12–15 с. | Ифтарга әзерләнү, аш пешерү, чәй әзерләү һ. б. |
| 5. | 15–17с. | Ифтар ашау-эчү, аш урыннарын җыю, табак-савыт тазарту |
| 6. | 17–19 с. | Тәравих намазы, анда-монда булу |
| 7. | 19–20 с. | Кичке чәй |
| 8. | 20–22 с. | Дәрес хәзерләү, яңа дәрес алу |
| 9. | 22–24 с. | Төнге йокы |
| 10. | 24–3 с. | Сәхәргә әзерлек, аш пешерү һ. б. |
| 11. | 3–4 с. | Сәхәр ашау |
| 12. | 4–5 с. | Ашау урыннарын җыю, табак-савытларны тазарту һ. б. |
| 13. | 5–9 с. | Иртәнге сәхәрдән соңгы йокы |

Кайбер мәдрәсәләрдә иртәнге йокы сәгать 10–11 ләргә кадәр дәвам итә. Мондый мәдрәсәләрдә иртә белән дәрес укулар булмый.

Рамазан керү белән, гадәттәге расписаниеләр туктатыла. Гадәттәге дәресләр урынына рамазанга караган ихтыяри дәресләр башлана. Рамазанда шәкертләр үзләре кызыксынган, үзләре теләгән дәресләрне генә укыйлар. Шуның белән бергә, бер дә укымасаң да була. Моның өчен беркем бернәрсә әйтми.

Рамазанда укыла торган ирекле дәресләр ике төрле була иде: 1) мәдрәсәләрдә укыла торган төп дәресләр буенча белемне тирәнәйтү теләге белән берәр әйбер уку, 2) мәдрәсә программасы буенча хәлфә һәм хәзрәтләрдән укылмый торган берәр фән уку. Икенче төргә мисал итеп, түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

1. Коръәннән сүрәләр өйрәнү, догалар ятлау.
2. Тәҗвид уку, мәкам (Коръән көе) өйрәнү.
3. Фикъһтан берәр китап уку.
4. Фәраиз (мирас бүлү юллары) уку.
5. Игътикадка карашлы булган «Әмали» уку.
6. Мәтен ятлау.
7. Китап язу, дәреслекләр күчерү.
8. Кереш сүзгә карата язып укылган бәхәс һәм истәлекләрне язу-күчерү.

Мәдрәсәләрдә укыла торган дәреслекләрнең мөкаддимәләре – кереш сүзләре шактый шау-шулы үтә. Бәхәссез, критикасыз бер генә кереш сүз дә булмый. Мәсьәлә ачык аңлашылсын өчен, гарәп сарыфы буенча фарсы телендә язылган «Бидан» дәреслеген алыйк.

Җиде-сигез сүздән торган «Бидан» мөкаддимәсе буенча айларга сузылган бәхәсләр түбәндәгеләрдән тора:

**Сөаль:** ни өчен мөсанниф (автор) «әгузене» элек китергән, «бисмиллаһ»ны соң китергән?

**Җавап**: «Әгузе»дә дәфгы мәзаррәт[1] бар, «бисмиллаһ»та җәлбе мәнфәгать[2] бар. Зарарны җибәрми торып, файданы алып булмый. Шуның өчен «әгузе»не элек китергән.

**Сөаль:** ни өчен мөсанниф «бидан» дигән, ни өчен «дан» гына димәгән?

**Җавап:** «бидан» – «бик бел» дигән сүз, «дан» – «бел» генә дигән сүз. Белүгә караганда бик белү артыграк. Шуның өчен мөсанниф «бидан» дигән.

**Сөаль:** ни өчен мөсанниф «бидан» дигән, ни өчен «бихан» димәгән?

**Җавап:** «бидан» – «бик бел» дигән сүз. «Бихан» – «бик укы» дигән сүз. Белүдән уку лазем түгел, бәлки укудан белү лазем. «Әз хандән данестән нәмиаяд, бәлки әз данестәне хандән миаяд[3].

**Сөаль:** Ни өчен мөсанниф «бидан» дигән, ни өчен «игълям» димәгән?

**Җавап:** «бидан» – фарсы сүзе, «игълям» – гарәп сүзе. Бу китап фарсы балалары өчен язылган. Әгәр мөсанниф «игълям» дисә иде, фарсы балалары моңардан качарлар иде.

**Сөаль:** ни өчен мөсанниф «әсгадәкә Аллаһе» дип, гарәпчә әйткән, ни өчен бу сүзне фарсыча әйтмәгән?

**Җавап:** «әсгадәкә Аллаһ» дога була, дога гарәп теле белән тизрәк кабул кылына. «Әд-догаи би-ләфзый гарәбияти мәкърунәт бил-иҗабәти»[4].

**Сөаль:** Ни өчен мөсанниф «әсгадәкә» дип, мазый сыйгасы[5] белән китергән, ни өчен «йосгыйдекә» дип мозариг сыйгасы[6] белән китермәгән?

**Җавап:** «әсгадәкә Аллаһ» дога була. Дога һәрвакыт мазый дога һәм вакыт мазый сыйгасы белән кылына.

---

[1] Дәфгы мәзаррәт – зарар-зыянны булдырмау.
[2] Җәлбе мәнфәгать – файдалыны тарту, китерү.
[3] Белем укудан килми, бәлки укый белүдән килә.
[4] Гарәпчә укылган дога Аллаһы Тәгалә тарафыннан кабул ителүгә якын дога.
[5] Мазый сыйгасы – үткән заман хикәя фигыль формасы.
[6] Мозариг сыйгасы – киләчәк заман хикәя фигыль формасы.

**Сөаль:** мөсанниф «фи-д-дарәйни – ике йортта» дигән. Бу ике йорттан максаты ни булган?

**Җавап:** «фи-д-дарәйни»дән морад дөнья белән ахирәт була.

Моннан соң шәкерткә «әгузе», «бисмилла» мәгънәләре өйрәтелә һәм «Бидан»ның кереш сүзе булган, «әсгадәкә Аллаһе фи-д-дарәйни» җөмләсе төшендерелә. Моннан соң гына «ки кәлимәти гарәп бәр сеһ гыйсмәт, исем әст вә фигыль әст»[1] дип, төп мәсьәләгә керешелә.

Гадәттә, бу югарыда язылганнар шәкерткә яздырып укытыла һәм тулысы белән бер-ике ай вакыт ала.

Кереш сүз бәхәсе «Бидан» буенча гына түгел. Ул һәрбер фән, һәрбер дәреслек буенча шулай куелган.

Мәдрәсәләрдә мәтен ятлау шактый әһәмиятле эшләрдән санала. Шуның өчен мәдрәсәләрдә мәтен ятларга бик зур игътибар бирелә. Шәкертләр, мәтен ятлар өчен, рамазанны көтеп алалар иде.

Хәзрәтләр мәтен тыңлатуны кирәксенмиләр. Шуңа карамастан хәлфәләр мәтен ятлау һәм мәтен тыңлатуга бик зур игътибар бирәләр. Хәлфәләр шәкертнең белем дәрәҗәсен һәм эшчәнлеген мәтен ятлау, мәтен белү белән үлчиләр.

Мәтен ятлау – шәкертләр өчен бик зур җаваплы эш, мәтен тыңлату куркынычлы бер хезмәт иде. Шәкертләр сыртына төшкән камчының 70–75% ы мәтен тыңлату уңае белән була. Адәм баласы кимчелексез була алмый бит. Шулай булгач, шәкертләрдә кимчелекләр булмый мөмкин түгел. Шәкертләрдә була торган бу кимчелекләр, бу җитешсезлекләр мәдрәсә гадәтенчә камчы белән тигезләнә иде. Мәдрәсә эчендә булган кимчелекләрне хәлфәләр исәпкә алып баралар һәм аларның ачуын мәтен тыңлатуда чыгаралар. Шуның өчен дә мәтен тыңлату көне дәһшәт көне, куркыныч көн санала.

### *Моназарә һәм аның формасы*

Дәреснең билгеле темалары буенча гыйльми сүз көрәштерү борынгы шәкертләр арасында бик көчле иде. Шуның белән бергә, «моназарә» дип атала торган бу гыйльми көрәш бик мактаулы эшләрдән санала. Гадәттә, моназарәләр фикъһ, нәхү, сарыф шикелле фәннәр өстендә булмый, моназарәләр мантыйк, хикмәт, гакаид-кәлям һәм ысуле фикъһ шикелле фәлсәфә белән бәйләнгән сузылмалы фәннәр буенча була торган иде.

[1] Гарәп сүзләре өч төркем[гә бүленә], исем һәм фигыль *(өченче төркеме турында чыганакта сүз юк).*

Гадәттә, моназарәләр түбәндәге урыннарда оештырыла:

1. Хәлфәләр дәресендә хәлфәнең үз шәкертләре арасында.

2. Хәзрәт дәресендә төрле хәлфә шәкертләре арасында.

3. Хәзрәт дәресендә чит мәдрәсәләрдән килгән шәкертләр белән ике арадагы зур һәм шау-шулы моназарә.

4. Дәрестән тыш, ял көннәрендә чит мәдрәсәләрдән килгән шәкертләр белән ике арадагы моназарә.

Гадәттә, чит мәдрәсәләрдән моназарә өчен килгән шәкертләрне «кунаклар» дип йөртәләр. Түбәндә моназарә формаларын язганда, чит мәдрәсә шәкертләрен «кунак» дип, икенче якны «шәкертләр» дип йөртәбез. Хәзрәтләр дәресендә кунаклар белән шәкертләр арасында була торган моназарәләр түбәндәгечә дәвам итә:

Мәдрәсәнең дәресханәсендә хәзрәтнең дәресе бара. Көтелмәгәндә дәресханәнең ишеге ачыла, ишектән күз күрмәгән, беркемгә дә таныш булмаган биш-алты шәкерт килеп керә. Хәзрәттән рөхсәт сораганнан соң, бу кунаклар дәрес тыңларга утыралар. Хәзрәт үзенең дәресен дәвам итә.

Кунаклар, утырганнан соң, хәзрәтнең дәресеннән моназарә башлап җибәрерлек момент күзәтәләр. Әйтик, хәзрәтнең дәресе «вәхдәте важиб – Алланың берлеге» турында бара икән, хәзрәт Алланың берлеген исбат итү теләге белән Коръәннән «ләү кәнә фиһима иләһәтен иллә Аллаһ ләфәсәдәта»[1] аятен укый да мәгънәсен сөйли башлый. «Әгәр гадәмдә Аллаһтан башка тагын бер Аллаһ булса иде, җирләр, күкләр һәлак булыр, күкләр, җирләр җимерелер иде», – ди. Хәзрәтнең бу сүзләре турыдан-туры моназарәгә юл ача. Кунаклар арасыннан берсе, хәзрәткә карап: «Галәмдә ике важиб – Аллаһ булсын, җир һәм күкләр һәлак булмасын» дип каршы төшә. Мондый каршы төшүгә гарәпчә «игътираз» диләр. Хәзрәткә карап әйтелгән бу сүзнең шәкертләргә юнәлдерелгәнен хәзрәт тә, шәкертләр дә бик ачык аңлыйлар, беләләр. «Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла»га охшый иде.

Хәзрәт, кунакларның бу чыгышларын хуплаганнан соң, шәкертләргә карап: «Җә, кайсыгыз керешә», – ди.

Хәзрәтнең тәкъдиме буенча, шәкертләрнең берсе: «Әлбәттә, шулай була шул» дип, сүзгә керешә. Моңа кунакларның берсе каршы төшә. Шулай итеп, моназарә башланып китә. Сүз артыннан сүз

[1] «Әгәр ул икәүдә (күкләрдә һәм җирдә) Аллаһтан башка илаһлар булса, ул икәү җимерелеп беткән булыр иде» – «Әнбия» сүрәсенең 22 нче аяте. – Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә. Казан: «Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты, 2019. Б. 322.

чыга, һәр сүзнең артында шәкерт яки кунак тора. Йомшак кына, матур гына башланган бу көрәш каты тавыш, ямьсез бер кычкырышка әйләнә. Күп вакыт инде тезләнеп утырулар онытылган була, саф бозыла, хәзрәтне бер читтә калдырып, кунаклар берәм-берәм уратып алынган була.

Хәзер дәресханәдә тавыш, кычкырыш. Шәкертләр белән кунакларның берсе әйткәнне икенчесе белми. Бер сүзгә ун җавап. Күзләр туза, авыздан төкерекләр чәчелә, куллар болгана. Шәкертләр дә, кунаклар да саташкан хәлгә килгән булалар.

Сүз артыннан сүз, җавап артыннан җавап ычкына торгач, төп мәсьәлә читтә кала, мәсьәләнең эзе югала. Төп мәсьәлә белән һичбер төрле бәйләнеш булмаган икенче бер темага күчелә. Көрәш мәгънәсез чүбек чәйнәүгә әйләнә.

Эш шул дәрәҗәгә килгәч, күзәтүче хәзрәт арага төшә. Тавышны бастыра. Малярия пристубыннан айныган авыру кыяфәтенә әйләнгән моназарәчеләр тынычланалар, тәртипкә киләләр. Моназарә туктала, көрәш бетә. Тиргә баткан шәкертләр һәм кунаклар сөртенәләр, киң сулыш алалар. Сөртенү материалы булып, күлмәк итәге, казаки чабуы, җиң һәм шуңа охшаган кием-салым хезмәт итә. Ара-тирә яулык та күренгәли.

Хәзер эш хәзрәткә калды. Ул моназарәгә анализ ясарга, бәя бирергә тиеш. Очы-кырые булмаган болганчык бу көрәшкә анализ ясауда, бәя бирүдә хәзрәт бертөрле авырлык сизми. Элек сүзне кунаклардан башлый. Аларның бик күп шәрех һәм хашия караганлыкларын искә ала, аларның тырышлыкларын әйтеп китә. «Матур, оста сөйләдегез», – ди. Моннан соң шәкертләр ягына күчә, шәкертләрнең дә күп китап караганлыкларын, бу турыда кунаклардан ким түгеллекләрен сөйли. Моназарәдә зур ярдәм итә торган берничә китапны укырга тәкъдим ясый. Моназарәне мактый. Кунакларның тагын рәхим итүләренә үтенә. Хәзрәтнең шушы сүзләре моназарәгә анализ һәм бәя бирү булып исәпләнә. Моназарә шуның белән тәмам була.

20–30 кешене эченә алган моназарәдәге дәлилләрне, андагы сүзләрне язып күрсәтү мөмкин түгел. Моны тулы итеп күрсәтер өчен, зур бер әсәр язарга кирәк. Шуның өчен без монда моназарәдәге сүзләрнең нинди яссылыкта барганын кыска гына язып, күрсәтеп үтәбез. Кыска гына итеп алганда, сүзләр түбәндәгечә бара:

1. Хәзрәт: «Ләү кәнә фиһима илаһәтен иллә Аллаһ ләфәсәдәта», ягъни галәмдә бер Аллаһтан башка тагын бер Аллаһ булса иде,

җирләр һәм күкләр һәлак булыр иде. Коръәндәге бу аять турыдан-туры галәмдә Ходаның (ваҗиб) бер генә булуын күрсәтә.

Кунак: галәмдә Хода ике булсын, җир белән күк һәлак булмасын.

Хәзрәт, шәкертләргә карап: «Я, кайсыгыз керешә, кунакларның игътиразлары туры һәм урынлы», – ди.

Шәкерт: Әлбәттә, шулай була шул. Галәмдә ике Хода булырга мөмкин түгел. Бәр тәкъдир[1], галәмдә ике Хода була икән, бу ике Ходаның һәр икесе кадир (көчле) буламы, әллә берсе көчле булып, икенчесе көчсез буламы? Ике шикнең берсе булмый мөмкин түгел.

Кунак: Берсе тулы көчле, икенчесе көч ягыннан кимрәк булсын.

Шәкерт: Әгәр сез әйткәнчә була торган булса, тулы көчлесе Хода була. Ә көчсезрәге Хода була алмый, чөнки көчсезлек Хода өчен мөмкин түгел.

Кунак: Һәр икесе көчле булыр, һәр икесенең көче тигез булыр.

Шәкерт: Бәр тәкъдир, һәр икесенең көче тигез булса, галәмне яратуда һәр икесенең кирәге бармы, әллә берсе җитәме?

Кунак: Берсе генә дә җитсен.

Шәкерт: Алай булгач, берсе заид-артык була. Артык булган зат Хода була алмый.

Кунак *(арадан берсе):* Алай булгач, һәр икесенең кирәге булсын.

Шәкерт: Вәин канә кәзалик – алай булгач, һәр икесе Хода була алмый. Өченче Хода эзләргә туры килә. Бу вакыт яки тәсәлсел[2] яки дәвер хасыйл була. Тәсәлсел дә һәм дәвер дә мөмкин. Шулай булгач, Ходаның ике булуы да мөхаль[3].

Кунак: Тәсәлсел дә, дәвер дә мөхаль булмасын, мөмкин булсын.

Кунаклар тарафыннан әйтелгән бу сүз «Кәлям» фәне буенча башланган моназарәне мантыйкка өстерәү була. Бу каршы төшүдән соң шәкертләр элек тәсәлселнең, моннан соң дәвернең юклыгын исбат итәргә тиеш була.

Борынгы юнан фәлсәфәсеннән торган тәсәлсел һәм дәвер мәсьәләсе күп тармакларга бүленә һәм бик озын сүзләргә сәбәп була. Шуның белән бергә, бу турыдагы сүзләр шәкертләрне җиңүгә юнәлдерәләр. Шунлыктан моназарәчеләр мондый сүздән саклана-лар. Димәк, бу сүз кунаклар тарафыннан уйламастан әйтелгән бер сүз була. Шуның өчен кунакларның берсе тиз генә мәсьәләне икенче якка борып ала һәм элек әйтелгән сүздән кире кайта.

[1] Бәр тәкъдир – әгәр була калса.
[2] Тәсәлсел – чылбырланып, бер-берсенә тоташып китү.
[3] Мөхаль – мөмкин булмый.

Кунак: Хода ике булсын. Дөнья һәм ма сиваны[1] яратуда кодрәт һәм көч ягыннан тигез булсыннар. Эштә иттифак булсын. Иттифак сыйфатларына зат булсын.

Кунакларның соңгы сүзләре шәкертләрне шактый авыр бер хәлгә сала. Шәкертләр, теләр-теләмәс төп мәсьәләне читтә калдырып, башка бер юл тотарга мәҗбүр булалар. Ничек кенә булмасын, бу сүздән соң кунакларның позицияләре шактый ныгу юлына керә.

Моназарәне башлап җибәрү өчен дә, моназарәгә катнашу өчен дә шәкерт моназарә белән бәйләнгән мәсьәләне яхшы белгән булырга тиеш. Шулай булмаганда ул хәзер төшеп кала, җиңелә. Шушы хәл булмасын өчен, шәкертләр алыначак дәресне бик нык һәм тирән итеп укып керәләр. Шәкертләрнең зур күпчелеге дәреслекне уку өстенә, 2–3 өстәмә китап – шәрех һәм хашия дә караган була. Бу – мәдрәсәләрнең яхшы ягы булып тора. Шәкертләр арасында дәрес хәзерләүгә ялкаулык күрсәтүчеләр дә була иде. Мондый шәкертләр дә моназарәдән читтә кала алмыйлар. Ләкин мондый шәкертләр авызларына ни туры килсә, шуны сөйләүчән булалар. Мондый шәкертләргә мәдрәсә телендә «сафсатачы» диләр.

Дәрестә кемнең текст-гыйбарә укуы алдан билгеле булмый, чөнки бу эшне хәзрәт билгели. Текстны ялгыш уку укучы шәкертнең шәкерт өчен йөз кызыллыгы иде. Гыйбарәне ялгыш укучылардан көләләр. Гыйбарә укуга салкын караган кайбер шәкертләргә кушамат та кушалар: «Мәхәлли Габдрахман» – «Мәхәлли» кушаматын «мәхәллә» сүзен мәхәлли дип, ялгыш укыган өчен алган иде.

Хәзрәтләр дәресендә була торган моназарәләр ике хәлфә шәкертләре арасында була. Шунлыктан бу моназарәләр хәлфәнең намусын саклау лозунгы астында дәвам итә. Хәтта кайбер вакытларда шәкертләрне хәлфәләр үзләре әзерләп кертәләр. Тавышлы моназарәләр күтәрелүе мөмкин булган дәресләргә хәлфәләр үзләре дә катнашалар иде, кайбер очракларда алар үзләре дә катнашып китәләр. Мондый моназарәләр тагын да тавышлырак була.

Дәрестән тыш шәкертләрнең үз араларында була торган моназарәләр түбәндәгечә башлана: кыш көне кич сәгать 7–8 ләр чамасы. Мәдрәсәгә таныш булмаган 4–5 шәкерт килеп керә. Садрины сорыйлар. Беренче караштa ук бу шәкертләрнең моназарәгә килгәнлекләре күренеп тора. Шәкертләр мондый кунакларга өйрәнеп беткән, аларны бер күрү белән таныйлар. Дүрт-биш минут эчендә

[1] Ма сиваны – моңардан башкаларны.

бу хәбәр бөтен мәдрәсәгә тарала. Сөйләшкән, сорашкан юк. Шуңа карамастан кунакларның кайсы мәдрәсәдән булулары да, яшьләре дә, дәрәҗәләре дә беленгән була. Һәрвакыт берәм-берәм йөргән мәдрәсә шәкертләре хәзер төркем-төркем булып йөриләр. Сөйләшәләр, киңәшәләр. Кичә генә пычакка-пычак булган төрле хәлфә шәкертләре хәзер туганлашканнар. Алар хәзер мәдрәсә намусы өчен шәһид китәргә разыйлар.

Кичә генә бер-беренә күз очы белән генә карашкан, ут белән су шикелле хәлфәләр кичәге хәлне онытканнар. Моназарәгә әзерләнүче төркемнәргә җитәкчелек итәләр. Сорау текстлары әзерләшәләр. Хәзер хәлфәләр арасында да, шәкертләр арасында синеке, минеке юк – бертуганга әйләнгәннәр.

Кунаклар хәзер Садри бүлмәсендә чәй эчәләр. Ләкин нәрсәдер көткән шикелле сәер утыралар, күңелләре тыныч түгел.

Ишек ачыла, йөзләгән шәкерт бүлмәгә басып керә. Бүлмә шәкерт белән тула. Кунаклар утырган кечкенә генә мәйдан кала. Ул урын да кысылганнан-кысыла бара, кечерәя тора.

Кунакларга сорау бирелә. Ләкин кунаклар әле назланалар: «Юк, без сөйләшер өчен килмәдек, сөйләшергә икенче вакыт килербез әле» дигән булалар. Кыстаталар. Шәкертләр «дөрр» кубып, чыгып китәләр. Бүлмә берничә минутка бушап кала.

Озак та үтми, шәкертләр тагын Садри бүлмәсенә басып керәләр. Тагын сорау бирәләр. Ләкин бу икенче сорау, беренче сорауга башкарак була.

Сорау: «Ләү канә фиһима илаһәтен иллә Аллаһ ләфәсәдәта» аятенә игътимадән вәхданияте важибне тәсәлсел юлы белән исбат чөн там?[1]

Бу юлы бирелгән сорау ачык һәм билгеле. Сорау йомшак төзелгән. Димәк, шәкертләрне сөйләтәселәре килә. Икенче сорау беренче сорау шикелле томанлы, болганчык түгел. Димәк, сүз башларга мөмкин.

Күзгә-күз карашып алганнан соң, кунакларның берсе: «Әлбәттә, шулай була шул....», – дип, моназарәне башлап җибәрә.

Шома гына, мөлаем генә башланган сүз көрәше бик тиз арада кызып китә һәм тавышлы бер талашка әйләнә. Бик дустанә башланган бу моназарәләр кайчакта хурлашулар, хәтта кыйнашулар белән тәмам була.

Шәкертләрнең моназарәгә барулары ничек башлана соң?

---

[1] Аллаһы Тәгаләнең берлеген ышанычлы дәлилләр белән раслау өчен, «Ләү канә фиһима илаһәтен иллә Аллаһ ләфәсәдәта» аяте генә җитәме?

Мәдрәсәнең берничә яшь моназарәчесе, чит бер мәдрәсәгә барып, бәхет сынап карарга уйлый. Хәлфәнең кәефле вакытын туры китереп, мәсьәләне аңа белдерәләр. Хәлфә бу фикерне алкышлап каршы ала. Хәзрәттән дә фатиха алырга куша.

Берничә көннән соң бу фикер хәзрәткә дә җиткерелә. Хәзрәт эшкә уңыш тели. Тәҗрибәдән чыгып, берникадәр киңәшләр бирә. Эш шушы дәрәҗәгә килгәч, мәсьәлә бөтен шәкерт арасында фаш була.

Моназарәгә бару өчен, хәзрәтнең рөхсәте кирәк түгел. Моны хәлфә дә һәм моназарәчеләр дә бик яхшы беләләр. Эш анда түгел. Моннан төп теләк – хәзрәт алдында хәлфә һәм аның шәкертләренең дәрәҗәсен күтәрү.

Хәлфә һәм хәзрәтнең теләге җиңде. Моназарә уңышлы чыкты. Шау-шулы булса да, сугышуга барып җитмәде. Башка төрле казаэыянга очрамады.

Шул ук көн шул ук мәдрәсәдән тагын бер төркем моназарәчеләр икенче мәдрәсәгә киткәннәр иде. Ләкин боларның эшләре уңышлы булмады. Беренчедән, артык авыр һәм катлаулы итеп төзелгән сорауларга очрадылар. Икенчедән, мәсхәрә юлы белән әйтелгән сүзләр йөкләргә туры килде. Моназарәчеләр беренче һәм икенче сорауга төшенә алмадылар. Көрәшүдән баш тарттылар. Ә өченче сорау намуска тия торган мәсхәрәле сорау иде. Әт-талибунә әт таирунә лил әкли вә шөрби казиясе сабит булганда, сохари белән булки чөн там?[1] дип бирелгән өченче сорау намуска тия торган иде.

Кунаклар дүртенче сорауда гына сүзгә керешә алдылар. Ләкин хәзер инде һәр ике якның ачуы кабарган, һәркемнең бармаклары йодрыкланган, кечкенә генә бер ишарә авызга менеп төшүгә сәбәп була ала иде.

Тавыш зур булды. Шунда да кыйнашулар булмады: «Синдә йодрык булса, миндә менә нәрсә бар», – дип, Фәхринең Кавказ пычагы күрсәтүе кыйнашуны басып калды.

Кунаклар чәй янына утыргач та, аяк киемнәре турында борчылганнар иде. Киез-каталарга ачу итеп су тутырсалар нишләрбез дип пошынганнар иде. Алай булып чыкмады. Аяк киемнәре кадак белән идәнгә кадакланып кына куелган иде. Зәкинең бишмәт чабуы киселгәне өйгә кайткач кына билгеле булды.

Кышкар шәкертләре моназарәгә зур хәзерлек белән киләләр. Алар элек Кышкарның үзендә айлар буена шәрех һәм хашияләр

[1] Шәкертләр һәм кошларның ашау-эчү хакын раслау өчен, сохари белән булки гына җитәме?

тикшерәләр, дәрес дәфтәрләре (язып укылган әйберләрне) күчерәләр. Җыелып, һәр көн репетиция ясыйлар.

Кышкарлар, моназарәгә килү белән, капыл-кара эш башламыйлар. Элек мәдрәсәләргә йөреп, хәзрәтләрнең дәресләрен күреп, темалар белән танышалар. Кышкарлар, моназарәгә барганда, үзләре белән бергә кирәкле китапларны да алалар. Хәзрәтләрнең дәрес темалары билгеле булгач, бу темалар өстендә тагын бер мәртәбә китап карап алалар. Шуннан соң гына моназарәгә йөри башлыйлар.

Кышкарлар шәһәрдә моназарә бетү белән кайтып китмиләр. Белеш-танышларга кунакка йөриләр. Яшереп, сакланып кына булса да, типтереп тә алалар. Шулай итә торгач, шәһәрдә атна-ун көн вакыт үтеп китә.

***Җәйге мәдрәсә һәм җәйдә шәкертләр тормышы***

Мәдрәсәләрнең эшләре тукталу ачык һәм билгеле көннәр белән бәйләнмәгән. Мәдрәсәдә дәресләрнең тукталуы шәкертләрнең таралуы белән бәйләнгән, ә шәкертләрнең таралуы елның килүе белән бәйле.

Мәдрәсәләрдә еллык сынаулар XIX йөз ахырында гына күренә башлады. Шул елларга кадәр мәдрәсәләрдә сынау булмады. Көннәр озынаеп, кояш карый башлау белән, хәлфәләр мәтен тыңлауны җәеп җибәрәләр иде. Шушы мәтен сынау урынын тота.

Мәдрәсәләрнең күбесендә шәкертләрнең таралу вакытлары ике төрле хәл белән бәйләнгән: 1) чана юлы бозылу – юллар киселү; 2) арба юлы төшү һәм су юлы ачылу. Димәк, кайбер шәкертләр юл бозылганга кадәр, кайбер шәкертләр арба юлы төшү белән мәдрәсәне ташлыйлар иде. Моннан калган шәкертләр үз җайларына карап, берәмләп таралалар.

Җәй көннәрендә мәдрәсәләрдә рәсми дәресләр булмый. Шулай булуга карамастан шәкертләр тик тормыйлар. Үзләренә берәр эш табалар. Җәй көне шәкерт ихтыярлы. Теләсә укый, теләсә башка бер эш таба.

Мәдрәсәләрдәге укудан тыш эшләр түбәндәгеләр була ала иде:

1. Шәкерт үзе дә белми. Аны бик яшь чагында ук мәдрәсәгә китереп ташлаганнар. Аның туган илендә сыенырлык бер кешесе дә юк. Җәй көне шәкертләрнең тормыш яклары да яхшыра төшә. Йөзләгән шәкертләр арасында бүленә торган хәер-сәдака дистәләрчә шәкертләр арасында гына бүленә. Шуның өчен бу шәкерт бер җиргә дә кузгалмый. Ел әйләнә мәдрәсәдә тора бирә.

2. Мәкәрҗәгә эшкә бару теләге белән урын күзәтеп торучы шәкертләр.

3. Сәүдә (сату-алу) итү. Кайбер шәкертләрнең яту-торулары, ашау-эчүләре мәдрәсәдә була. Ләкин шәкерт, уку эшен ташлап, нинди булса да берәр сәүдә башлый. Кыш өчен үзенә ризык әзерли.

4. Шәһәр җирләрендә матур язучы, хәттат-каллиграфлар була. Болар теләгән кешеләргә бушлай язу өйрәтәләр. Кайбер шәкертләр шундый осталардан язу өйрәнәләр. Чутай Мостафа[1], Камал кари, Кыйвам кари[2] һәм Нури Бортас Казан шәһәренең данлыклы язучылары иде.

5. Шәкерт коръәнхафиз булырга, кари исемен алырга тели. Карилар халык арасында игътибарлы булалар. Шуны күздә тотып, шәкерт җәй көне Коръән ятлый.

6. Шәкертнең кышкы тормышы өчен чыганагы юк. Сәүдә итәр өчен суммасы да юк. Шәкерт кемгә булса да җәйлек берәр хезмәткә яллана. Ләкин тормышы мәдрәсәдә була.

7. Укымый һәм эшләми тик яту, тик торучы шәкертләр. Шәкертләрнең йорт эше өчен кирәге юк. Ашау-эчү, кием-салым белән тәэмин ителгән. Шәкерт ял итеп мәдрәсәдә ята бирә. Җәйге мәдрәсәдә шундый шәкертләр дә була.

8. Шәкерт, мулла булу өчен, бер авылдан тамга җыйган. Ул хәзер губернатордан указ көтеп ята. Эш җайланганга, авылга кайтып торасы килми.

9. Хосусый рәвештә русча укучылар. Шәкерт муллалык хезмәтен үтәгәндә, файдаланырлык дәрәҗәдә русча беләсе килә яки шәкерт мәдрәсәдән туйган. Мәдрәсәне ташлап, рус мәктәбенә керергә исәпли. Шуңа күрә ул җәйге тормышын русча укырга биргән.

10. Хәлфәләр, карилар һәм суфилар җәйне мәдрәсәдә уздыралар иде. Боларның да җәй көненнән көткән мәнфәгатьләре була.

**Җәйге мәдрәсәләр.** Кайбер мәдрәсәләр кыш көннәрендә башлангыч мәктәпкә әйләнәләр. Җәй көннәрендә гөрләгән мәдрәсәгә әйләнәләр. Мондый мәдрәсәләрдә пәскадәмнәр булмый. Монда сакаллы, мыеклы зур кешеләр генә була. Шуның белән бергә, бу мәдрәсәнең шәкертләре ел саен алмашынып тора. Быел булган

---

[1] Чутай Мостафа – XIX гасыр ахырында үзенең хәттатлыгы белән мәшһүр шәхес. Аның хакында Г. Рәхим, Г. Газизнең «Татар әдәбияты тарихы» (1922–1924) китабында да телгә алына.

[2] Кыйвам кари – каллиграф, педагог һәм фотограф Кыйвам карый (Кыйваметдин) Камаледдин улы Зөлфәкаров (1870–1921).

шәкерт киләсе ел бу мәдрәсәдә күренми. Бу мәдрәсәләрдә беррәттән ике ел булган шәкерт аз очрый.

Бу җәйге мәктәпләрдә фәкать Коръән һәм Коръәнчә турыдан-туры бәйләнешле әйберләр генә укыла. Монда укыла торган әйберләрнең кайберләре түбәндәгеләр:

1. Коръән укыла һәм Коръән ятлана.
2. Тәҗвид укыла, кыйраәт сәбгы[1] белән таныштырыла.
3. Мәкам – көй өйрәнелә.

Мондый мәдрәсәләрнең иң атаклысы һәм зурысы хәзерге Татарстанның Буденный районы Иске Шәйморза авылында иде. Әбү-Бәкер хәзрәт тарафыннан оештырылган бу мәдрәсәдә һәр җәй 100–150 чамасы укучы була иде. Бу мәдрәсәдә Себер, Төркестан, Волга буе, Казакъстан, Башкортстан, Кырым һәм Кавказдан шәкертләр була иде. <…>

***Мәдрәсәләрдә дин, дини гыйбадәтләрне үтәү һәм дәһрилек***

Борынгы татар мәдрәсәләре һичсүзсез дини. Мәдрәсә мулла, мөәзин һәм дини галимнәр әзерли иде. Мәдрәсә дини булгач, мәдрәсәдә дини фәннәр төп фәннәр булып торырга, дини кагыйдәләр ныклы күзәтү астында күтәренке игътибар белән үтәлергә тиеш була иде. Кыскасы, мәдрәсәдәге барлык эш дин күзлегеннән чыгып эшләнергә тиеш иде. Ләкин дин һәм дингә караш мәсьәләсендә мәдрәсәләр бер-береннән шактый аерылалар.

Хәлфәләр дәресе дә, хәзрәтләр дәресе дә кискен бер вакыт белән чикләнми.

Кайбер мәдрәсәләрдә диннең үзенә дә, дини кагыйдәләрнең үтәлешенә дә нык игътибар бирелми. Шәкертнең динендә дә һәм дини гадәтләрне үтәвендә дә беркемнең катнашы юк. Ә кайбер мәдрәсәләрдә дин һәм дини мәсьәләләр көчле режимга куелган. Дин һәм дини эшләр көчле контроль астында тора. Мондый мәдрәсә шәкертләре дөрес игътикадлы булырга, биш вакыт намазны калдырмаска, дингә һәм дини гореф-гадәтләргә хөрмәт белән карарга тиеш иде. Кайбер мәдрәсәләр дин өстендә артыкка китеп, фанатизм дәрәҗәсенә җитәләр. Мондый мәдрәсәләрдә тәсаувыфка – суфичылыкка да зур урын бирелә иде. Мәдрәсәләр арасында дин һәм дини мәсьәләләргә төпле бер карашка ия булмаган мәдрәсәләр дә бар. Татарда бер мәкаль бар: «Май чүлмәге тышыннан билгеле» диләр. Шуның шикелле, татар шәкерте дә тышыннан билгеле. Шәкертнең

[1] Кыйраәт сәбгы – Коръән укуның 7 төрле ысулы.

йөзенә, өс-башына карап, аның кайсы мәдрәсәдән булганын белеп була иде. Казан шәһәрендә 10–12 ләп мәдрәсә булса, алар эчендә дин мәсьәләсе буенча төрле типтагы мәдрәсәләр бар. Мисал өчен, берничә мәдрәсәне алыйк.

**Күл буе мәдрәсәсе.** Бу мәдрәсәнең шәкерте динле, намаз укый, руза тота. Дин һәм дини гореф-гадәтләргә хөрмәт белән карый. Мәчеткә йөрү шәкертнең үз ихтыярында. «Бу намаз калдырмый, мәчеткә йөри» яки «бу намаз укымый, мәчеткә йөрми» дип, ике төрле шәкерткә ике төрле бәя бирелми.

**«Халидия» мәдрәсәсе**. Берничә бүлмәдәге шәкертләр динле, биш вакытны калдырмыйлар, руза тоталар. Мәчеткә йөрү ихтыярлы. Башка берничә бүлмәдәге шәкертләр, фанатик динче булу өстенә, тәсаувыфка бирелгәннәр. Биш вакыт мәчеттә үтәлә. Һәрбер эш дога белән башлана, дога белән тәмамлана.

Шул ук мәдрәсәнең берничә бүлмәсендә башка тип шәкертләр тора. Болар дин белән уйныйлар, намаз укымыйлар, хәтта бүлмәдә намаз укучыга штраф салалар. Араларында руза тотучылар да чамалы. Мәдрәсә җитәкчеләре бу хәлгә әйләнеп тә карамыйлар.

Борынгы татар мәдрәсәләре дини булуга карамастан, дини дәресләргә бик аз игътибар ителә иде. Мәдрәсәләрдә дин дәресе буларак кәлям һәм ысуле фикъһ укылса да, шәкертләр фикъһ белән бик өстән генә таныш булалар. Кыскача әйткәндә, мәдрәсәләрдә фикъһ дәресе йомшак куелган иде.

Шәһәр мәдрәсәләренең күбесенең шәкертләр арасында «Дәһрилек чоры» дип атала торган бер чор була. Бу чорда шәкерт чәч үстерә, чәчне сулап, төкерекләп (кәләпүшне басып киеп) артка җибәрә. Шәкерт кеше күзенә яланбаш күренергә тырыша. Dингә каршы сүз сөйләүне гадәт итә. Дини гыйбадәтләрне куеп тора. Шәкертләр арасында була торган бу чор мантыйк яки хикмәт укый торган вакытка туры килә иде. Менә шушы дәһрилек чоры мәдрәсәләрдә кагыйдә рәвешенә кергән иде. Шуның өчен дәһриләр турында бертөрле дә чара күрелми.

Шәкерт яшүсмер дәверендә фикъһка әһәмият бирми. Фикъһ кагыйдәләрен укып түгел, бәлки телдән телгә ишетеп кенә белә. Шәкертнең яшүсмер дәвере үтеп, мулла булыр вакыты килеп баса. Хәзер муллалыкта тамга җыелган. Духовное собраниегә барып, имтихан бирәсе бар. Имтиханда беренче урынны фикъһ ала. Имтиханда шәкерткә 100 сорау бирелсә, шуның 60–70% ы фикъһ мәсьәләсе була. Шәкерт шушы дәрәҗәгә килгәч кенә, шушы

вакытта гына фикъһның кирәклеген аңлый. Шушы вакытта гына фикъһ укырга керешә иде.

***Мәдрәсәләрдә әхлак мәсьәләсе***

Халык арасында элек-электән мәдрәсә шәкерте «җир фәрештәсе» дип йөртелә. Мондый исем алуның сәбәбе билгеле. Мәдрәсә эчендә дин һәм дини кагыйдәләр белән бәйләнеше бик түбән булган шәкерт тә моны халыкка сиздерми. Халыкка үзен динле һәм дин өчен шәһид булырга хәзер торган итеп күрсәтә. Хәтта «дәһрилек дәвере»ндә торган бер шәкерт тә, халык масса белән очрашканда, үзен чеп-чи динче, дин өчен көрәшүче итеп күрсәтә.

Мәдрәсәләрдә исерткеч кулланучылар шактый була. Кайбер шәкертләр тәмәке дә тарталар. Әфьюн кабучы, тел астына салучы һәм тәмәке иснәүчеләр дә аз булмый. Хатын-кыз белән мөнәсәбәт тотучылар да бар. Ливата мәдрәсәдә киң урын ала иде. Ләкин бу эшләр бары да мәдрәсә эчендә генә кала, тышкы массага чыгарылмый.

20–30 яшендәге сау-сәламәт кешенең җенес органы таләпсез була, төрле ят күренешләргә яки ливатага бирелә, яки фәхешханәләргә йөрүне гадәт итеп ала. Ир хатыннары, асраулар, тол хатыннар белән бәйләнеш тоткан шәкертләр арасында тәтәйләр белән эш итүчеләр була. Суфыйлык һәм тәкъвалык сөюче зур шәһәр шәкертләре арасында ят гамәлләр көчле була иде.

Мәдрәсә легендасы: Гәрәй – янып тора торган егет, пишкадәм. Белем ягыннан да көчле шәкертләрдән санала. Гарәп хәзрәт дәресенә бер вакытта да буш керми, аз гына булса да «төшереп-сугып» керә. Гәрәйнең сәгатьләп-минутлап эшләнгән бу гадәтен шәкертләр белә. Ләкин берәү дә бер сүз әйтми.

Гәрәйнең еллар буенча сузылган бу гадәте хәзрәт колагына чагыла һәм хәзрәт бу эшнең торышы белән кызыксына. Яшерен генә тикшерә-кызыксына торгач, «төшерү»нең сәгать-минутлары да билгеләнә.

Хәзрәт бүген көндәгегә караганда 4–5 минут элек керә һәм туп-туры Гәрәй бүлмәсенә юнәлә, бүлмәне ачып керә. Гәрәй, хәзрәтне күрү белән, стакандагы аракыны китап белән бастырып куя, яшерә. Ләкин хәзрәт стаканны күреп кала. Нәтиҗәдә хәзрәт белән Гәрәй арасында түбәндәгечә сүз башлана:

Хәзрәт *(бармак белән китапка төртеп)*. Ахмак, бу нәрсә! – ди.

Гәрәй *(бер дә каушамыйча)*. Сәттарел гоюб – гаепләрне яшерүче, – ди.

Хәзрәт *(аракыны күрсәтеп)*. Сафсата, бусы ни! – ди.

Гәрәй *(туп-туры хәзрәткә карап).* Бусы – кашшәфел колүб – күңелне яктыртучы, – ди дә, аракыны кулына ала.

Хәзрәт *(Гәрәйгә карап).* Аллаһ гаффар әз-зөнүб[1], – ди дә аракыны эчеп җибәрә һәм, «Хуш» дип, бүлмәдән чыгып китә. Шул көннән башлап, Гәрәй мәдрәсәдә күренми, юк була. Бу вакыйганы Казандагы Күл буе мәдрәсәсендә булган, диләр.

***Борынгы мәдрәсәләрдә кушамат***

Борынгы мәдрәсәләрдә кушаматсыз шәкертләр бик аз була торган иде. Кайбер шәкертләргә кушаматны тышкы күренешенә, кыяфәтенә карап кушалар. Мондый кушаматлар бик тиз арада тагыла. Ә кайбер шәкертләр кушаматны мәдрәсә тормышында очраклы рәвештә ала торганнар иде. Ничек кенә булмасын, шәкерт мәдрәсәдә кушаматсыз кала алмый. Кайбер шәкертләргә кушамат зур тантана – торжество белән кушыла. Мәдрәсәләрнең һәрберендә кушамат тагу белән кызыксынган берничә шәкерт була. Тантана белән тагыла торган кушамат шушы шәкертләр тарафыннан эшләнә. Яңа килгән шәкертләргә кушамат тагу шәкертләр арасында кызык бер эшкә хисаплана.

Шәкертләр арасындагы кушаматларны берничә төргә бүләргә мөмкин. Алар түбәндәгечә:

1. Чутыр Сабир, Сукыр Садыйк, Чукрак Гали, Кылый Саттар, Борынсыз Вәли, Чулак Садри, Чатан Хәйри һәм Борын Гыйльман (зур борынлы) шикелле шәкертләрнең табигый кимчелекләренә карап тагылган кушаматлар.

2. Куян Сәгъди, Шүрәле Шәмси, Бәкар (сыер) Фатих, Сволочь Сәгъди, Марҗа Кәрим, Бозау Кадир, Нури маймыл, Әтәтән Шакир шикелле шәкертнең табигать һәм хәрәкәтенә карап бирелгән кушаматлар.

3. Әхиш Вафа, Бухмир Фатих, Такы Зариф, Котыр Шиһап, Әчти Җәмали шикелле очраклы кушаматлар.

4. Бугавыз Вәли, Күтәнсез Зариф, Тычкак Закир, Ыштансыз Хәйри, Хонса Кәрим шикелле кимсетү, хурлау кушаматлары.

5. Урыс Фатих, Ялкын Сафа, Матур Бари, Йөгереп Сәгъди, Керәшче Хәмит, Кыйгач Сәлим, Файласуф Хәйдәр шикелле мактау кушаматлар.

Кушамат нинди генә булмасын, ул шәкертләр арасында аерымлык билгесе булып санала, шәкерт белән бергә үсә, шәкерт белән бергә гүргә керә иде.

[1] Аллаһ – гөнаһларны ярлыкаучы.

***Кушамат тагу тантанасы***

1) Фәхри белән Хәйри мәдрәсәдә кушамат тагу белән кызыксынган шәкертләрдән санала. Бу ике кушаматчының яңа килгән шәкертне күрү белән йокылары кача. Алар төннәрен йоклый алмыйлар. Төннәре кушамат эзләү, оештыру, планнар төзү белән үтә.

Көз көне, сентябрь ахырлары. Шәкертләрнең күпчелеге мәдрәсәгә тупланган. Тик кайбер малайлар белән зәкят козгыннары гына килеп җитмәгәннәр.

Фатих әтисе белән мәдрәсәгә килеп керде. Алар беренче кеше – Фәхригә очрадылар. Фәхри, Фатихны күрү белән, «яңа кош, хәзерләнергә кирәк» дип куйды. Яңа кош килү хәбәре кушаматчыларның бөтенесенә иреште. Тикшеренә торгач, Фатихның Хәбир хәлфәгә беркетелгәнлеге дә аңлашылды.

Хәбир хәлфә мәдрәсә тормышын бик яхшы белә. Фатихның кушаматсыз калуына ышанмый да, ул тик кушаматның тантана белән кушылуына гына каршы торырга исәпли. Моны булдырырмын дип уйлый. Шул уңай белән, ул үз шәкертләренә кисәтү ясап куйды, алардан вәгъдә алды, «Фатихны саклагыз», – диде.

Фатихны кушаматчылар кулына төшүдән 10–15 көн саклый алса, Фатихның тантанадан котылачагына ышанып була. Хәбир хәлфә шул фикердә. Шул фикер аркасында, Фатих, вакытлы булса да, хәлфә бүлмәсенә алынды. Хәбир хәлфәнең рөхсәтеннән башка бүлмәдән чыгып йөрмәскә кушылды. Ләкин моның сәбәбе Фатихка әйтелмәде.

Көннәрнең берендә Хәбир хәлфә ябык бер хат алды. Зур конверт эченә салынган кечкенә генә бу хатны китерүче билгеле түгел иде. Хатта болай язылган:

Без ки гыйззәтлү Хәбир әфәнде! Сәлам бәгъдендә кәлам будыр. Мин Горьев шәһәреннән килгән сәүдәгәрмен. Казан шәһәренә товар алмак касды[1] белән килгән идем. Сезгә җизнәгез Зәйнулла әфәндедән әманәт бар иде. Эшем күп булганга, үзем бара алмыйм. Рәхим итеп, шул әманәтне бүген нәкъ сәгать 5 тә килеп алсагыз иде. Адрес: Печән базарында 10 нчы йорт.

Хәбир хәлфә хатны укып чыкты да кәгазьнең икенче ягын әйләндереп карады. Хатның бу ягында кызыл карандаш белән зур итеп «Бухмир» дип язылган иде: бу сүзгә Хәбир хәлфә бертөрле әһәмият бирмәде.

---

[1] Касды – нияте.

Кич сәгать биш чамасы иде, бер төркем шәкерт кызуланып йөри, нәрсәгәдер әзерләнә. Боларның башында Фәхри белән Хәйри тора иде. Чалмалар, чапаннар әзерлиләр иде, эш рәтләнде.

Сәгать алтылар чамасы. Бүлмәдә Хәбир хәлфә юк, ул Гурьев бае янына киткән иде. Бүлмәгә бер шәкерт керде, «казый чакыра» дип, Фатихны үзе белән алып чыгып китте. Бүлмәдәге шәкертләр ләммим әйтмәделәр, тик елмаеп кына калдылар.

Бу вакыт түбән каттагы малайлар бүлмәсе суд залына әйләндерелгән, өстәлләр-урындыклар куелган. Казый һәм хәлфәләр үз урыннарын алганнар, бүлмә идәне шыгрым булып шәкерт белән тулган иде. Шәкертләр арасына алгы сафка Фатихны да тезләндерделәр. Шул арада бүлмә ишеге ачылды, баш казый керә, диделәр. Ишектән урта яшьле, зур гәүдәле өлкән казый килеп керде. Бөтен шәкертләр аякка тордылар. Өлкән казый, урынына утыргач, озын итеп дога кылды. Моңа шәкертләр дә катнаштылар, кул күтәрделәр.

Өлкән казый: «Яңа килгән шәкерт кайда, кем ул?» диюгә, Фатихны күрсәтәләр, Фатихтан түбәндәгечә сорау башлады:

Казый: Исемең ничек?

Шәкерт: Фатих.

Казый: Атаңның исеме?

Фатих: Нурмөхәммәт.

Казый: Фамилияң ничек?

Фатих: Шаһиев.

Шул арада шәкертләрдән берсе: «Казый әфәнде, ул бүлмәгә кергәндә сәлам бирмичә керде», – диде. Икенчесе: «Аның тәһарәте дә юк әле», – дип өстәде. Фатихка бүлмәдән чыгарга, сәлам биреп, бүлмәгә яңадан керергә кушылды.

Фатих бүлмәгә кергәндә, ишек төбенә комган белән ләгән куелган иде. Хәзер Фатих ике зур эштән котылды. Сәламле дә, тәһарәтле дә булды. Сорау яңадан башланды.

Казый: Семьягызда ничә кашык?

Фатих: Алты кашык.

Казый: Кемнәр?

Фатих: Әти, әни, мин, апа, энем, сеңлем.

Казый: Әтиең ничә яшьтә?

Фатих: Белмим.

Казый: Әниеңнең яшен беләсеңме?

Фатих: Юк.

Казый: Апаң ничә яшьтә?

Ф а т и х : Утыз алтыда.

Бер дә көтмәгәндә казый Фатихка «Тугыз җирдә тугыз ничә?» дип сорау бирде. Фатих «белмим» диюгә, шәкертләр арасыннан берсе «81» дип кычкырды.

К а з ы й : Бер кәгазьгә язып куй шул сүзне, – дип, Фатих кесә дәфтәренә язып куйды.

К а з ы й : Казанга нәрсә белән килдең?

Ф а т и х : Пароход белән килдем.

К а з ы й : Нинди пароход белән килдең?

Ф а т и х : «Бухмир» пароходы белән килдем.

Шул арада шәкертләр арасыннан берсе «Тәкъсир, аның исемен мулла кушмаган икән, хәбәр килде», – диде. Сүзне ишетү белән, казый Фатихка кайтып китәргә туры киләчәген белдерде. Исемен мулла кушмаган шәкертләрнең мәдрәсәгә кабул ителә алмаганлыгын белдерде. Бу Фатихка нык тәэсир итте. Еламакчы булды, күзеннән яшьләре чыга.

Шул арада шәкертләр арасыннан берсе. «Тәкъир, шул ук исемне, хәзер үзегез кушып, Фатихны мәдрәсәдә калдырырга мөмкин булмасмы?» – диде. Моңарга башка шәкертләр дә кушылалар.

«Яңа туган балаларга исем биргәндә, баланы идәнгә яткызалар, зур кешегә исем кушканда, ул кеше кыйблага каршы басып торырга тиеш», – диде казый.

Кыйблага каршы баскан Фатихка карап, казый азан әйтте, кул күтәреп дога кылды, шәкертләр дә моңа кушылдылар. Шул арада шәкертләрдән берсе «Тәкъсир, исеме ничек булды?» – диде. Шул сорауга каршы казый: «Үзенең исеме Бухмир, атасының исеме Таттыфа (ты x ты = 81)[1] булды», – диде.

Казыйның шул сүзе ишетелүгә, шәкертләрдә дөрләп кузгалу башланды, тавыш күтәрелде. Шул арада шәкертләрдән берсе: «Бухмир, Хәбир хәлфә чакыра», – диде. Тагын берсе: «Таттыфага сәлам яз», – диде. Тагын көлү башланды, тагын каһкаһә күтәрелде.

Фатих каридорга чыкты. Монда «Бухмир» белән «Таттыфа» хор белән кычкырылды. Фатих баскычтан күтәрелде, югары коридорга чыкты. Тавыш тукталмады, «Бухмир» белән «Таттыфа» тәсбих урынына тезелде.

[1] Гарәп телендә саннар аерым бер хәрефләр белән билгеләнә. 9 санына ط (та) хәрефе туры килә. 9×9=81. Шушы система буенча 81 – ف һәм ا хәрефләре белән бирелә. Шул рәвешле, 9×9=81 не «татафа», сөйләмгә яраклаштырып, «таттыфа» рәвеше килеп чыга.

Хәбир хәлфә бүлмәсенә кайтып кергәндә, Фатих үксеп елап утыра иде. Хәбир хәлфә, бу хәлне күрү белән, мәсьәләне аңлады. Хатның нинди теләк белән язылганын төшенде. Ләкин хәзер вакыт үткән иде. Көннәр, еллар үтте. Фатих пишкадәм булды, мулла булды, балалар үстерде һәм үлде. Кушамат аның белән гүргә керде.

1. Харисны хәзрәт Сәгъди хәлфәгә бирде. Сәгъди хәлфә Харисның кушаматчылар кулына төшүеннән әмин түгел. Шуның өчен ул Хариска килгәннең беренче көнендә үк: «Энем, сак бул, үзеңә кушамат чыгармасыннар. Чит бүлмәгә чакырсалар да барма, бүлмәдән күп чыгып йөрмә», – дип кисәтү ясап куйды. Сәгъди хәлфә Харисның үзенә кисәтү ясау белән генә калмады, үз шәкертләренә дә, урындаш малайларга да әйтеп куйды. «Хариска күз-колак булыгыз», – диде.

Кушаматчылар Харисны күп күзәттеләр. Ләкин тантана белән кушамат бирә алмадылар. Харис кулга төшмәде.

Мәдрәсәнең ял көне җомга көн иде. Мәдрәсә кухнясы шәкерт белән шыгрым тулы. Һәркем бер эштә. Шәкертләр тавышыннан кухня шау килә. Харис та кухняда кем беләндер аш әзерли.

Кухняга эре гәүдәле, зур чалмалы бер кеше кереп сәлам бирде. «Әссәламегаләйкем!» – диде. Кухняда кинәт тавыш булды, һәркем баскан урынында катып калды. Шәкертләр бер-берләренә караштылар да «яшь хәзрәт» диештеләр. Харис та шулай дип аңлады, яшь хәзрәт керде дип белде.

Хәзрәт шәкертләрдән комган, сөлге сорады. Шәкертләр бердәм бу эшне Хариска куштылар: «Сөлге белән комган китер», – диделәр.

Хәзрәт тәһарәт алганда, Харис комганнан су салып торды, хәзрәт кул-йөз сөрткәндә сөлге тотты. Хәзрәт тәһарәттән бушап, киемен киеп алгач, кул күтәреп кычкырып догага керешге. Шәкертләр дә кул күтәреп, «амин» дип тордылар. «Амин» тавышлары арасында Харис тавышы да бар иде. Ул да «амин» диде.

Хәзрәт Харисның башыннан сыйпады: «Исемең йомшак булсын, Ходa йомшак җирләреңне тик тотмасын», – диде. Шәкертләр арасыннан берсе: «Кай җире йомшак соң аның?» – диде. Моңар каршы хәзрәт: «Эзләсәгез табарсыз», – диде. Шул сүз бетүгә, кухняда зур тавыш, кычкырып көлү башланды. Шушы шау-шуга чалмасын болгап, хәзрәт тә кушылды. Кухнядагы шәкертләрнең яртысы «йомшак җир» эзләргә тотынды. Харисны уртага алдылар, кухняның бер очыннан икенче очына йөрттеләр. Ай-ваена куймадылар.

Сәгъди хәлфәнең башы күренү белән, кухня тып-тын булып калды, һәркем үз эшендә. «Кем моны эшләде, Харис кайда?» – диде

Сәгъди хәлфә. Беркем бертөрле дә җавап бирмәде. «Йомшак Харис» бер кырыйда үксеп елап тора иде.

***Мәдрәсәләрдә күңел ачулар***

Борынгы мәдрәсәләрдә күңел ачу кичәләре, күңел ачу мәҗлесләре дә була торган иде. Шәкертләр бу мәҗлесләрне «хозур» дип атыйлар. Гадәттә, хозурлар кыш көне мәдрәсәнең үз эчендә, җәй көннәрендә урманнарда, болыннарда һәм су буйларында оештырыла иде. Казан, Уфа һәм шуңа охшаган зур шәһәрләрдә кышкы хозурлар мәдрәсәләрдә бик аз очракларда гына эшләнә иде.

Мәдрәсәләрдәге хозурлар берничә төрле уңай белән үткәрелә:

*1. Акчалы хозурлар*. Озын һәм каты кыш көне көчле уку бара. Хәлфәләр дә, шәкертләр дә арыганнар, ялыкканнар. Шәһәрдә ял бирерлек, күңел ачарлык бер урын да юк. Яки шәһәрдәге күңел ачу урыннарына шәкертләргә керергә мөмкин түгел. Менә шул яклардан чыгып, шәкертләр мәдрәсәләрнең үзләрендә күңел ачуны уйлап чыгарганнар. Моның өчен шәкертләр үзара акча салышалар, комиссия сайлыйлар.

Гадәт буенча хозурларның ашау-эчү бүлегенә хәлфәләр һәм пишкадәмнәр генә катнаша алалар. Түбән дәрәҗәле шәкертләр катнаштырылмыйлар иде. Катышырга ярамаганны пәскадәмнәр үзләре дә ачык беләләр. Хозурның икенче бүлегенә – уен-көлке бүлегенә мәдрәсәнең барлык шәкертләре катнашырга хаклы иде.

Хозурның ашау-эчү бүлеге иң кимендә 15–20 тиенгә төшә. Хәлбуки бу акча шәкертләрнең күбесендә булмый. Кулында акчасы булганнары да мондый зур расходларга керергә теләмиләр. Шунлыктан хозурларның сыйлану өлешенә күп шәкерт катнаша алмый.

Хозурның ашау-эчү бүлеге дә, уен-көлке бүлеге дә һичбер вакыт музыкасыз үтми – скрипка яки гармун була. Шәкертләр арасында оста җырчылар, биючеләр һәм талантлы комик-көлдергечләр дә табыла.

Хозурлар хәзрәтләрдән һәм халыктан яшерен эшләнә. Шунлыктан хозур капка-ишекләрне бикләп, тәрәзәләрне томалап, эчке биналарда гына үткәрелә иде. Гадәттә, хозурлар кичке сәгать 8–9 ларда башлана, төнге сәгать 1–2 ләрдә тәмам була.

*2. Кияү хозурлары, кәләш туе.* Мәдрәсәнең берәр шәкерте мулла булып чыга. Берәр бай мулла кызына яки берәр зур бай кызына өйләнә, остабикәле була. Мәдрәсә гадәтенчә, мондый шәкертләр мәдрәсәгә килеп, иптәшләрен-шәкертләрне сыйларга тиеш. Мәдрәсәдә үткәзелә торган мондый хозурларга «Чәкчәк мәҗлесе» диләр

иде. Чөнки бу мәҗлескә кияү хәзрәт чәкчәк алып килгән була. Бу хозурлар да, акчалы хозурлар шикелле үк, зур тантана белән үтә, хозурларның барлык чыгымнары кияү тарафыннан тотыла.

Мондый хозурларның беренче бүлегенә (ашау-эчү бүлегенә) хәзрәтләр, мөәзиннәр һәм кайбер чит кешеләр дә чакырыла. Гадәттә, мондый чит кунаклар аерым биналарга яки аерым бүлмәләргә утыртылалар.

Ашау-эчү тәмам булганнан соң, киленне бүләклиләр. Мәҗлескә катнашучылар тарелка-бүләк салалар. Бүләк акчалата да була, әйберләтә дә ярый.

Мәдрәсәнең серен читкә белдерергә мөмкин түгел. Шуның өчен һәрбер уенчыны мәдрәсәгә кертеп булмый. Мәдрәсәгә керә торган уенчы сер саклый торган, хозурларда булган уен-көлкеләрне гаеп итми торган булырга тиеш. Шуның белән бергә, уенчы кичәдә актив катнаша белә торган кеше булырга кирәк.

Шәһәрнең үзендә яки күрше авылда шундый уенчылар була торган иде. Шәкертләр менә шундый уенчылардан файдаланалар. Шәкертләр гармунга караганда скрипканы артык күрә, чөнки скрипканың тавышы еракларга китми.

*3. Никрут-рекрут хозуры.* Мәдрәсәдә быел ничә шәкерт гаскәргә каралачак? Алар, хәзер каралу өчен, авылларына кайтып киткәннәр. Менә бу каралучыларның тәмам котылучылары мәдрәсәдә хозур ясап, шәкертләрне сыйларга тиешләр. Бу хозурның чыгымнары каралучылар кесәсеннән тотыла.

*4. Нәзер хозурлары.* Шәһәрнең яки мәхәлләнең берәр кешесе, берәр эш уңае белән нәзер әйтә: «Эшем мин әйткәнчә, мин теләгәнчә булып чыкса, шәкертләргә бер үгез (яки башка нәрсә) кертер идем», – ди. Шәкертләрнең бәхете җиңә, мәдрәсәгә үгез яки тана кертелә. Үгез үзе генә булмый, аның янында бер-ике сум сәдакасы да була. Үгезне суеп, тиресен саткач, аңарга бер-ике сум сәдаканы да кушкач, бу акчага дөге дә, чәй, шикәр дә, бал да, күмәч һәм чикләвек шикелле продуктлар да алып була. Скрипкачыга түләргә дә кала. Бугазлаучы, тунаучыга һәм пылау пешерүчеләргә «нисыфлык» та кала. Аллаһ ризалыгы өчен бирелгән нәзерләр исәбенә типтерүне шәкертләр «нәзер хозуры» диләр иде.

*5. Җәйге хозур.* Укулар тукталу уңае белән шәкертләр таралган. Мәдрәсәдә җәйге шәкертләр генә калган. Алар да күп түгел. Утыз-кырыктан артмый. Вакыт май ахырлары, июнь башлары. Кайсыдыр бер шәкерт хозур турында сүз кузгата.

Шәкертләр арасында оста җырчылар, матур биючеләр шактый күп була иде. Гадәттә, хәлфәләр җырламыйлар да, биимиләр дә. Кечкенәләр алдында җырлау, бию дәрәҗәне төшерү дип карала.

Бу сүз яшен тизлеге белән шәкертләр арасына тарала һәм шәкертләр тарафыннан яхшы каршы алына. Озак та үтми, хозур комиссиясе сайлана. Комиссия әгъзалары кулына иганә, ярдәм туплау листы бирелә. Бу лист хәзрәтнең печате белән расланган була.

Йорттан йортка, кибеттән кибеткә йөри торгач, хозурга җитәрлек акча да, продукт та туплана.

Атна-ун көнгә сузыла торган бу хозур шәһәрдән еракта, урманда яки су буйларында, тугайда оештырыла.

Мондый тантаналы хозурларга хәзрәтне дә һәм шәһәрнең могтәбәраны да (билгеле кешеләре) чакырыла. Кунаклар киләсе көндә музыка яшерелә, җыр һәм биюләр туктатыла. Моның урынына милли уеннар оештырып, Сабан туе төсе бирелә иде.

Хозурларда исерткеч эчү, тәмәке тарту рөхсәт ителми. Бу турыда мәдрәсәдә кисәтү ясап куела. Шуңа карамастан шәкертләр дә, хәлфәләр дә аракы һәм тәмәкесез хозурга чыкмыйлар иде. Соңгы елларда хозурлар башыннан ахырына кадәр исереклек белән үтә иде.

Мәдрәсәләрдәге җырлаулар хатын-кыз тавышы белән нечкә итеп башкарыла иде. Җырлаучыларның тавышы никадәр нечкә булса, шулкадәр сөеп, яратып тыңлана. Бу хәл мәдрәсәдә генә түгел, бөтен татар галәмендә шулай, мондый вакытларда калын тавыш белән җырлау авыл яшьләре арасында гына була.

1912 елларда булса кирәк, Троицкиның Мирфәйзә дигән бер татар җырчысы Оренбургта концерт бирде. Татарлар тарафыннан зур алкышларга очраган бу концертка рус халкы бик зур гаҗәпсенү белән караган иде. Көрәк шикелле сакалга ия булган бер абзыйның хатын-кызлар тавышы белән җырлавы һәм җыр арасында иңбаш-күкрәкләрен сикертүе шаккатмаслык түгел иде.

Кайбер мәдрәсәләрдә хозурларның уен-көлке бүлегендә көлке һәм тәнкыйть бүлекләре дә була, шул уңай белән төрле инсценировкалар оештырыла. Бу инсценировкаларда байлардан, мещаннардан һәм мужиклардан көләләр, аларны тәнкыйть итәләр.

Мәдрәсәдә нинди генә хозур оештырылмасын, аның икенче бүлегенә – уен-көлке бүлегенә зур-кечкенә һәрбер шәкертнең катнашырга хакы бар.

Хозурларның уен-көлке бүлегенә яшь шәкертләр актив катнашалар иде. Җырлау-биюнең зур бер өлеше яшьләр өстенә төшә. Мо-

ның өчен яшь шәкертләр шелтәгә һәм җәзага тартылмыйлар. Хозурда эшләнгән барлык эш шунда кала, соңыннан искә-телгә алынмый.

Хатын-кызлар киеме киеп бию яки җырлауны хәлфәләр дә һәм пишкадәмнәр дә яратып карыйлар, сөеп тыңлыйлар. Шуның өчен кайбер шәкертләр хатын-кызлар киеме киеп җырлыйлар һәм бииләр иде.

<...>[1]

***Борынгы мәдрәсәләрдә сәнгать һәм иҗат эшләре***

Борынгы мәдрәсәләрдә сәнгать һәм иҗат эшләре дә була иде. Аерым үзенчәлеккә ия булган бу эшләрне түбәндә күрсәтәбез:

1. Матур язу. XVIII йөзнең югары ягында мәдрәсәләрдә басма китаплар күренмәде. Шуның өчен дә шәкертләр үзләренә кирәк булган китапларны үзләре язалар, ягъни яздыралар иде. Шушы уңай белән шәкертләр матур язуның әһәмиятен аңлыйлар. Шунлыктан шәкертләр арасында матур язучылар шактый күп була. Кайбер мәдрәсәләрдә язу өйрәтүчеләр һәм башкаларга язып көн күрүчеләр дә була иде.

Борынгы мәдрәсәләрдә куллана торган язулардан күп кулланыла торганы «тәгъликъ», аннан кала «нәсех» иде.

2. Китап төпләү. Борынгы мәдрәсә шәкертләре арасында китап төпләү – переплет эшен белүчеләр дә була иде. Мәдрәсәдә язылган китапларның күпчелеге мәдрәсәнең үзендә төпләнә, шәкертләр арасында картон, чуар кәгазь язучылар да була иде.

3. Шәмаилләр язу. Стенага тагар өчен матур итеп, бизәкләп язылган язуларга «шәмаил» диләр иде. Шәмаилләрнең эчтәлеге Коръән аятьләреннән тора. Төрле догалардан төзеп ясалган шәмаилләр дә була иде. Казан дәүләт университеты көтепханәсендә берничә шәмаилнең кульязмалары саклана.

Менә шундый шәмаилләрнең шактый күп өлеше мәдрәсәләрдә эшләнә иде. Гадәттә, шәмаилләр кәгазь һәм пыялага языла.

4. Борынгы шәкертләр арасында сәгать төзәтүчеләр, кечкенә механизм белән эш итүчеләр дә булгалый иде. Һәвәскәрлек нигезендә башланган бу һөнәр кайбер шәкертләр өчен тормыш чыганагы булып та әверелә иде. Казан, Уфа, Оренбург һәм Әстерхан шикелле зур шәһәрләрдәге татар сәгатьчеләренең күбесе элеккеге шәкертләр

[1] Алга таба кульязмада, сөйләгәннәргә мисал рәвешендә, «Шура» журналыннан (1914 ел, № 9) «Хозурга чыккач» исемле мәкалә тәкъдим ителә.

иде. Казандагы Хәлим Минкин[1], Гыйлаҗ Сәйфуллин[2], Габделмән Казанскийлар шәкерттән чыккан сәгатьчеләр иде.

5. Мәдрәсәләр шактый гына сәхнә эшчеләре дә бирде. Артистлардан Кариев[3], Сакаев[4], Кулалаев[5] һәм башкалар мәдрәсә шәкертләре иде.

***Мәдрәсәләрдә рус теле***

Борынгы мәдрәсәләрдә рус теле уку булмады. Рус теле укуны шәкертләр кирәк дип тә белмәделәр. Мәдрәсәләрдә русларга «кяфер» дип карагач, кяфер телен өйрәнүне дә гөнаһ дип санадылар.

Шәкерт мәдрәсә бетереп чыга. Мулла була. Ләкин кечкенә генә бер язарлык русчасы булмый иде. Халык арасында шактый игътибар казанган муллалар да русча язуларын авыл писарьләреннән эшләтәләр иде.

Муллалар кулында хөкүмәт документы – метрика саклана, муллалар метрика буенча халыкка справка бирергә тиешләр. Менә бу справкаларны муллалар авыл писареннән яздыралар һәм һәрбер язу өчен писарьгә акча түлиләр яки писарьне сыйлыйлар иде.

XIX йөз башларында шәкертләр арасында русча хәрефләр белән танышуга кызыксыну башлана. Мәдрәсә шәкертләре арасында русча хәрефләр язу, хәрефләрдән сүзләр төзү шикелле хәрәкәт күренә башлый. Хәзер бу эшкә гөнаһ дигән караш та бетә. Ләкин рус теле мәдрәсәләрдә дәрес булып керми.

...[6] елларда муллалар өчен башлангыч мәктәп күләмен дә русча белү мәҗбүри ителә. Ләкин бу положение дә мәдрәсәләргә рус телен укытуны кертә алмый.

Шәкерткә мулла булырга туры килә. Тамга җыя. Шул арада хосусый рәвештә русча укый башлый. Һәм ай, ай ярымнан соң төрле хәйлә һәм взяткалар белән свидетельство (шәһадәтнамә) ала. Ләкин әле ул рус телен рәтләп аңламый торган була. <...>[7]

---

[1] Хәлим Минкин – сүз XX йөз башында яшәп иҗат иткән музыка кораллары остасы Гариф Минкин турында барса кирәк.

[2] Сәйфуллин Гыйлаҗетдин Гайнетдин улы (1873–1946) – музыка кораллары остасы, халык җырларын туплаучы.

[3] Кариев Габдулла (Хәйруллин Миңлебай Хәйрулла улы) (1896–1920) – актер, режиссер.

[4] Сакаев Нури Нәбиулла улы (1885–1927) – актер.

[5] Кулалаев Әхмәт (1887–1924) – актер, педагог.

[6] Чыганакта дата күрсәтелмәгән.

[7] Кульязманың бер бите юк. Аннан соң килгән текстның эчтәлегенә караганда, әлеге бүлекчәне шартлы рәвештә «Тәрҗеман» газетасы һәм татар шәкертләре» дип исемләргә мөмкин булыр иде.

2) Гомуми бер лозунг табып, шул лозунг астында татар халкын берләштерү, бер авызга карату.

3) Шушы теләкләргә ирешү өчен, яңа тип мәктәпләр – ысуле җәдидә мәктәпләре торгызу. Бу мәктәпләрдә фән укуны көчәйтү һәм рус теленә киң урын бирү.

4) Яшьләрне рус мәктәпләренә күбрәк бирү һәм мәктәпләрнең ишеген татарлар өчен киңрәк ачарга тырышу.

Атаклы татар байларыннан оренбурглы Әхмәт бай Хөсәенов[1] рус һәм еврейларны үзенә зур конкурент дип саный. Татар байларын конкурентларга бирелмәскә өнди. «Урыс һәм еврейлар белән көрәшер өчен, татарлар берләшергә кирәк һәм алар шикелле фән һәм техника белән коралланырга кирәк, шунсыз безгә нәҗат[2] юк», – ди. Шул ук вакытта ул Оренбургта яңа тип «Хөсәения» мәдрәсәсен торгыза. Бу мәдрәсә өчен йөз мең сумнан артык акча тотып, зур бина салдыра һәм җиһазландыра. Һәм шул ук вакытта үз исеменнән хөкүмәтнең урта һәм югары уку йортларында шактый санда стипендияләр билгели, авылларда дистәләрчә ысуле җәдидә мәктәпләре ача. Боларның расходларын үз өстенә ала.

Татар байлары шундый эзләнүләр чорында торган бер вакытта, татар мәдрәсәләренә Кырымда Исмәгыйль бәй Гаспринский тарафыннан чыгарыла торган «Тәрҗеман» газетасы килеп керә. Сембер фабриканты Алиевлар суммасының катнашы белән чыгарыла торган бу газета үзенең битләрендә нәкъ Әхмәт бай әйткән мәсьәләләрне күтәреп чыга: 1) Мәдрәсәләрнең тормыштан артта калулары, аларга реформа кертүнең кирәклеге мәдрәсәләр программасына фән кертеп, аларны яңа ладка[3] салу; 2) Европа һәм рус мәктәпләре тибында яңа мәктәпләр – ысуле җәдидә мәктәпләре барлыкка китерү; 3) Ысуле җәдидә мәктәпләре өчен яңа кадрлар әзерләү; 4) Тумышыннан татар булып туган, татар халкына «Шималь төрекләре» исемен биреп, чепчи төрек теле булган «Тәрҗеман» теле астында берләштерү; 5) Зур культуралы ислам байрагы торгызып, шуның астында җир йөзендәге барлык мөселманнарны бер ноктага туплау һ. б.

Исмәгыйль бәй, бу теләкләргә ирешер өчен, «Тәрҗеман» битләрендә системалы рәвештә түбәндәгеләрне чагылдыра: 1) Төрек, рус һәм Европа мәктәпләре турында хәбәрләр һәм мәкаләләр

[1] Әхмәт бай Хөсәенов (1837–1906) – 1 нче гильдия Оренбург һәм Казан сәүдәгәре.

[2] Нәҗат – котылу, исән калу.

[3] Ладка – рәвешкә.

урнаштыра, аларның программалары белән таныштыра. Педагогика, методика мәсьәләләренә карата мосахәбә-беседалар алып бара. 2) «Тәрҗеман» теленең төрек-татарлар өчен уртак әдәби тел булуы турында озын-озын мәкаләләр урнаштыра. Моңа каршы килүчеләргә каршы көрәш ача (кавказлы Шахтактинскийның чөй язуы турында «Шәркы рус» газетасы белән «Тәрҗеман» газетасы көрәше). 3) Төреклек байрагы астында төрек-татарларның берләшүләре турында фикерләр урнаштыра. 4) Ислам дине белән фәннең кардәш булуы турында хәбәр һәм мәкаләләр урнаштыра. Моны исбат йөзеннән «Дарел-рәхәт мөселманнары» исемендә романнар тудыра. Ниһаять, шул ук максат белән Һиндстанга – Бомбейга, Мисырга – Каһирәгә барып чыга (Бомбейга баруы 1910 ел, Каһирәгә баруы 1907 ел, Төркиядә – Истамбулда булуы 1909 елда), Төркияне зиярәт итә.

Нәкъ шул чорда «Тәрҗеман» газетасының ишарәсе белән мәдрәсә шәкертләре арасында фән укуга таба юнәлеш башлана. Йомшак кына башланган бу фән уку мәсьәләсе, мәдрәсә башында торган мөдәррисләр арасында тынычсызлык тудыра. Бик күп мөдәррисләр бик нык каршы торалар, хәтта бу эшкә дини төс биреп, халыкны өркетергә уйлыйлар. Мөдәррисләрнең бер кадәресе бу эшкә салкынлык, битарафлык күрсәтәләр. Азчылык булса да, кайбер мөдәррисләр бу фикерне алкышлап каршы алалар.

Шул ук чорда, мәдрәсәләргә фән кертү белән беррәттән, әдәби тел мәсьәләсе күтәрелә. Моңа кадәр гарәп, фарсы һәм уйгур сүзләреннән болгатып эшләнгән һәм укымышлылар арасында әдәби һәм гыйльми тел булып саналган чагатай теле үзенең газаматын[1] югалтырга йөз тота. Моның урынына шул ук гарәп, фарсы һәм төрек сүзләреннән файдаланып эшләнгән башка бер тел – «Тәрҗеман» теле көч ала башлый.

Борынгы татар мәдрәсәләрендәге борынгы әдәби тел, әдәби язма үрнәге:

*Газиз әл-кадер кирами вә мөхтәрәми, старший казый вә наибе мәнаб мөфти[2] дамелла Мөхәммәди бине Салих әл-Гомәри җәнабе сәгадәте мәнабләренә, әһле әүладләренә ихтива үзрә бәгъдәс-сәлам сөннәт әл-ислам анки, җәнабе фәкыйрь мелла әл-хәмед вә-л-миннә, шәһре рамазан әл-мөбарәкне хушлык үзрә гезар идеп, мизаҗымыз сахих улды. Ләкин бәгъдә әл- гаед кәефемез тәбәддел табыб, берничә нәхушырак булып торамын. Хак Тәгалә бихәер әйләя.*

[1] Газаматын – көчен, өстенлеген.
[2] Наибе мәнаб мөфти – мөфтинең урынбасары.

*Без бу сәнә гаеде фитырны йәүме дүшәмбе укыдык әһле бәляд көллән вә әһле кора бәгъзан улды, безнең бердә ирадәмез һәм дүшәмбе укырга аслан хөҗҗәтемез юк иде, ләкин меллалар үзләре әксаре иттифакъ идеб, дүшәмбе укымак булыб, күб җиргә әтрафга һәм хәбәр салганлар, әмма безгә бер дә хәбәр итмәделәр вә мәслихәт һәм кылмай тәмам карар виргәнләр, безгә хөҗҗәтләрене һәм күргәзмәделәр, шул әснада казый мелла Җәлалдан телеграф килде бездә гаед сишәмбе дәю...*[1]

«Тәрҗеман» газетасы теле:

*... «Америка вә Аурупада бәгъзе гафиф кадынлар әхлак бозыклыгыйна чара улмак үзрә «тәгаддеде зәүҗати» булыйюр вә буның канунлә мөсагадә иделмәсен матбугат васыйтәсилә эстиюрләрмеш».*

*У нә кадәр вә насыл гафиф кадинлар ки, бөтен әхлаксызлыгын сәбәби улмак үзрә әркәкләре күстриюрлар; буның ичин дә шу әркәкләрә бер кач кадин виреб, әхлаксызлыгын үңене алмак ляземдер диюрләр...»*[2]

Әдәби тел мәсьәләсендә артыкка киткән кайбер тотнаксыз хәлфә һәм шәкертләр без татар түгел, төрек дигән юлга кереп киттеләр һәм татарлыкны үзләренә түбәнлек санау дәрәҗәсенә килделәр.

Фән һәм тел мәсьәләсе белән бер вакытта мәдрәсәләрдә тагын бер яңа мәсьәлә – «рәдде нәсара» – христианлыкны кире кагу мәсьәләсе килеп чыкты. Татарлар белән руслар арасында дини сугышлар тудыру нигезендә кабартылган бу мәсьәлә барлык мәдрәсәләрдә бик зур вакыйга булып каршы алынды. Рәдде нәсара турында уку, рәдде нәсара өстендә диспут һәм моназәрәләргә катнашу шәкертләр арасында зур бәхет булып саналды.

Казан борадәране Кәримовлар тарафыннан контрабандлык юлы белән яшерен рәвештә кертелгән һәм фахиш бәя белән сатылган төрекчә «Рәдде нәсара» китабы мәдрәсәләрдә бу мәсьәләне тагын да куертырга сәбәп булды. «Рәдде нәсара» китабы – рөхсәтсез китап. Аны фаш итү куркынычлы. Шуның белән бергә, бу фикерне барлык шәкертләр белән уртаклашмый да килешми. Менә шул уңайдан чыгып, «Рәдде нәсара»дан өзекләр чыгарыла һәм шәкертләр арасында кулдан кулга күчеп йөри иде.

Мәдрәсәләрдә башланган «рәдде нәсара» кузгалышын Буби хәзрәтләре һәм Уфа Зыя[3] хәзрәт башка бер төскә кертеп җибәрделәр.

[1] Ш. Мәрҗанинең Мөхәммәди казыйга язган хатыннан өзек. *(Авт. иск.)*

[2] «Шура» журналындагы К. Җәмалетдинов мәкаләсеннән өзек. *(Авт. иск.)*

[3] Зыяддин әл-Камали, Зыяэддин Җамалетдин улы Камалетдинов (1873–1942) – мәгърифәтче, фәлсәфәче, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче, мәдрәсә мөгаллиме, «Галия» мәдрәсәсен оештыручы.

Зыя хәзрәтнең «Фәлсәфәи диния»се белән «Фәлсәфәи исламия»се «Рәдде нәсара»ның икенче төрлесе һәм соңгысы иде.

XIX йөзнең соңгы елларында, югарыда әйтеп үтелгән фән уку, әдәби тел һәм «рәдде нәсара» мәсьәләләре кайнап торган бер чорда, Волга буе фабрикантларыннан Акчуриннар[1], Дибердиевлар[2], Себер байларыннан Нигъмәтулла хаҗи[3], Казан тирәсе байларыннан Заһидулла хаҗи Шәфигуллин[4] һәм Оренбург байларыннан Әхмәт һәм Гани бай Хөсәеновлар берничә урында яңа тип ысуле җәдидә мәктәпләре оештыра башлыйлар. Тормышлары шушы байлар белән бәйләнгән муллалар мәхәлләләрен һәм иске тип мәктәпләрен байлар карамагына тапшыралар һәм бу турыда кулларыннан килгән хезмәтләрен тәкъдим итәләр.

Мәдрәсәләрдә кузгалган фән-уку мәсьәләсе хисаптан (күп саннар эчендә) дүрт гамәл, Коръән уку буенча «Карабаш» исемле тәҗвид, тарих буенча «Алты бармак», «Мохтәсар тарихе әнбия», җәгърафия буенча бидаяте җәгърафиядән[5] югарыга күтәрелә алмады.

Мәдрәсәләрдән Оренбургта Галим хәзрәт Дәүләтшин, Казанда Галимҗан хәзрәт Баруди, Троицкида Зәйнулла ишан Рәсүлев мәдрәсәләре һәм шулар кебек тагын берничә мәдрәсәгә реформа кертелде – «ибтидаи», «рөшди», «игъдади» һәм «гали» исемнәре белән дүрт бүлеккә бүленде. Шушы көннән башлап, бу уку йортлары фән укыла торган дини мәдрәсәләргә әйләндерелде.

Бу чорларда реформа кертелгән мәдрәсәләр өчен дә, яңабаштан оештырылган җәдит мәктәпләр өчен дә квалификацияле һәм фән белән таныш профессиональ мөгаллимнәр юк иде. Менә шул якларны уйлап, байлар өметле дип танылган шәкертләрне Мисырга, Истанбул һәм Мәккә, Мәдинә шикелле җирләргә җибәрә башладылар.

1899 елда Оренбург якынындагы Каргалы авылында кыска сроклы укытучылар курсы ачылды. Фән нигезләре белән таныштыру, педагогик һәм методик юллар күрсәтү теләге белән ачылган бу курслар турында карагоруһ муллалар донос ясадылар. Шушы донос буенча, падишаһ хөкүмәте тарафыннан курслар таратылды.

[1] Акчуриннар – Сембер губернасы сәүдәгәр-эшмәкәрләре, Сембер губернасында постау җитештерүне оештыручылар, җәмәгать эшлеклеләре.

[2] Дибердиевлар – сәүдәгәр-эшмәкәрләр, хәйрияче-меценатлар.

[3] Нигъмәтулла хаҗи – сүз II гильдияле сәүдәгәр һәм меценат Нигъмәтулла хаҗи Сәйдуков-Кармышаков турында бара.

[4] Заһидулла Шәфигуллин – Заһидулла Шәфигулла улы Шәфигуллин (1840–1919) – мәгърифәтче, педагог, меценат, җәмәгать эшлеклесе.

[5] Бидаяте җәгърафия – география фәне буенча башлангыч белем.

Хөкүмәт белән эш күрмәгән курсантлар үзләре белгән якка качарга мәҗбүр булдылар.

Мәдрәсәләргә реформа кертү, ысуле җәдидә мәктәпләре торгызу турында сөйләшүләр кайбер урыннарда тыныч кына барса да, практик эш башлагач, аңсыз татар муллалары, карагоруһ татар байлары һәм болар тозагына төшкән хезмәт ияләре бу эшкә бик нык каршы чыктылар, тавыш күтәрделәр. Ниһаять, татар халкы капма-каршы ике платформага – «кадимче», «җәдитче» платформаларына бүленделәр.

Кадимче-җәдитче исемендә башланган бу көрәштә кадимчеләр ягында Түнтәр Ишмөхәммәт (Ишми) мулла, Казан байларыннан чәйче Ишморатов, Мөхәммәтҗан хафиз, Оренбургта Вәли мулла Хөсәенов, Ханисламов, Уфа байларыннан Хәкимов, Себер мулла һәм Москва байларыннан Байрашевлар шикелле кешеләр торды.

Дини журнал дип чыгарылган «Дин вә мәгыйшәт»[1] журналы, «Сыйрател-мөстәкыйм»[2] журналы җәдитләргә каршы куелган гайбәт капчыгы иде.

Ысуле җәдидә мәктәпләренең башлангыч чорында фән белән коралланган, педагогик һәм методик аң белән сугарылган, рус һәм төрек мәктәпләре белән якыннан таныш мөгаллимнәр юк иде. Шунлыктан бу мәктәпләрнең төзелеше дә, торышы да бик түбән була. Турысы: мәктәпләр мөгаллимнең фантазиясе һәм хыялына бәйләнә. Икенче төрле әйткәндә, күз буявы иде.

Төпле бер программага ия булмаган, халыкның йон уңаена яткызып оештырылган бу мәктәпләрнең планында 50% ы дин сабаклары, 25% ы догалар, иляһиләр[3] ятлау, көйләр көйләү, калган 25% ы хисап, тәҗвид, бидаяте җәгърафия, «Мохтәсар тарихе әнбия» дәресләренә бирелә.

Мәктәпләрнең бу дәверендә иляһиләрне халык көйләре белән башкарырга мөмкин түгел иде. Шуннан чыгып, чеп-чи гарәп телендә язылган касыйдәләрне, шигырьләрне укыр өчен көй итеп рус композиторы тарафыннан язылган «Персидский марш» кебек көйләр милли көй итеп кабул ителә.

[1] «Дин вә мәгыйшәт» – сәяси, дини һәм әдәби журнал. 1906 елның декабреннән 1918 елның февраленә кадәр Оренбург шәһәрендә айга 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә.

[2] «Сыйрател-мөстәкыйм» («Туры юл») – 1800 елда Төркиядә Мехмед Акиф Эрсой һәм Әшрәф Әдип Ферган тарафыннан нәшер ителгән журнал.

[3] Иляһиләр – иляһи бәйтләр – дини эчтәлекле шигырьләр, мөнәҗәтләр.

Садә дәвере дип атарга мөмкин булган бу мәктәп дәвере фән өйрәтү, белем бирү белән түгел, шигырь ятлату, көй көйләтү белән узды. Бу яктан караганда, мәктәп күргәзмә урынын алды. Мәктәпкә кем генә кермәсен, мәктәп яныннан кем генә үтмәсен, мөгаллим нәүбәттәге дәресен туктата да, иляһи укытырга, көй көйләтергә тотына иде.

Ысуле җәдидә мәктәбенең сынаулары бик зур күтәренкелек белән үткәрелә һәм зур бәйрәм төсе бирелә иде. Сынауга карата чакыру кәгазьләре әзерләнә. Бу чакыру кәгазьләре авыл яки шәһәрнең аерым кешеләренә җибәрелә. Бик күп кешеләр телдән генә дә чакырылалар. Шулай итеп, сынаучылар сыналучылардан сан ягыннан күбрәк була иде.

Сынау хәзерлеге көчле хәйләләр, зур алдашулар астында барды. Сынау хәзерлеге үтелгән дәресләрне кабатлау тәртибендә булмады, бәлки укучыга бүлеп бирелгән темалар өстендә шомару – «шлифоваться итү» тәртибендә барды. Шуның белән бергә, укучыларга бирелгән темалар сынауга килүчеләрнең саннары уңаена каратылган булды. Шушындый алдашулар нәтиҗәсендә, сынауга кергән укучылар авызларыннан ут чәчәләр. Мәсьәләдән хәбәре булмаган халык, моңарга шаккатып, хәйран булып калалар иде.

Ысуле җәдидә мәктәпләренең башлангыч дәверендә парталар булмады. Парта урынына кыска аяклы тәбәнәк өстәлләр кулланылды. Өстәл әйләнәсенә балалар тезләнеп утыралар иде.

Халык алдында мәктәп һәм мөгаллим өчен бик зур кара тап булып саналган класс тактасын – кара тактаны нәрсә белән дә алмаштырырга мөмкин булмады. Катыргыдан да, линолеумнан да, калайдан да эшләп карадылар, ләкин халыкның ышанычын казана алмадылар, һаман тәре тактасына охшаттылар.

Ысуле җәдидә мәктәбенә каршы чыгучы кадимчеләр дин дәресләренә, дини касыйдәләргә, көйле шигырьләргә бәрелә алмыйлар. Аларның бәйләнгән нәрсәләре иҗек системасын ташлап, тавыш, аваз – ысуле саутия системасына күчү һәм кара такта булды. Әле бу чорда ысуле җәдидә мәктәпләре фәкать ир балалар өчен генә иде.

Ысуле җәдидә мәктәпләренең башлангыч чоры мөгаллимнәр өчен иң авыр чор иде. Мөгаллимнең фәнни нигезләре йомшак, педагогик һәм методик белеме сай, дәреслекләр юк, һәрнәрсәне язырга кирәк, моның өчен кулланмалар табып булмый иде.

Кайбер мөгаллимнәр айлык хезмәт хакы алмыйлар, аларның хезмәт хакы сәдакага юнәлдерелгән. Айлык хезмәт хакы алучыларның алган айлыклары тормышларын тәэмин итә алмый иде. Шун-

лыктан бу мөгаллимнәргә дә сәдакага кул сузып, түбәнчелекләргә төшәргә, кимсетүләргә очрарга туры килә иде.

Сәдака, бер яктан, шәхси мәнфәгатьне рәткә салса, икенче яктан, гомуми мәнфәгатьне нигезеннән җимерә. Мөгаллим, сәдакага кул сузу аркасында, бик күп һәм бик зур гомуми мәнфәгатьләрдән ваз кичәргә мәҗбүр була.

Муллалар, кулаклар, карагоруһлар мәктәп һәм мөгаллимгә каршы агитация ясыйлар. Мәсьәләдән хәбәре булмаган хезмәт ияләре дә, коткычыларга ияреп, мөгаллимнәрне кимсетә, тел озайта башлый. Шуның нәтиҗәсендә мөгаллимнәргә орылып-сугылырга да туры килде. Шуңа карамастан мөгаллимнәр ысуле җәдидә мәктәпләренең игътибарын күтәрүдә фидаилек күрсәттеләр, барлык мөмкинлекләрдән файдаландылар.

Реформа кертелгән (бармак белән генә санарлык) берничә мәдрәсәне исәпкә алмаганда, күпчелек мәдрәсәләрдә файдалы якка бер төрле дә үзгәреш булмады. Киресенчә, шушы чордан башлап, татар мәдрәсәләре үзләренең газаматларын-величиеләрен югалта башладылар. Шәкертләр карашында изге һәм бик югары саналган Бохара мәдрәсәләренә караш әкренләп үзгәрә.

«Әгәр барсаң Бохараи шәрифкә,
Кәлер хезмәтеңә ике фәрештә»,

дип язылган мәдхияне көлке якка борырга тотындылар. Бохара мәдрәсәләре һәм Бохара шәкертләреннән мыскыллы көлделәр.

Ысуле җәдидә мәктәпләре башланган көннән алып мөгаллимнәр берничә төрле җаваплы эшне үзләренә йөкләделәр: 1) Ана телендә дөрес һәм ачык укый-яза белә торган һәм фән белән коралланган яшь буын әзерләү. 2) Яңа мәктәп файдасына һәм төрле метод белән өзлексез аңлату һәм төшендерү эшләре алып бару. Шуның аркылы яңа мәктәп һәм яңача укуга тарафдар әзерләү. 3) Мөгаллимлекнең изге һәм мактаулы бер эш булуын исбат итү. Шуның аркасында укучыларны яңа мәктәпләргә күбрәк тарту.

Менә бу хезмәтләрне үтәү мөгаллимнәр өчен бик җиңел булмады. Бу юлда зур көрәшләр алып барырга туры килде. Шушы хезмәтләр өстендә муллалар да, кулаклар да, алар тозагына төшкән масса да мөгаллимгә капма-каршы килделәр. Мөгаллимнәрне сүктеләр, хурладылар, көлделәр. Мөгаллимнең үз күзе алдында мәктәпкә погром ясау, мәктәп инвентарьларын җимерү, дәреслекләрне ертып ташлау шикелле кабахәт эшләр эшләделәр.

Карагоруһларның коткылары аркасында халык яңача укуны диннән язу, руслаштыруның башы дип карадылар. Мәктәп һәм мәктәп инвентарьлары арасыннан иконалар эзли башладылар, әллә нинди килешсез, ошамый торган сүзләр тараттылар. Имештер, озакламый мәктәп түбәсенә каланча куячаклар икән. Имештер, мөгаллим хөкүмәткә укучыларның исемлеген биргән, озакламый балаларны урыслар алып китәчәкләр икән һ. б., һ. б.

Менә шушы юлда килеп чыккан вакыйгаларның берничәсен түбәндә язып үтәбез:

1) Әхмәт бай үзе салдырган бер мәктәпкә мөгаллим җибәрә. Ике арадагы аңлашу буенча, мөгаллим мулла өенә төшә. Мулла аны хуплап каршы ала. Телдән телгә, колактан колакка йөри торгач, мөгаллим килү хәбәре бөтен авылга таралып ала. Шуның нәтиҗәсе булса кирәк, биш-алты карт белән үтәлә торган өйлә намазында мәчет халык белән шыгрым тулы була. Халык намаз укырга түгел, бәлки авылның тарихында беренче мәртәбә булган һәм бик зур шау-шулар чыгарган мөгаллимне күрергә килгәннәр.

Намаздан соң мөгаллим, бик зур көч куеп, Коръән укыды. Ул моның белән үзенең урыслаштыручы түгел, бәлки саф мөселман икәнлеген исбат итәргә теләде, үзенә яхшы караш тудырырга уйлады.

Мөгаллимнең Коръән тәэсире төрле кешедә төрлечә булды; Коръән кайбер кешеләргә бик нык ошады, мөгаллимне сандугачка охшаттылар. «Мөгаллим дә сандугач, сандугач та мөгаллим», – диделәр. Кайберләре мөгаллим турында салкын канлылык күрсәттеләр; «Күреп карыйк әле, тормыш үзе күрсәтер», – диделәр. Ә кайберләре: «Беләбез без аны, шайтан Коръәнхафиз булган, алай булса да, оҗмахтан сөрелгән, өйрәтеп җибәргәннәр, Коръән белән күз буяп ышандырмакчы була», – диделәр.

Намаздан соң мулла мөгаллимне халыкка тәкъдим итте, халык белән таныштырмакчы булды: «Менә бу – Сабирҗан әфәнде, Оренбург бәлдәсеннән[1] килгән, мөгаллим булып килгән. Ягъни мәсәлән, сезнең әүладларыгызны укытырга җибәрелгән мөгаллим була. Иртәдән башлап, мулла Сабирҗан мәктәптә укыта башлаячак», – диде. Тагы берникадәр сөйләгәннән соң, халыкка карап: «Җәмәгать, аңладыгызмы?» – диде. Халык тып-тын торды, ләм-мим әйтүче булмады. Тик мөгаллим белән янәшә торган бер кеше мәсхәрәле бер елмаюдан соң: «Әйе, хәзрәт, аңладык», – диде һәм, халыкка карап,

[1] Бәлдәсеннән – шәһәреннән.

сул кулы белән җилкәсенә сугып куйды. Ул бу мимикасы белән: «Безнең җилкәне кимерергә килгән сорыкорт», – димәкче булды.

Икенче көн иртә намазыннан соң мулла белән мөгаллим мәктәпкә керделәр. Сорашып, тикшереп караганнан соң, мәктәптәге йөз җитмеш укучыдан фәкать 20–30 гына укучының калганлыгы аңлашылды. Аталарының кушулары буенча, күпчелек балаларның нәрсә-караларын кичәдән үк алып китканлекләре беленде. Мөгаллим, шактый күңелсез вакыйга алдында калган булса да, үзен югалтмаска тырышты, серне бирмәде.

Мөгаллимнең килереннән хәбәр алгач та, мулла мәктәпнең бер почмагына кечкенә генә бүлмә ясатып куйган иде. Ләкин мөгаллим бу бүлмәдә торуны мөмкин дип тапмады. Турысы – курыкты. Чөнки ул шундый бүлмәләрдә торучы мөгаллимнәргә килгән вакыйгаларның берничәсен күргән һәм ишеткән иде.

Өендә мөгаллим тотып, авызы пешкән муллалар да юк түгел. Шул уңай белән булса кирәк, йорт-җире зур булуга, бүлмәләре күп булуга карамастан, мулла мөгаллимне үз йортында калдыруны мөмкин тапмады. Берәр кешегә бирергә уйлады.

Бик озак һәм тырышып эзләүгә карамастан, авылдан мөгаллимгә квартира табарга мөмкин булмады. Төрле сәбәпләр таптылар, төрле хәйләләргә бардылар, мөгаллимгә почмак бирмәделәр. Мәсьәлә белән кызыксынган авыл писаре-секретаре Алексей Иванович Пономарев мөгаллимгә, үзе белеп, квартир тәкъдим итте: «Кечкенә өем буш тора, утын алып бирсәң, Мария Ивановна пичеңне дә ягып бирер, аш та әзерләр», – диде. Шуның белән квартира мәсьәләсе хәл ителде.

Шул көннән башлап, авыл халкы икегә бүленде, зур күпчелек мөгаллимгә начар карады, аны тереләй пешереп ашардай булдылар. Хәтта кайбер кулаклар муллага карашны да үзгәрттеләр: [балаларын] бирмәс булдылар, бирүне азайттылар. Мулла моның сәбәбен үзе дә ачык белде. Шуңа карамастан мулла теше-тырнагы белән мөгаллимне яклап килде.

Дошманнар мөгаллимнән котылуның юлын бик җиңел табып алдылар. «Хәзрәт картаеп килә, улы мәхдүм яшь әле, эзләп торасы юк, тотарга да мөгаллимгә тамга җыярга», – диделәр. Сөйләнә торгач, бу сүз мулла һәм абыстай колагына да килеп сугылды. Кайбер аталарның мөгаллимне үзен генә, аулаклап кына чәйгә чакырулары, мунчага алулары муллада шөбһә һәм куркыныч тудырды. Мулла мөгаллимне көндәш саный башлады. Мөгаллимгә чеп-чи дошман булып әверелде. Шушы көннән башлап, мулла мөгаллимнән котылу чараларына

кереште. Мәктәп тә кирәк түгел, мөгаллим дә кирәк түгел. «Кирәк булса, Әхмәт бай мәктәбен дә, мөгаллимен дә бау бәйләп муенына таксын», – диде. Зур теләкләр белән килгән мөгаллим язгы сынауларга барып җитә алмады, мәктәпне ташлап китәргә мәҗбүр булды.

2) Шәһәр бае Шәрип авылына зур һәм матур итеп мәктәп салдырды. Гомеренә рәтле мәктәп күрмәгән Шәрип авылы искиткеч бер мәктәпкә ия булды.

Бай, мәктәпкә дини төс бирү теләге белән, бинаның бер почмагына манара сыман әйбер ясап, ай куярга исәпләде. Бай, ай эзләп, күп кибетләрдә булса да, яраклы ай таба алмады. Нәтиҗәдә ай урынында таяксыман нәрсә генә утырып калды.

Башта бертөрле әһәмияткә ия булмаган бу манара, мөгаллим килеп эшкә керешү белән, зур шау-шуларга сәбәп булды. Имеш, манарага ай урынына тәре куелачак, колокол күтәреләчәк. Имештер, мөгаллим, колокол сорап, губернаторга гариза җибәргән. Имештер, иртәгә яки берсекөнгә колокол килеп җитәчәк икән, дигән хәбәр авылны каплап алды. Башта колактан колакка күчеп йөргән бу сүз беркөнне дары шикелле кабынып китте. Кемдер, авылның бер кешесе, колоколны пристаньда күреп кайткан. Ул бу хәбәрне авылга тараткан. Шул сүз буенча, авыл шау килә. Бик күп кешеләр дин өчен шәһид китәргә әзер.

Шушы вакыйгадан 3–4 көн узгач та, авылның ике кешесен пристаньга җибәрделәр. Мәсьәләне ачык итеп белеп кайтырга куштылар.

Юлчылар пристаньга барып җитә алмадылар. Ярты юлда, Ивановка авылы урамында колоколга очрадылар. «Әнә колокол китерәләр бит, малай», – диде мөселманнарның берсе. «Әйдә, сорашып карыйк әле», – диде икенче мөселман. Колоколның Шәрип авылына баруына һичбер шөбһә юк. Бу ачык. Тик илтүчеләрнең кемнәр икәнен генә белергә кирәк. «Әйдә, тизләт атны, карап әйләник әле», – диде мөселманның берсе.

Мөселманнар колоколчыларга бер сүз дә кушмаска, фәкать күреп кенә әйләнергә булдылар. «Мәсьәлә ачык, сорашасы юк», – диделәр. Ләкин эш мөселманнар уйлаганча булып чыкмады. Колоколчыларның берсе: «Шарипово сколько километр отсюда» дигән сорауларына җавап бирергә туры килде.

Колоколчыларның бу соравы яшен орган шикелле булды. «Әйдә, бор атны, тизрәк хәбәрне авылга ирештерик», – диде икенчесе.

Мөселманнар кайтып керүгә ярты сәгать үтмәде, хәбәр бөтен авылга таралып өлгерде. Халык коралланды. Элек мәктәпкә басып керделәр. Мөгаллим белән исәпләшергә теләделәр. Ләкин мөгаллим

качып өлгергән иде. Мулла өенә басып керделәр, аны да өйдә туры китерә алмадылар.

Мулла өенә бертөрле дә зарар тидерелмәде. Мәктәпнең манарасы алып ташланды, инвентарьлары шырпыга әйләндерелде. Тәрәзәләре ватылды, китаплар ертылды.

Кораллы халык колоколчыларны төн буе саклап чыктылар. Колоколны җимерергә, китерүчеләрен юк итәргә уйладылар.

Иртә белән мәсьәлә ачык билгеле булды. Колоколчылар белепме, белмиме, юлны үзгәрткәннәр. Шәрип авылына кермичә, башка юл белән киткәннәр. Колокол Шәрип авылыннан 60–70 чакырымдагы Малиновка авылына кайтарылган.

1905 ел революциясе якынлашканда, ысуле җәдидә тарафдарлары шактый күбәйгән иде. Шуның нәтиҗәсендә шәһәрләрдә дә, авылларда да күп санда яңа тип мәктәпләр барлыкка килгән иде. Мәдрәсә шәкертләренең бер өлеше мулла, мөәзин булу уеннан кайткannar иде. Бу шәкертләр мулла булуга караганда мөгаллимлекне артыграк саныйлар иде. Һәм бу фикердәге шәкертләрнең шактый бер өлеше мөгаллим булып та өлгергән иде.

1905 ел революциясенең беренче көннәрендә үк мәдрәсәләрне ислах ит мәсьәләсе кузгалды. Шәһәр мәдрәсәләрендә башланган бу дулкын авыл мәдрәсәләренә дә барып кагылды.

Мәдрәсәләрнең үз эчләрендә дә һәм читтә дә мәдрәсәләрне ислах итү турында җыелышлар, митинглар оештырылды, хәзрәтләргә ислах итү турында таләпләр-ультиматумнар да бирелде. Яшерен газеталар, прокламацияләр таратылды. Кайбер мәдрәсәләрдә дәрес ташлаулар, чыгып китүләр булды. Мәдрәсә шәкертләре дә капма-каршы ике платформага аерылдылар.

1905 ел революциясе нәтиҗәсендә татар халкы газета, журнал чыгару хокукына ия булды. Казан, Оренбург, Уфа шикелле шәһәрләрдә берничә газета һәм журнал чыгарылды. Мәсләк һәм караш ягыннан бер-береннән шактый ерак торган бу газеталар мәктәп һәм мәдрәсәләр турында бер фикердә булдылар, бер сүзне сөйләделәр. Мәдрәсәләрне ислах итү, мәктәпләрне күбәйтү һәм көчәйтү турында өзлексез язып тордылар.

Шул елларда татарлар арасында «зыялылар» дигән бер сыйныф мәйданга килде. Революцион зыялылар да, буржуй зыялылар да мәктәп, мәдрәсәләр турында баштарак бер фикердә булдылар.

Шул ук зыялылар арасында шагыйрьләр, язучылар, методистлар житеште, педагоглар чыкты. Татар дөньясында матур әдәбият,

дәреслекләр барлыкка килде, фәнни әсәрләр язылды. Ниһаять, яңа тип нәшрият ширкәтләре, яңа тип китап кибетләре оештырылды. Электә «Карынҗа догалары», «Тәкый гаҗәп», «Иман шарт»лары белән эш итә торган борадәране Кәримовлар, Шәмсетдин Хөсәеневләр[1] китап сәүдәләрен яңа юлга бордылар. Карынҗа догалары, шәмаилләр белән беррәттән әдәби әсәрләр, ысуле җәдидә дәреслекләре нәшеренә керештеләр.

Шәкертләрнең ислах турындагы таләпләрендә мәдрәсәләр программасына тәфсир, хәдис, гарәп әдәбияты, фәлсәфә һәм дөньяви фәннәр кертеп, мәдрәсәләрне ярым дини, ярым дөньяви бер уку йортына әйләндерү сорала иде.

Ислах ителгән уку йортларына шул вакыт кешеләре төрлечә карадылар. Татар халкының киләчәге муллаларга бәйләнгән дип ышанган кайбер кешеләр аларны фән белән коралланган яңа фикерле муллалар әзерләү өчен кирәк дип саныйлар. Татар халкының иҗтимагый һәм икътисади тормышында муллаларның әһәмияте юклыгын аңлаган кайбер кешеләр мондый мәдрәсәләрне фән белән коралланган югары культуралы мөгаллимнәр әзерләү өчен кирәк диләр.

Күп елларга сузылган бу таләп һәм ультиматумнарның файдалы нәтиҗәсе зур була алмады. Материаль таянычка ия булган кайбер зыялы муллалар гына мәдрәсәләренә шәкертләр таләбенә муафикъ реформа кертә алдылар. Ләкин бу мәдрәсәләр бармак белән генә санарлык иде. Мәдрәсәләрнең зур күпчелеге һаман да шул иске хәлләрендә калдылар. Әйтерлек үзгәреш күрмәделәр. Тормыш белән бергә бара алмаган һәм халык теләгенә туры килә алмаган бу мәдрәсәләр көннән-көн зәгыйфьләнүгә юл тоттылар, көннән-көн халык күзеннән төштеләр. Ниһаять, халык бу мәдрәсәләргә кирәксез дип карады. Сәламәт гакыллы яшьләр бу мәдрәсәләргә кереп укудан баш тарттылар. Ниһаять, мәдрәсәләрдә тормышка яраксыз сорыкортлар һәм гарип-горабалар гына җыелып калды. Нәтиҗәдә мондый мәдрәсәләрнең зур күпчелеге Бөек Октябрь революциясенә барып җитә алмадылар. Элекке тантаналарыннан яздылар, череп юкка чыктылар.

Оренбургта Вәли мулла Хөсәенов мәдрәсәсе, Казан бае Ишморатов карамагындагы Түнтәр Ишмөхәммәт мулла мәдрәсәсе һәм

[1] Шәмсетдин Хөсәенев (?–1905) – китап сәүдәгәре һәм нашир. Һиндстан, Иран, Төркия, Мисырда нәшер ителгән китапларны кайтартып сата. 1870 еллар урталарыннан татар китапларын нәшер итә.

шуңа охшаган берничә мәдрәсә Октябрь революциясенә барып терәлсәләр дә, бу аларның ахыргы көннәре булды.

Гомумән алганда, Бөек Октябрь революциясенең беренче көне борынгы татар мәдрәсәләренең юкка чыгу көне булды.

***1905 ел революциясе һәм ысуле җәдидә мәктәпләре***

1905 ел революциясе ысуле җәдидә мәктәпләре өчен яңа дәвер ачты. Шушы көннән башлап, татар укытучысы, татар язучысы, татар зыялысы матбугат аркылы үзенең тавышын бик еракларга, хәтта караңгы почмакларга кадәр ирештерде. Шуның нәтиҗәсендә шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да мәктәпләр берсе артыннан берсе ачылып торды.

1905 елга кадәр татар кызлары өчен ысуле җәдидә мәктәбе булмады. Кыз балалар әле һаман да абыстайлар һәм остабикәләр кулында, аш өйләрендә тәрбия ителәләр иде. 1905 ел революциясе татар кызларын да истән чыгармады, татар кызлары өчен дә ысуле җәдидә мәктәбе тудырды.

Ысуле җәдидә мәктәпләренең тизлек белән үсүе, шәһәр һәм авылларда яңадан-яңа мәктәпләр ачылып тору, мөгаллим һәм мөгаллимәләрнең сан ягыннан күбәюләрен, сыйфат ягыннан яхшылануларын таләп итте. Менә шуның тәэсирендә борынгы мәдрәсә шәкертләренең шактый бер өлеше үзлекләреннән мөгаллимлеккә әзерләнә башладылар. «Хөсәения», «Госмания», «Мөхәммәдия», «Рәсулия» шикелле мәдрәсәләр, мулла әзерләүдән ваз кичеп, укытучылар әзерләү юлына керделәр. Шуның белән бергә, «Буби», «Галия» шикелле яңа мәдрәсәләр барлыкка килде. Хатын-кызлар арасыннан мөгаллимәләр әзерләү теләге белән, кыска сроклы җәйге курслар оештырылды. Бу курсларда мөгаллимәләр мәктәп төзелеше, педагогика һәм методика кагыйдәләре белән таныштырылды, тарих, география, табигать, математика һәм тел, әдәбият шикелле фәннәр укытылды.

Баштарак катнаш педагогик курслар оештырырга мөмкинлек булмады. Курслар мөгаллимнәр өчен аерым, мөгаллимәләр өчен аерым оештырылды. Ләкин һәр ике курсларда укытучылар ирләр булды. Курсларның финанс һәм материаль якларын земстволар күтәрде. Татарлар үз хисапларына да шактый гына педагогик курслар үткәрделәр. Педагогик курсларның күбесе Казан, Оренбург, Уфа шикелле шәһәрләрдә оештырылды.

Бөек Октябрь революциясенә кадәр катнаш мәктәпләр булмады. Ир балалар, кыз балалар аерым мәктәпләрдә укыдылар. Шуның

белән бергә, ир балалар мәктәбендә хатын-кызлар, кыз балалар мәктәбендә ирләр укыта алмады. Бу эшкә халык начар карады. Соңга таба, 1915–1916 еллар тирәсендә кыз балалар мәктәпләрендә ир укытучылар күренгәли башлады. Уфа, Буби һәм Троицк «дарел мөгаллимат»ларында укытучыларның күпчелеге ирләр иде.

Шәһәрләрдә дә, авылларда да мәктәпләр муллалар кулында булды. Кыз балалар мәктәпләре мулла хатыннары – абыстайлар (остабикә, остазбикә) карамагында булды.

1910 еллар тирәсендә мулла һәм абыстайлар белән бәйләнеше булмаган мәктәпләр дә күренә башлады. Мондый мәктәпләр башында җәмгыяте хәйрияләр яки хосусый кешеләр торды. Мондый хосусый мәктәп дип аталган мәктәпләр башлап зур шәһәрләрдә оештырылды. Оренбургта Багбостан ханым[1] һәм Зәйнәп Камалия мәктәпләре шул чорның яхшы куелган мәктәпләреннән иде. Мондый мәктәпләр Казанда, Уфада, Троицкида һәм башка шәһәрләрдә дә бар иде.

Бөек Октябрь революциясенә аяк баскан көннәрдә авыл һәм шәһәрдәге ир балалар өчен булган барлык башлангыч мәктәпләр ысуле җәдидә мәктәпләренә әйләнеп бетәләр. Ләкин кыз балалар өчен булган башлангыч мәктәпләрнең күпчелеге муллалар өендә, абыстайлар карамагында һәм өшкерү, төкерү белән көн күрүче тол карчыклар кулында иде. Шуның белән бергә, авылларда кыз балаларның 50% ы укудан мәхрүм булып торды. Октябрь революциясенә кадәр бу кызлар турында кайгыртучы да булмады.

Ысуле җәдидә мәктәпләре программалары ягыннан бер-берләренә якын торсалар да, уку елының срогы ягыннан бер-береннән бик нык аерылалар иде. Уку срогы төрле шәһәрдә һәм төрле мәктәптә төрлечә иде. Кайбер башлангыч мәктәпләрнең уку срогы өч еллык булдыгы хәлдә, икенче бер мәктәпләрнең уку срогы 4 ел иде. Бишьеллык, алтыеллык башлангыч мәктәпләр дә бар иде.

Бу чорларда класслар өчен аерым бүлмәләргә бүлеп эшләнгән татар мәктәпләре бик сирәк урыннарда гына иде. Моңарга сәбәп итеп, түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

1) Татар халкының экономик яктан түбән торуы һәм мәктәпләргә хөкүмәт тарафыннан ярдәм булмавы.

2) Өч-дүрт классны мәктәптә бер генә укытучы булып, балаларны күз алдында тотарга кирәклеге.

[1] Багбостан ханым – Багбостан Вилдан кызы Мөэминова (1884–1963) – педагог, Оренбургта хатын-кызлар мәдрәсәсен нигезләүче.

Гадәттә, күпчелек мәктәпләр зур бер зал яки зур бер бүлмәдән тора, мәктәптә ничә класс булса, алар шул зал яки бүлмәнең бер почмагына урнаштырыла.

Ысуле җәдидә мәктәпләренең бик күбесендә мөгаллим бер генә була, шунлыктан мөгаллимгә өч, дүрт класс белән бер вакытта берьюлы эш итәргә туры килә. Бу хәл укуның сыйфат ягыннан кыйммәтен төшерсә дә, моңарга бертөрле чара күрергә мөмкинлек юк иде.

Берьюлы бер вакытта дүрт класс белән эш алып бару мөгаллим өчен җиңел түгел. Шуның өчен кайбер мөгаллимнәр, эш вакытын сузып булса да, балаларны ике сменага бүлеп укыталар.

Бер үк сәгатьтә дүрт класс белән эш алып барырга туры килгәндә түбәндәгечә планлаштырыла:

1) Мәктәп өчен аерым үзенчәлекле расписание төзү. Мондый хәлдә мөгаллим бер класста телдән эш алып барса, башка классларга мөстәкыйль эш бирә, мәсәлән:

| I кл. | II кл. | III кл. | IV кл. |
|---|---|---|---|
| Матур язу | Күчереп язу | Хисап чыгару | Дин дәресе |

Менә бу хәлдә I, II һәм III класслар мөгаллимнән башка үзләре генә эш алып баралар. Мөгаллим IV классларда дин дәресе укыта, ләкин, шуның белән бергә, мөгаллим башкаларны да күз уңыннан ычкындырмый.

2) Югары класс укучылары эченнән көчлерәк балаларны үзенә ярдәмче итеп файдалану һ. б.

***Мөгаллим, мөгаллимәләрнең хезмәт хаклары***

Октябрь революциясенә кадәр мөгаллим һәм мөгаллимәләрнең хезмәт хаклары, дөресрәк итеп әйткәндә, килер-төшемнәре түбәндәгеләрдән тора иде:

1) Кем тарафыннан булса да билгеләнгән хезмәт хакы – зарплата. Гадәттә, мөгаллимнәрнең хезмәт хаклары бик төрле. Күбесенчә хезмәт хаклары мәктәпнең экономик хәленә яки хезмәт хакы бирүченең һиммәтенә карап билгеләнә. Мөгаллимнең белем дәрәҗәсенә һәм аның игътибарына карап та була ала. Хезмәт хакының кечкенәсе 4–5 сумнан башлый, югарысы 25–30 сум була. 50–60 сум һәм 100 сум зарплата биргән мәктәпләр дә бар иде. Ләкин мондый мәктәпләр бармак белән генә санарлык. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә башлангыч класс укытучылары 30–35 сум, рөшдия укытучылары 60–70 сум, игъдади һәм гали класс укытучылары 150–200 сумгача зарплата алалар иде. Шуның белән бергә, бик күп

мәктәпләрдә хезмәт хаклары 8–9 айга укыткан айларга гына түләнә, каникул айларына зарплата түләнми. 12 айга хезмәт хакы түләү земство мәктәпләрендә һәм кайбер шәһәр мәктәпләрендә генә була. Земствоның башлангыч мәктәпләрендә хезмәт хакы 36 сум иде.

2) Зур шәһәрләрдә кайбер мәктәпләрдә кече атна сәдакасы алу тыелган булса да, мәктәпләрнең күпчелегендә бу гадәт Октябрь революциясенә кадәр дәвам итеп килде. Гадәттә, бу атналык сәдака балаларның хәленә карап, 2–3 тиен, 5–10 тиен чамасында була, мөгаллим һәр кече атна көн 3–4 сум акча җыйнап ала.

3) Бала аталары мөгаллим һәм мөгаллимәләрне муллалар белән гомуми мәҗлесләргә чакыралар. Шул мәҗлесләрдә мулла белән беррәттән мөгаллимгә дә сәдака бирәләр. Шәһәрләрдә мондый мәҗлесләр – кунакка чакырулар көн саен булып тора. Монда бирелә торган сәдаканың кечкенәсе 2–10 тиен, зурысы 50–60 тиен чамасында була. Шуның белән бергә, кайбер ата-аналар, җай китереп, мөгаллим-мөгаллимәләрне үзләрен генә дә чакыралар иде.

4) Шәһәрләрдә төрле уңай белән ата-аналар мөгаллим-мөгаллимәләргә бүләкләр дә биргәлиләр. Кием-салым шикелле бүләкләр, гадәттә, имтихан-сынаулар вакытында була.

5) Кайбер мөгаллим-мөгаллимәләр зәкят, гошер һәм фитыр шикеллеләрдән дә файдаланалар.

Хосусый мәктәпләрнең кайберләре фәкать сәдакага бәйләнгән иде. Монда эш хакын сорап алу юк, ни бирсә, шуңа риза булалар. Ә кайбер хосусый мәктәпләр уку өчен уку хакы да алалар. Шуның белән бергә, сәдакадан да тартынмыйлар. Мондый мәктәпләрдә уку хакы укучының экономик хәленә карап билгеләнә, фәкыйрь балалардан айга 40–50 тиен, урта хәллеләрдән 1–2 сум, байлардан 5–10 сум алына. Мәктәп саен берничә бала түләүсез дә укытыла. Хосусый мәктәпләрнең йөзен күрсәтү теләге белән Оренбург шәһәрендә 1912 елда оештырылган һәм Октябрь революциясенә кадәр яшәп килгән Зәйнәп ханым Камалованың хосусый мәктәбе «Камалия мәктәбе» турында язып үтү файдалы булыр.

Зәйнәп ханым Камалия мәктәбе 1912 елның көзендә ачыла. Беренче уку елында 15–20 чамасындагы кыз балалар кечкенә бер бүлмәдә укыйлар. Мәктәпне ачар өчен, беркемнән дә рөхсәт соралмый. Хөкүмәттән рөхсәт соралганда да файдасы булмаганлыгы ачык мәгълүм була.

Елдан-ел мәктәптә укучылар артып торганлыктан, мәктәп фатирын һәр ел алмаштырып торырга туры килә. 1912 елда сигез сумлык

кечкенә генә фатирда башланган бер мәктәп 1914 елда ун бүлмәле фатирга урнаша. Әле бу бина да кысынкы сизелә.

Мәктәп бишьеллык башлангыч мәктәп һәм ике еллык мөгаллимәләр әзерләү классларыннан тора. Читтән, ераклардан килгән укучылар өчен 15–20 кешелек пансион карала.

150–160 кешелек мәктәптә укытучылар составы түбәндәгечә була.

1) Гомуми фәннәр һәм тәгълим-тәрбия фәннәре укытучы ир укытучылар – 3 кеше.

2) Гомуми фәннәр укытучы хатын-кызлар – 5 кеше.

3) Рус теле укытучы – 1 кеше.

4) Тегүгә өйрәтүче – 1 кеше.

5) Чигү өйрәтүче – 1 кеше.

6) Бәйләү эше өйрәтүче – 1 кеше.

Барлыгы: 12 кеше.

Зур шәһәрдә оештырылган (хатын-кызлар өчен булган) хосусый мәктәпләрнең күбесе бер формадарак була торган иде.

Зәйнәп Камалия мәктәбе укучылардан җыйналган уку хаклары һәм кайбер хосусый ярдәмнәр белән тәэмин ителде.

### *Ысуле җәдидә мәктәпләренең программалары, уку планнары һәм расписаниеләре*

Ысуле җәдидә мәктәпләре дип аталган яңа тип татар мәктәпләренең нинди дә булса берәр оешма тарафыннан төзелгән яки расланган уртак бер программалары юк иде. Һәр мәктәп программаны үзе өчен үзе төзи. Башка берәр мәктәптән алырга да хаклы иде.

Шактый вакытлар мәктәп программасы белән мөгаллим, мөгаллимәдән башка кеше кызыксынмады. Шуңа карамастан төрле куллар тарафыннан төзелгән бу программалар нигез ягыннан бер-берләреннән бик ерак тормыйлар. Мәсәлән, Оренбург губернасы Каргалы авылындагы бер мәктәпнең программасын Саратов губернасы Кулатка яки Пәлдәнге мәктәбе программасы белән чагыштырып каралганда ике арада аерма бик зур булмый торган иде. Кайбер мәктәпләрдә язма программа сакланса да, күп мәктәпләрдә программа бөтенләй булмый. Программаны хәзерге мәгънә белән алганда, ысуле җәдидә мәктәпләрендә (башлангыч мәктәпләрдә) бу программа бөтенләй булмады. Бу мәктәпләрдәге программа дәресләрне елларга бүлеп күрсәткән схемадан гына гыйбарәт. Түбәндә күрсәтелгән программа схемасы мәктәпләр арасында кулланыла торган программаларга якын.

Бу схемага күз салганда, башлангыч ысуле җәдидә мәктәпләренең йөзен дә, күләмен дә ачык күрергә мөмкин булыр.

| I класс | | | II класс | | |
|---|---|---|---|---|---|
| №№ | Фән исемнәре | сәгать | №№ | Фән исемнәре | сәгать |
| 1 | Татарча әлифба | 6 | 1 | Һәфтияк | 6 |
| 2 | Күчереп язу | 2 | 2 | «Гыйльме халь» (дин) | 4 |
| 3 | Матур язу | 2 | 3 | Төрки уку | 3 |
| 4 | Хисап-арифметика | 6 | 4 | Хисап-арифметика | 6 |
| 5 | Күңел сабагы | 1 | 5 | Имля (диктовка) | 2 |
| 6 | Илаһи (җыр) | 1 | 6 | Матур язу | 2 |
| 7 | Гарәп әлифбасы | 6 | 7 | Илаһи (җыр) | 1 |
| 8 | Төрки уку | 3 | | | |
| III класс | | | IV класс | | |
| №№ | Фән исемнәре | сәгать | №№ | Фән исемнәре | сәгать |
| 1 | Коръән | 6 | 1 | Коръән | 6 |
| 2 | Дин сабагы | 3 | 2 | Дин сабагы | 3 |
| 3 | Төрки уку | 3 | 3 | Төрки уку | 3 |
| 4 | Хисап | 5 | 4 | Хисап | 5 |
| 5 | «Тарихе әнбия» | 2 | 5 | «Тарихе ислам» | 2 |
| 6 | Тәҗвид | 2 | 6 | Җәгърафия | 2 |
| 7 | Имля | 1 | 7 | Имля | |
| 8 | Инша | 1 | 9 | Матур язу | |
| | | | 10 | Илаһи | |

Ысуле җәдидә мәктәбе укытучылары чирекләргә бүлеп эшләнгән уку планын һәм көндәлек эш планын белмиләр. Мондый нәрсәләр бу мәктәпләрдә булмады. Мөгаллим-мөгаллимәнең чиреклек һәм көндәлек план белән эше юк, ул дәреслекне генә белә, дәреслек тәртибенә буйсына.

«Хөсәения», «Галия», «Мөхәммәдия» шикелле зур һәм атаклы мәдрәсәләрдә гомуми программа булу өстенә «мөфрәдат[1] программасы» дип йөртелә торган тагын бер программа була иде. Ул гомуми эш планы урынын тота. Һәр ике программа мәктәп идарәсендә саклана, мөгаллимнәр күрсәләр күрәләр, күрмәсәләр дә, беркем дә бер сүз әйтми.

Атаклы мәдрәсәләрдә рөшди, игъдади һәм гали дип аталган класслардан тыш, башлангыч класслар да була. Мондый мәдрәсәләрдә

[1] Мөфрәдат – аерым, ялгыз.

башлангыч класслар өчен дә программа төзелә. Гадәттә, мөгаллим кайсы мәдрәсәне бетереп чыккан булса, үз мәктәбендә шул мәдрәсә программасыннан файдалана.

Мәктәпләрнең укытучылар составында зур үзгәреш булмаса яки, үзгәреш булып та, киткән укытучылар белән яңа укытучылар арасында кискен мәсләк аермасы күренмәсә, программаларда да, расписаниеләрдә дә үзгәреш ясалмый. Гомумән, программаларга үзгәреш ясалмый. Программаларга, планнарга, диалектика законнарына буйсынмый торган – үзгәрешсез бер нәрсә дип карала.

Бик зур күпчелек мәктәпләрдә яңа уку елын башлау уңае белән яңа расписание төзелми, бәлки үткән елгы расписание яңа һәм яхшы кәгазьгә күчерелә генә. Мин үзем Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсендә сигез-тугыз ел укытучылык иттем. Ләкин шул дәвер эчендә программага үзгәреш ясау турында фикер йөрткән кешене күрмәдем.

Ысуле җәдидә мәктәпләренең башлангыч дәверләрендә расписаниеләр китап һәм дәресләрне күрсәтеп кенә төзелә. Расписаниедә фән исемнәре телгә алынмый.

*Мәктәп расписаниесе*

| № | Сыйныф |
|---|---|
| 1 | Һәфтияк |
| 2 | Тәһарәт («Гыйльме халь») |
| 3 | «Мөгаллим әл-кыйраәт» |
| 4 | Гамәли хисап, 1 нче җүз. |
| 5 | «Фән әт-тәҗвид» |
| 6 | Имля мөгаллиме |

Реформага эләгеп, ярым дини, ярым фәнни булган мәдрәсәләрнең исемнәре башка булсалар да, өстән караганда программалары бер-беренә башка шикелле тоелса да, эчтәлекләрен җентекләп тикшергәндә, һәр мәдрәсәнең программасы бер юнәлештә булып чыга.

Ибтидаи, рөшди, игъдади һәм гали исемендә дүрт бүлектән торган яңа тип мәдрәсәләрнең программалары түбәндәгеләрне эченә ала иде.

1 – Ана теле, уку, язу, имля, инша, әдәбият кагыйдәләре, матур язу.

2 – Хисап, геометрия, тригонометрия һәм алгебра.

3 – География, физик һәм экономик география һәм астрономия.

4 – Тарих, тарихе әнбия, тарихе ислам, тарихе гомуми, милли тарих, тарихи әдъян[1].

5 – Табигать, ботаника, зоология, минерология.

6 – Химия.

7 – Физика.

8 – Педагогика.

9 – Методикалар.

10 – Әхлак.

11 – Рус теле, уку, язу, сарыф, нәхү.

12 – Гарәп теле, уку, язу, сарыф, нәхү, гарәп әдәбияты.

13 – Дини дәресләр; фикъһ, ысуле фикъһ, кәлям тәфсир, хәдис, «Сияре шәриф», «Фәлсәфәи диния».

14 – Фарсы теле, уку, язу.

15 – Гигиена.

16 – Мантыйк-логика.

17 – Рәсем.

Гадәттә, яңа тип мәдрәсәләрдә бүлекләрнең уку срогы түбәндәгечә була иде.

1 – Ибтидаи бүлек, уку срогы 4 ел.

2 – Рөшди бүлек, уку срогы 3 ел.

3 – Игъдади бүлек, уку срогы 3 ел.

4 – Гали бүлек, уку срогы 2 ел.

Һәрбер мәктәпнең үзенә хас бер мәсләге – направлениесе була иде һәм мәдрәсәнең бу мәсләге мәдрәсә башында торган мөдәрриснең яки мәдрәсәдәге мөгаллимнәрнең карашы белән бәйләнгән була. Программада фәннәргә сәгатьләр бирү әнә шушы мәсләк һәм шушы карашка нигезләнә.

Уфа шәһәрендә «Галия» мәдрәсәсен оештыручы һәм шул мәдрәсәнең мөдире Зыя хәзрәт Камали күп еллар буенча дин гыйлеме өйрәнгән. Зыя хәзрәт фән белән дә беркадәр таныш. Шунлыктан ул фәнгә дә бәя бирә ала. Шуңа карамастан Зыя хәзрәт кешелек дөньясының рәхәте, сәгадәте һәм киләчәге дингә һәм дини белемнәргә бәйләнгән дип ышанган. Шуның өчен Зыя хәзрәт «Мәдрәсәи Галия»дән фән белән таныш, дин белән үтә сугарылган имамнар, муллалар чыгарырга уйлый, ул шул теләкне максат итеп куя. Теләк ачык һәм билгеле булгач, «Галия»гә программа төзү мәсьәләсе үз-үзеннән билгеләнә. Программа фән җирлегендә дин һәм дини белемнәр белән сугарыл-

[1] «Тарихе әдъян» – диннәр тарихы.

ган була. Программада дини предметлар нигез булып торгач, дини предметларга күп сәгать бирелү мәсьәләсе үзеннән-үзе килеп чыга.

«Буби» мәдрәсәсен[1] оештыручылар һәм шул мәдрәсәнең башында торучылар Габдулла һәм Гобәйдулла мәхдүмнәрнең карашлары тагын бертөрле. Бубиларча татар халкының киләчәге динне фәлсәфәсе белән аңлаган һәм фән белән үтә сугарылган укытучыларга – мөгаллим, мөгаллимәләргә бәйләнгән. Бубиның «Дарел мөгаллимин»е һәм «Дарел мөгаллиматы» шул күзлектән карап оештырылган. Шулай булгач, Буби мәдрәсәсе программасында фән нигез булып тора һәм фәнгә күбрәк сәгать бирелә.

Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең башында Галимҗан хәзрәт Баруди[2] тора. Мәдрәсә тулысы белән Баруди тәэсиренә бирелгән. Галимҗан хәзрәт – Бохарада укып кайткан дини галим. Ул, гарәп, фарсы телләрен яхшы белүе өстенә, дини белемнәр белән дә нык таныш. Шуның белән бергә, Баруди – фәнгә хөрмәт белән карый торган кеше.

Баруди фикеренчә, татар халкы динне яхшы белгән, фән белә торган муллаларга, дин һәм фән белән сугарылган мөгаллимнәргә мохтаҗ.

Шуның белән бергә, Баруди – тәсаувыф, ишанлык белән кызыксынган кеше. Татар халкының сәгадәтендә тәсаувыфның да катнашы бар дигән фикердә. Шулай булгач, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең программасы ачык күренеп тора. Тәсаувыф белән сугарылган дини белемнәр программада киң урын ала. Нәтиҗәдә фәнни предметларга бик аз урын кала. Фәлсәфә, мантыйк шикелле предметларга программада бөтенләй урын бирелми.

### *Мәдрәсәләрнең игъдади һәм гали бүлекләрендә дәреслекләр*

Бөек Октябрь революциясенә кадәр татар мәдрәсәләренең игъдади, гали дип аталган бүлекләрендә кулланыр өчен, Россиядә басылган дәреслекләр юк иде. Шунлыктан бу бүлекләр өчен булган дәреслекләр чит илләрдән алына. Дин һәм гарәп теле буенча дәреслекләр Мисырдан, дөньяви фәннәр буенча дәреслекләр Истанбулдан алдырыла. Шуның белән бергә, кайбер фәннәр яздырып укытыла.

---

[1] «Буби» мәдрәсәсе Вятка губернасы Иж Бубый авылында (хәзер Татарстан Республикасының Әгерҗе районында). Җәдитчә белем биргән уку йорты.

[2] Баруди Галимҗан Мөхәммәдҗан улы (1857–1921) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе. 1881 елдан Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен нигезләүче, аның җитәкчесе һәм мөдәррисе.

1905 елга кадәр дәреслекләр башлангыч мәктәпләр өчен дә җитәрлек булмады. Шунлыктан бу дәвердә башлангыч мәктәпләрдә дә яздырып-күчертеп укыту дәвам итте.

Мәктәпләр өчен дәреслек язучы авторлар баштарак гарәп һәм төрекчә дәреслекләрдән файдаландылар. Соңга таба русча әсәрләрдән файдалана башладылар.

Мәктәпләр өчен дәреслекләр әзерләүдә һәм аларны бастыруда Казан беренче урында торды.

Татар телендә язылган кайбер дәреслекләр сорау һәм җавап юлы белән, кайберләре нәзым юлы белән язылды. Сорау һәм җавап юлы белән язылган дәреслекләр җиңел аңлашыла, нәзым юлы белән язылган дәреслекләр җиңел ятлана диләр иде.

***Патша хөкүмәтенең татар мәктәпләре белән бәйләнеше***

Патша хөкүмәте татар мәктәпләренең саны белән дә, сыйфаты белән дә кызыксынмый. Хөкүмәт күзлегеннән караганда татар халкының үсмәгәне, укымаганы яхшы иде. Патша хөкүмәте татар мәктәпләренең пантюркизм һәм панисламизм белән бәйләнешеннән генә курка. Ара-тирә мәктәпләргә кергән патша чиновниклары, рус түрәләре дәреслекләрнең кайда басылганлыкларын һәм цензураның рөхсәт биреп-бирмәвен карыйлар, патша гаиләсенең исемен һәм титулларын сораштыралар. Шуннан еракка узмыйлар. Дәреслектә түбәндәге җөмләләр булса, ул дәреслек куркынычсыз иде:

*«Бу китаб басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербургда 1 нче июньдә 1898 нче елда, табгы би-мәсарыф әт-таҗир Мөхәммәдгали бине Минһаҗетдин әл-Казани фи мәтбаг вәрасәтел-Чирков фи сәнәтә 1898*[1].

*Дозволено цензурою С.-Петербурга 1 июня 1898 года. Типо-Литография наслѣдниковъ М.Чирковой, въ Казани».*

Түбәндә «Шура» журналыннан күчерелеп язылган мәкалә патша хөкүмәтенең татар мәктәпләренә булган карашын ачык күрсәтсә кирәк. Мәкалә үзенчә, үзгәртми күчерелде.

*Дини вә милли мәктәпләремез*

*Чит диннәрне карый торган департамент директоры үткән ел (1913 ел) сентябрь аенда Оренбург мөфтисе исеменә ошбу мәзмунда*[2] *бер кәгазь җибәргәнлеге мәгълүм булган иде: хәзерге вакытта ми-*

[1] 1898 елда сәүдәгәр Мөхәммәдгали бине Минһаҗетдин әл-Казани чыгымнары хисабына Чирков варислары басмаханәсендә басылды.

[2] Мәзмунда – эчтәлектә.

*нистерство мәмләкәтнең һәр тарафындагы мөселман дини мәктәп-мәдрәсәләренең бу көнге хәле хакында үз кулында булган материалларны тәртипкә салырга кереште. Ошбу мөнәсәбәт илә мөтәхассыйс*[1] *булган затларның отзывлары буенча мөселманларның дини тәгълимгә тугрыдан-тугры мөнәсәбәте булган шәригать карарларыны белергә ихтыяҗ табылды.*

*Шул сәбәпле үтенәбез, шәригатьтә мөхәммәдиләрнең дин тәгълим итә торган школларының назначениесе вә анлардан көтелгән максатлар, анларда тәгълим тәртибе вә укытылачак нәрсәләр, вә программ, мөгаллимнәр һәйяте вә бала һәм егетләргә дин үгрәтүгә алынган кешеләрнең нинди сәляхиятләрне*[2] *хаиз*[3] *булулары хакында гомумән бәяннар бармы, булсаниләр?..*

*Ошбу сөальләр хакында Оренбург мөфтие тарафындан үз кул астында булган меллаларның бәгъзеләренә кәгазьләр язылып, фикерләре соралды. Кәгазь өстендә булган бу җавапларга гына канәгать итми, шул 10 декабрьдә үз риясәтендә бер мөшавәрәт*[4] *мәҗлесе тәгъйин итеп*[5]*, беркадәр муллаларны шул мәҗлескә дәгъвәт кылды. Дәгъвәт ителгән адәмнәр Уфа шәһәренә сәфәр итәргә тордыкларында (бәгъзеләре сәфәр кыйлганнар иде) Оренбург мөфтисе тарафыннан дәгъвәтлеләр исеменә «Имди мәҗлес булмый, килмәңез!» дип, икенче бер кәгазь таралуы мәгълүм булды.*

*Мәҗлес тукталуның сәбәбе исә, Оренбург мөфтисе бу мөшавәрәтне*[6] *үз хокукы даирәсендә генә ясамакчы булганы хәлдә чит диннәр департаментының директоры моның өчен аерым рөхсәт алуны лязем күргән. Оренбург мөфтисе исә мондый эшләрне илтизам итәсе*[7] *килмәдекендән, «Инде мәҗлес булмый» дип, ул чакырган кешеләренә килмәскә кушып, икенче хәбәр җибәргән.*

*Ләкин 10 нчы декабрь көнендә Уфа шәһәрендә 30 дан артык ахундлар, мөдәррисләр вә имамнар хазир булдылар*[8]*. Моның күбесе «Килмәңез» дип язылган соңгы кәгазьне алмаган вә белмәгән булганнар. Бәгъзеләре исә, мәсьәләнең мөһим булуына күрә, ала торып та килделәр вә ничек кенә булса да, мөшавәрәт мәҗлесе ясарга иҗтиһад итәргә керештеләр.*

---

[1] Мөтәхассыйс – белгеч.
[2] Сәляхиятләрне – сәләтләрне.
[3] Хаиз – ия.
[4] Мөшавәрәт – киңәш.
[5] Тәгъйин итеп – билгеләп.
[6] Мөшавәрәт – киңәш мәҗлесе.
[7] Илтизам итәсе – үз өстенә аласы.
[8] Хазир булдылар – килделәр.

*Мәҗлес ясау турында Оренбург мөфтисенең иҗтиһад итмәзлегене белдекләреннән соң, башкаларның тапшыруларына күрә, бөтен мәсьүлиятне үз өстләренә алып, Бәләбәй мәсҗедендә ахунд Җәмалетдин Хурамшин*[1]*, Мәскәү мәсҗедендә имам Габдулла Шәмсетдинов*[2]*, Уфа губернаторы аркылы 14–15 декабрьдә мөшавәрәт мәҗлесе ясар өчен, министрдан рөхсәт сорадылар. Мәҗлеснең программыны һәм катышачак кешеләрнең исемләрене язып тапшырдылар.*

*Имамларның үтенечләрене игътибарга алып, ошбу мөшавәрәт мәҗлесене ясар өчен, министр рөхсәт бирде (гүя Оренбург мөфтисе риясәт итмәк шарты илә имеш). Рөхсәт телеграммасы 13 нче декабрьдә көндез өйләдән соң тапшырылды.*

*Шуңа күрә имамнар вә ахундлар 14 нче декабрьдә Оренбург Духовное собраниесенә җыелдылар вә үзләренең дәгъвәтнамәләренә күрсәтеп, исемләрене яздырдылар. Мәҗлес була торган собрание залына керер өчен, чит кешеләргә рөхсәт булмады, хәтта газета мөхбирләрене дә кертмәделәр (шаять, бу кысынкылык министр вә губернатор тарафларыннан булмагандыр).*

*Сәгать 9 да мәҗлес башланды. Оренбург мөфтисе үзе рәис (председатель) булды, имамнардан Мәсгуд Гобәйдуллин*[3] *илә Гатаулла Гобәйдуллин секретарьлык (кятиб) хезмәте өчен тәгъйин кылындылар*[4]*. Монларның әүвәлгесе русча язар вә соңгысы татарча язар өчен иде. Мәҗлес ошбу адәмнәрдән гыйбарәт иде:*

*1) Мөхәммәдьяр Солтанов*[5]*. Оренбург мөфтисе вә шул мәҗелестә председатель.*

*2) Хаҗиәхмәт Рәхманкулов. Троицк шәһәрендә 1 нче мәсҗед хозурында ахунд вә мәшһүр галимләрдән.*

*3) Мөхәммәдзариф Юнысов*[6]*. Петербург шәһәрендә 2 нче мәхәлләдә ахунд.*

---

[1] Хурамшин Җәмалетдин (1874 яки 1877 – 1925 елдан соң) – җәмәгать һәм дин эшлеклесе. 1 нче Дәүләт Думасы депутаты (1906).

[2] Шәмсетдинов Габдулла (1870–1937) – дин эшлеклесе. Мәскәү мәчете имамхатибы.

[3] Мәсгуд Гобәйдуллин (1874–1921) – Бәйрәкә авылындагы «Гобәйдия» мәчете имамы, мөгаллим, 1907 елда «Тәрәккыюн ислам җәмгыяте», ягъни Бәйрәкә мөселман тәрәккыйпәрвәрләр җәмгыятен оештыручыларның берсе, шул оешманың рәисе.

[4] Тәгъйин кылындылар – билгеләнделәр.

[5] Мөхәммәдьяр Солтанов (1837–1915) – дин эшлеклесе, Оренбург мөселман Диния нәзарәте мөфтие (1886–1915).

[6] Юнысов Мөхәммәд Зариф (1850 тирәсе –1914) – дин эшлеклесе. 1869 елдан С.-Петербургта 1 нче мәхәллә имамы.

*4) Габдулла Шәмсетдинов. Мәскәү шәһәрендә беренче мәсҗед хозурында имам.*

*5) Мөхәммәдшакир Гаффаров. Сембер шәһәрендәге мәсҗед хозурында ахунд.*

*6) Хәсән Таһиров. Тамбов губернасы Әҗе карьясендә имам вә мөдәррис.*

*7) Җәмалетдин Хурамшин. Бәләбәй шәһәрендәге мәсҗед хозурында ахунд.*

*8) Мәсгуд Гобәйдуллин. Бөгелмә өязе Бәйрәкә карьясендә имам вә мөдәррис.*

*9) Гатаулла Гобәйдуллин. Самар губернасы Мәләкәстәге мәсҗед хозурында имам вә мөдәррис.*

*10) Җәлалетдин Соколов. Сергач өязе Пашад карьясендә ахунд.*

*11) Гобәйдулла Таһиров. Сембер губернасы Старое Тимошкино карьясендә ахунд.*

*12) Йосыф Сәгыйдов. Түмән өязе Манчыл[1] карьясендә ахунд.*

*13) Мирза Габдерахман Зәбиров. Минзәлә өязе Теләнче Тамак карьясендә имам вә мөдәррис.*

*14) Әхмәдсафа Баһаветдинов. Златоуст уязе Лаклы карьясендә ахунд.*

*15) Мөхәммәдхаҗи Габделгафуров. Златоуст уезды Кыйгый карьясендә ахунд.*

*16) Гомәр Капкаев. Имам.*

*17) Габделвәкил Мөслимов. Шадрин өязендә ахунд.*

*18) Җиһангир Абызгилдин. Уфа шәһәрендә 1 нче мәсҗед хозурында ахунд вә мөдәррис.*

*19) Пәрвазетдин Камалетдинов. Уфа шәһәрендә 2 нче мәсҗед хозурында ахунд вә мөдәррис.*

*20) Мөхәммәтсабир Хәсәнов. Уфа шәһәрендә 3 нче мәсҗед хозурында имам.*

*21) Мөхәмәдһади Фәхретдинов. Уфа шәһәрендә 4 нче мәсҗед хозурында имам вә мөдәррис.*

*22) Хаҗиәхмәд Вәлиев. Уфа шәһәрендә 5 нче мәсҗед хозурында имам.*

[1] Манчыл мәдрәсәсе – яңа ысул буенча укытуга бөтен Россия мәдрәсәләре арасында беренчеләрдән булып күчкән мәдрәсә. Төмән шәһәреннән ерак булмаган Манчыл (Малчын) авылында 1841 елда ачылган мәдрәсәне 1841–1871 елларда сәүдәгәр Габделниязов, 1871–1917 елларда сәүдәгәр бертуган Сәйдуковлар (Нигъмәтулла, Рәхмәтулла, Хәбибулла) үз хисабына тоткан.

*Мәҗлестә иң элек директорның сөальләре укылып, сөальләрне ошбу маддәләргә аерып, һәрберенең тугрысына җавапларыны да яздылар. Ошбу рәвеш илә:*

*1 нче сөаль: мөселманнарның дини мәктәп вә мәдрәсә шәригатьтә нидән гыйбарәт?*

*Җавап: «Әхкяме диния вә әхлакы исламия үгрәтеп, дөнья вә ахирәттә сәгадәтле булмак өчен кирәкле мәгълүматны бирә торган урындыр».*

*Дәлилләр: Аятьләр. Коръәннән дүрт аять китерелә. Хәдисләр: бу урында унбер хәдис язылган.*

*2 нче сөаль: Мәктәп вә мәдрәсәдән гая[1] нәрсә?*

*Җавап: Мәктәптән гая мөселман балаларына уку-язу үгрәтеп, әхкяме исламияне белдермәк, гүзәл әхлак белән тәрбия кыйлыб, дөньяда ахирәт вә сәгадәткә ирешдерә торган юл күрсәтмәк вә мәмләкәтемезнең тыныч вә рәхәт яшәве өчен хезмәт итмәкдер. Әмма мәдрәсәдән гая? Ошбу юлны башкаларга күрсәтерлек голуме диния вә фөнүне дөньявиядән мәгълүматлы вә заманның икътизасына[2] кәмил әшна булган мөфти вә казыйлар, мөдәррис вә мөдәррисәләр, мөгаллим вә мөгаллимәләр, галим вә фәкыйһләр, хатиблар, имамнар, мөәзиннәр җитештермәкдер. (Шушы җавапны исбат йөзеннән өч аять, өч хәдис китерелә.)*

*3 нче сөаль: Мәктәп вә мәдрәсәләрдә укыту тәртибе хакында шәригатьтә бәян бармы?*

*Җаваб: Мәктәб вә мәдрәсәләрдә ысуле тәгълим җиңеллек вә тизлек илә максудга ирешдерерлек рәвешчә һәм ана телендә хоруфе гарәбия илә булмак тиешледер. (Бу турыда ике аять, ике хәдис китерелгән.)*

*4 нче сөаль: Мәктәп вә мәдрәсәләрдә программа.*

*Җавап: Мәктәптә укылачак нәрсәләр: 1) Ана телендә уку, язу кагыйдәләре белән имля вә инша. 2) Коръән мәга[3] әт-тәҗвид. 3) Гыйльме халь. 4) Әхлакый вә гыйбадәти берничә хәдисләр. 5) Гыйльме әхлак. 6) Тарихе мөкаддәс[4]. 7) Тарихе ислам. 8) Тарихе милли. 9) Россия тарихы. 10) Хисап. 11) Җәгърафия. 12) Хифзыссыйхәт[5]. 13) Риязияте бәдәния. 14) Әшгаре мәшруга[6] вә илаһи мөнәҗәтләр. 15) Гыйльме*

---

[1] Гая – соң, монда: аннан соң.
[2] Икътизасына – теләвенә.
[3] Мәга – белән.
[4] Тарихе мөкаддәс – Коръән иңү, таралу, ислам дине тарихы.
[5] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау, гигиена.
[6] Әшгаре мәшруга – дин, шәригатькә багышланган тезмәләр.

*әшья (ягъни нәбатат[1], хәйванат, мәгадин[2] вә зирагатькә[3] тәгаллекъле[4] бераз мәгълүмат. 16) Рәсем әшкял вә хөсне хат[5].*

*Мәдрәсәләрдә укылачак нәрсәләр: мәктәптә укылган фәннәр өстенә: 1) Гомуме Коръән (рәсме әл-мәсахиф[6], тәфсир, вөҗүһе кыйраәт вә вөкуф[7]). 2) Гомуме әл-хәдис (Истыйляхат әл-хәдис[8], тәбакат әр-риҗаль[9], әхвал әр-рават кеби гыйлемнәр). 3) Гыйльме әл-кәлям. 4) Гыйльме әл-фикъһ. 5) Гыйльме әл-ысуле әл-фикъһ. 6) Гыйльме әл-мантыйк. 7) Гарәп теле әдәбияты белән. 8) Сиярән-Нәби вә тарихе ислам[10]. 9) Тарихе әл-әдъян. 10) Тарихе табигый. 11) Тарихе гомуми. 12) Тарихе милли вә ватан тарихы. 13) Хөкүмәт лисане (теле). 14) Гыйльме әл-әхлак. 15) Гыйльме ысуле әт-тәгълим. 16) Гыйльме әл-мәүгыйза вә әл хөтбә. 17) Гыйльме хәяте әл-бәшәр. 18) Риязияте бәдәния. 19) Кануне әсасине [11]тану дәресе. 20) Лисане фарси. 21) Гыйльме әл-икътисад. 22) Гыйльме әхвале рух. 23) Төрки әдәбияты әкъсаме[12] белән. 24) Хикмәте табигыя вә илаһия. 25) Һәйят. 26) Һәндәсә. 27) Гыйльме әл-моназарә. 28) Гыйльме хифзыссыйхәт. 29) Гыйлме әл-хисаб вә әл-җәбер[13]. 30) Гыйльме әл-җәгърафия. 31) Гыйльме хикмәте әл-мәгашь (бакчачылык, игенчелек гыйлеме). 32) Әшгаре мәшруга, мөнәҗәте илаһия. 33) Хөсне хат. 34) Гыйльме тыйбтан[14] бераз мәгълүмат. 35) Фәлсәфәи-диния. 36) Гыйльме кимия[15].*

*Мәҗлес тарафыннан кабул ителгән башлангыч мәктәпләр программасында күрсәтелгән предметларны яклап, һәрбер предметка дистәләрчә аять һәм хәдисләр китерелә. Күп урын алудан куркып, без аларны тулысынча алмадык. Шулай ук мәдрәсәдә укыла торган предметларга карата да бик күп хәдисләр, аятьләр китерелә.*

---

[1] Нәбатат – үсемлекләр.
[2] Мәгадин – казылма байлыклар.
[3] Зирагатькә – игенчелеккә.
[4] Тәгаллекъле – бәйләнешле.
[5] Хөсне хат – матур язу.
[6] Рәсме әл-мәсахиф – Коръәнне дөрес уку, күчереп язу һәм нәшер итү тәртибе.
[7] Вөҗүһе кыйраәт вә вөкуф – Коръәнне дөрес уку тәртибе.
[8] Истыйляхат әл-хәдис – хәдис фәне терминнары.
[9] Тәбакать әр-риҗаль – ислам диненең күренекле кешеләре, хәдисләрне җиткерүче дин галимнәре турында мәгълүматлар.
[10] Сияр ән-Нәби вә тарихе ислам – Пәйгамбәребезнең тәрҗемәи хәле һәм ислам тарихы.
[11] Кануне әсаси – канун нигезләре.
[12] Әкъсаме – өлешләре.
[13] Әл-җәбер – алгебра.
[14] Гыйльме тыйб – медицина.
[15] Гыйльме кимия – химия.

*5 нче сөаль: Һәйяте тәгълимия.*

*Җавап: Һәйяте тәгълимия (мөгаллим вә мөгаллимәләр, мөдәррис вә мөдәррисәләр) хакында торган иң мөһим нәрсә – әһлият[1] вә исламдыр. Әһлияте булган һәр мөслим вә мөслимә кирәк каю сыйныф вә нәселдән булсын мәкъбүлдер[2]. Бинаән галәйһи[3] һәйяте тәгълимия әгъзасы булмак өчен диянәтле, гүзәл әхлаклы, ысуле тәгълимнән хәбәрдар, үзенең өстенә йөкләнмеш вазыйфаны камил үтәрлек икътидарлы[4] булмак тиештер.*

*Бишенче сөальгә булган җавапны исбат йөзеннән тугыз дине аять китерелгән.*

*1913 нче ел 15 нче декабрьдә кич сәгать 10 да мәзкүр матдәләргә карар бирелеп, исемнәре югарыда зикер ителгән әгъзалар имза кыйлдылар (һичбер матдә хакында аерым фикердә калучы булмаган буладыр).*

*Ошбу карарнамә русчага тәрҗемә ителеп, Оренбург мөфтисе тарафыннан чит диннәрне карый торган департаментның директорына (үзенең сөаленә җавап ителеп) җибәрелер, бәлки бу көндә җибәрелгәндер».*

«Шура» журналыннан алып язылган бу материал патша хөкүмәтенең һәм түрәләренең татар мәктәп-мәдрәсәләре турында булган кайгыртучанлыгын ачык күрсәткән шикелле, татар мәктәп-мәдрәсәләре турында аңлау дәрәҗәләре белән кызыксыну үлчәүләрен дә ачык күрсәтәдер.

Шушы уңай белән булган мәҗлес әгъзалары исемлегенә күз салганда, элек татар мәктәп вә мәдрәсәләре нинди кешеләр кулында булганлыгы һәм татар мәктәп-мәдрәсәләренең тәкъдирен кемнәр хәл иткәнлекләре дә тулысы белән ачык булып тора.

*Сәлах Камал*
*1945–1946 еллар*

[1] Әһлият – эшкә сәләт.
[2] Мәкъбүлдер – кабул ителгән.
[3] Бинаән галәйһи – шуның өчен.
[4] Икътидарлы – куәтле, көчле.

# ЭЧТӘЛЕК

С. Камал һәм аның «Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре» хезмәте турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

Кереш сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

Борынгы татар мәктәпләре. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12

I. Ир балалар өчен башлангыч мәктәп *(мәптек яки мәфтек)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12

II. Кыз балалар өчен башлангыч мәктәп . . . . . . . . . . . . . 39

Борынгы татар мәдрәсәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 45

**Салах Камал**

**СТАРИННЫЕ ТАТАРСКИЕ ШКОЛЫ И МЕДРЕСЕ**

**Духовное наследие: поиски и открытия**

Выпуск 25

(На татарском языке)

Редактор А. А. Давлетова
Компьютерная верстка Н. Т. Абдуллиной
Дизайн обложки Т. В. Семиной

Подписано в печать: 23.12.2024.
Бумага офсетная. Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Усл.-печ. л. 9,3. Уч-изд. л. 13. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20